**Ризаэддин Фәхреддин**

# АСАР

# آثار

**Икенче том**

ایکنچی جلد

Казан
«Рухият» нәшрияты
2009

ББК 63.3(2Рос=Тат)
Ф97

Фәнни мөхәррир
*Миркасыйм Госманов*,
тарих фәннәре докторы,
Татарстан Фәннәр академиясе академигы

Фәнни консультант
*Марсель Әхмәтҗанов*,
филология фәннәре докторы

Төзүчеләр
*Илшат Гыймадиев, Рамил Миңнуллин, Сиринә Баһавиева*

Бизәлеш рәссамы
*Шамил Насыйров*

**Фәхреддин Ризаэддин**
Ф97 Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – 304 б.
ISBN 978-5-89706-122-8
© «Рухият» нәшрияты, 2009

## *Төзүчеләрдән*

Татар халкының тарихын, мәдәниятен сөюче укучыларыбыз игътибарына мәшһүр татар галиме, тарихчы, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар» дип аталган дүрт томлы биобиблиографик хезмәтенең икенче томын тәкъдим итәбез. «Асар»ның бу томы 1904-1909 нчы еллар дәвамында җиде аерым кисәк рәвешендә Оренбург шәһәрендә Мөхәммәдфатих Кәримов басмаханәсендә нәшер ителгән.

«Асар» татар теленә тәрҗемә ителеп, хәзерге әдәби тел кагыйдәләренә яраклаштырылып, шул ук вакытта авторның стиль үзенчәлекләре сакланган хәлдә бирелә.

Әсәрнең төп нөсхәсендәге бит саннары ике сызыкчадан соң шакмаклы җәяләр эчендә күрсәтелде.

Китапта тәрҗемәи хәлләре тасвирланган шәхесләр һәм текстта очраган географик атамалар хезмәтнең ахырында аерым күрсәткечләр рәвешендә туплап бирелде.

«Асар»ның өйрәнү даирәсен киңәйтү максатыннан төп текст шулай ук рус теленә дә тәрҗемә ителде.

Китапны басмага әзерләү дәвамында ярдәм иткән галимнәр тарих фәннәре кандидаты Җәүдәт Миңнуллинга, филология фәннәре кандидаты Раиф Мәрдановка чиксез рәхмәтләребезне җиткерәбез.

Асарның моңа кадәр һич дөнья күрмичә, кулъязма хәлендә генә архивларда саклаучы өченче һәм дүртенче томнары да киләчәктә укучыларыбыз кулына ирешер дигән өметтә калабыз.

# ТУГЫЗЫНЧЫ КИСӘК

# طقوزنچی جزء

// [7]

**223. Фәтхулла бине әл-Хөсәен бине Габделкәрим әл-Орый**

Мәшһүр Фәтхулла ахун буладыр. Атасы белән абыйсы Хәбибулла бине әл-Хөсәен турында язылды. Фәтхулла ахун Оры авылында имам, мөдәррис, ахун булып, 78 яшендә 1259 елның рабигыль-ахир аенда (1843 ел, 10 май) вафат булган. Кабере Орыда билгеле.

1181/1767 елның рабигыль-әүвәл аенда дөньяга килде.

1200/1786 елның җөмадиел-әүвәл аенда укыр өчен Сәгыйдь бистәсенә килде.

1201/1787 елның рабигыль-әүвәл аенда Бохарага керде.

1205/1790 елның рабигыль-ахир аенда икенче мәртәбә Бохарага керде.

1209/1795 елның рамазанында кайтыр өчен Бохарадан чыкты.

1209/1795 елның 20 зөлкагдәсендә Оренбурга керде.

1210/1795 елның мөхәррәм аенда Орыга кереп ата вә анасын зиярәт итте.

1210/1795 елда хатыны Сахибкәмал бинте Мөнасиб бине Мәксуд бине Рахманколый бине Мөхәммәдкә өйләнде.

1799 елда Орыда таш мәчет хозурына имамлыкка указ алды.

1814 елда ахунлыкка билгеләнде.

1819 елның 28 августында старший ахунлык ротбәсенә билгеләнде.

1244/1829 елның зөлкагдә аенда Казан шәһәрендә Муса бине Гайсә исемле кемсәнең Фатыйма // [8] исемле кызына өйләнде. Бу вакытта үзе 63 яшендә иде.

Вафат булганында рәсми ротбәсе «имам җамигъ, мөдәррис, мөхтәсиб, старший ахун» дәрәҗәләреннән гыйбарәт иде.

Остазлары: Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Бохарада Гата бине Һади әл-Бохарый һәм башкалар.

Шәкертләре: Мөхсин бине Биккол әш-Шашый, Хөсәен бине Нәзир әл-Кавали, Сәгыйдь бине Хәмид әл-Бәрәскәви, Хисамеддин бине Сәйфулла, Сибгатулла бине Габделкадир әш-Шәрифи, Сәгъдеддин бине Хәбибулла әс-Сабачаи һәм башкалар.Балалары: Габдулла, Хәдичә, Фатыйма. Хәдичә – Нәҗмеддин әл-Хафиз бине Мөхәммәдшәриф бине Арыслан әл-Казакларый никахында вә Фатыйма

Мөхәммәдхәлил ишан бине Гофран никахында иде. Ишаннан аерылганнан соң, Мөхәммәдшәриф бине Габбас бине Габдулла әл-Әшнәкигә никахланган. Ишаннан аерылырга сорап, мәзкүр Фатыйма Җәмгыяте шәргыягә ошбу эчтәлекле гариза биргән: «1819 елда 14 яшемдә вакытымда атам мине Бохара кешесе булган Мөхәммәдхәлил Гофран улына никахландырган иде. Никахны хәзер инде вафат булган ахун Габдессаттар бине Сәгыйдь укыган иде. 2000 сум мәһәремнән чиреген түләп, калганны шул Гофран улы бирмәде, нәфәкалек [яшәрлек мал, алимент] исә һич калдырмады. Хәзерендә Хуканд ханлыгында Ташкент шәһәрендә торадыр, дип ишеттем. Мин исә яшь хәлемдә шул рәвешле ялгыз вә нәфәкасез тормакта идем. Шул сәбәпле Җәмгыяте шәргыя мине Гофран улыннан аерса иде. 12 февраль, 1840 ел». Риваятьләргә караганда, Җәмгыяте шәргыя, ошбу дәгъвага нигезләнеп Фатыйма Фәтхулла кызын Мөхәммәдхәлил Гофран улының никахыннан шул елның 6 мартында аерган.

Әсәрләре: ахун хәзрәтләренең бу көндә бездә булган әсәрләре шушы: 1) «Рисалә фи иттисаф әл-ваҗиб би-л-вәхдәт ал-гадәдия». 2) «Рисалә муһиммә». Һилял хакында булган 10 битлек бу рисалә 1872 елда Казан шәһәрендә басылган. 3) «Мәҗмәгъ». Бу китап 25 юллы 798 биттән торган күчермәдән гыйбарәт. Бу җыентыкта булган күчермәләрнең күбесе һәр ни кадәр турыдан-туры асыл нөсхәләреннән күчерелсә дә, бер кадәресе китап читләреннән вә билгесез аңлатмалардан җыелган. Хәтта бер җирдә (635 биттә) имам Мөхәммәд бине әл-Хәсән эш-Шәйбани китабы буларак «Җамигъ әл-гараиб» исемендә бер китап күрсәтелгән. Хәлбуки әлеге имамның тәрҗемәсен язган бөек мөәллифләр – безгә мәгълүм булганнары – бу исемдәге китабы барлыгына ишарәт итмиләр.

Замандашлардан бер зат бу җыентык хакында: «Бу китапта фикъһ, кәлям, тәфсир, әхлак, тыйб, һәндәсә [геометрия], һәр шәй бар, фәкать таянырлык бер шәй юк!..» – дигән.

Тиешле дәрәҗәдә игътибар ителерлек беркадәр нәрсәләр күрелер, теләгәннәр мөрәҗәгать итә алалар.

Хатлары: ахун хәзрәтләренең күп язмалары бу көндә китапханәбездә бар. Болар исә сәясәткә кагылышлы нәрсәләр булмаган кебек, чит дин вә башка милләт әһеленең

намусларына тиячәк нәрсәләр түгел. Бәлки үз халкыбызның горефләренә вә үз гадәтләребезгә бәйле нәрсәләрдер. Шулай итеп, боларны нәшер итүдә һичкемгә зарар булмаса кирәк. Болардан Русия мөселманнарының иҗтимагый тормышы өчен күп файдалар күрелер. Язган вә күчерелгән шәйләр күп затлар карашында файдасыз булып күренсәләр дә, ләкин файдасыз шәйләрнең бөтенесен юкка чыгару кирәк булмас, әгәр дә кирәк булса, // [13] дөньяда күп адәмнәр, бигрәк тә каләм белән мәшгуль затлар никадәр бәхетле булыр иде!... Моннан башка, бер кемсә карашында бер дә исәпкә алынмаган шәйләрнең кайберләре, ихтимал ки, башка кемсәләр карашында әһәмиятле дә булыр. Инсан өчен бөек тырышлык белән табылган шәйләрнең газиз булачагында шөбһә булмас. Мин дә исә бу язмаларны булдыру юлында мадди вә мәгънәви мәшәкатьләр чиктем, шуңа нигезләнеп монда китермичә калдыра алмадым, һич нәфесемне риза итә алмадым да китердем. Фәкать заман үзенең никадәр кодрәтле икәнен күрсәтә белер. Монысы исә минем эшем түгел, заман эшедер.

Ахун хәзрәтләренең хатларын, рәсми вә рәсми булмаган өлешләренә аерганнан соң, ике өлешкә бүлеп тездек. Кайбер тарихлары [даталары] булмаганнарын үз фикеребезчә туры килә торган урыннарына куйдык.

Мөляхәзә: фазыйләтле ахун хәзрәтләренең күп хатларын бу җирдә китерергә насыйп булды. Үз сәләтләренең нәтиҗәсе булган кайбер әсәрләрен дә күргән идек. Болар исә мәйдандадыр, һәркем күрер вә аңы ирешкән кадәр бәя бирә белер. Телгә алынган әсәрләр ярдәме белән без дә бу зат хакында киң вә тирән фикерләр йөртү белән күп вакытлар зиһенебезне эшләттек. Безнең көчсез фикеребезгә күрә ахун хәзрәтләренең гыйлемдә булган мәртәбәсе Шам галимнәреннән вә үзенең дә гасырдашларыннан булган сәед Мөхәммәдәмин Габидин бине сәед Гомәр Габидин әл-Хөсәени әл-Хәнәфи дәрәҗәләренә караганда күп мәртәбә түбәндер. Сәед Ибне Габидин Димәшкъ шәһәрендә 1198 елда дөньяга килеп, ахун хәзрәтләреннән 17 яшь кече булып, 7 ел мөкаддәм 1252 елның рабигыль-әүвәл аенда вафаттыр.

Сәед Ибне Габидин хәзрәтләре никадәр генә кирәгеннән артык күчерү белән мәшгуль булса да вә гыйбарәләрдә булган игътибарсызлык вә кайбер җитешсезлекләре сәбәбеннән хәтта иң мөһим бәхәсләрне нәтиҗәсез калдыру кебек //

[65] гыйльми көченә туры килмәгән эшләрдә катнашкан булса да, үз мәсләге булган хәнәфи мәзһәбендә гүзәл сәләтләре булганы инкяр ителмәс. Моннан башка гарәп теле табигый вә саф булганыннан, һәркемне шатландырачак сурәттә ләззәтле телгә дә иядер. Бүгенге саф вә җиңел булган гарәп әдәбияты Шам христианнары тырышлыклары нәтиҗәсендә барлыкка килгәнен бәян иткән әсәрләрдән күбесен укыдык. Боларның гүзәл хезмәтләрен һәр ни кадәр инкяр итмәсәк тә, әгәр дә кодрәтебез булса иде, безләр бу әдәбиятның нигезе сәед Ибне Габидин, Мөхәммәд әл-Мөхибби, тарихчы Габдеррахман бине Хәсән әл-Җәбәрти кебек затларның әсәрләре булачагын дәгъва итәр идек.

Ахун хәзрәтләренең гарәби гыйбарәләре һәр ни кадәр кимчелексез булса да, сәед Ибне Габидин язмаларына тиң булачак дәрәҗәдә түгел икәнен аның тарафдарлары да таный дип уйлыйм. Ихтимал, ахун хәзрәтләре зирәклек, тырышлык вә гайрәт ягыннан Ибне Габидин дәрәҗәсендә, бәлки аннан да бөегрәк мәртәбәдә булыр, чөнки аның яшьлек еллары вә укуда булган вакытлары безгә мәгълүм түгел. Фәкать без бу җирдә ялгыз әсәрләренә таянып фикер йөртеп бәя бирдек. Әгәр дә ахун хәзрәтләре Ибне Габидин укыган остазлар мисалында төпле гыйлем ияләреннән укыса вә Ибне Габидин аралашып, дуслашкан шәехләр мисалында гыйлем диңгезләре булган шәехләр белән аралашып торса иде, ихтимал ки, Ибне Габидин дәрәҗәсеннән дә югары булган бер баскычка аягын куйган булыр иде. Ләкин ни чара ки, заман таләпләренә вә гадәтләргә ияреп гыйлем туплау теләге белән көнчыгыш тарафына сәфәр итәргә мәҗбүр булган. Анда исә гыйлем исеменә бер файдасы вә кирәклеге булмаган әсәрләр укып, китап эчтәлекләрен ятлап, канны боза торган вә инсанның табигый халәтеннән чыгуына сәбәп булган // [66] низаг вә бәхәсләрне өйрәнеп, гыйлем мәйданында бөек адымнар атларга киртә булачак китапларга игътибар итеп, мәгарифнең чиксез киңлекләрендә иркенлек белән очачак канатларын куәтсезләндерәчәк күп кенә нигезсез ышану, иманулар алып кайткан. Ахун хәзрәтләренең бөек мәртәбәләргә ирешмичә калуының сәбәбе менә шул булыр. Бу сүзләремнең максаты хәзрәтне, Аллам сакласын, кимсетү түгелдер. Бәлки моның барган юлында ярдәм бирмәгән заманыннан һәм тәрбиясеннән зарланып сукранудыр.

Башка хәлләре: Ахун хәзрәтләре үз гасырында вә үз тиңдәшләре арасында үз-

үзен гаять олы тотып, зур дәрәҗәгә ия булган. Шәргый фәтваларны бирү вә дәгъваларны тикшереп хәл итү мәсьәләсендә бар көч вә мөмкинлек үзендә булган, Казан вилаятеннән башка хәтта Сембер вә Вятка вилаятендә булган мөселманнар мөрәҗәгать итә торган булганнар. Элек заманда дәресе куәтле // [72] вә шәкертләре дә күп булганлыктан, Мәхкәмәи шәргыядә әгъза булган затларның кайберләре моның шәкертләре булу сәбәпле, мәхкәмә тарафыннан да игътибарга лаек булган. Мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим гасырында зур абруйга ия булган. Хәтта күп мәсьәләләр хакында иң элек хосусый сурәттә моның фикере соралыр вә соңрак теркәлер, имеш. Соңрак, бигрәк тә Габделвахид мөфти бине Сөләйман көннәрендә, уку-укыту эшләрендә вә башка мәсьәләләрдә дәрәҗәсе беркадәр түбәнәйгән. 1840 елның 2 октябреннән языла башлаган имтихан дәфтәренә караганда, 1844 ел башына кадәр фәкать бер генә шәкерте имтихан ителгән. Хәлбуки замандашлары булган мөдәррисләрнең күп-күп шәкертләре [имтиханга] килгән.

Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани дә язган.

**224. Габделвахид бине Габделмәннан бине Аблай**

Бөгелмә өязе Минзәләбаш авылында имам, мөдәррис вә ахун // [73] булып, 72 яшендә, 1259 елның 3 зөлкагдәсендә (1843 ел, 14 ноябрь) вафат булды. Кабере шул авылдадыр. Асылы Зәй елгасы буендагы Габдеррахман авылыннан иде. Атасы Габделмәннан типтәрләр старшинасы хезмәтендә булып гомер кичергәне мәгълүм. Чистай шәһәрендә имам вә мөдәррис булган Габделгафур бине Габделмәннан моның бертуганы иде. Габделгафурдан башка Габдессаттар, Мәхбүбә, Хәдичә, Габдулла, Габдеррәшид исемле тагын туганнары бар иде. Әлеге зат белән Габделгафур шөһрәтле мөдәррисләрдән, калганнары да гыйлем вә фазылдан мәхрүм түгел иделәр. Шуңа нигезләнеп Габдеррахман авылында вә гомумән Бөгелмә якларында Габделмәннан йорты гыйлем йорты диергә лаек бер йорт иде. Фәкать бу гыйлем ханәсе бу көндә сүнде, андагы дәвамчылары ялгыз бер адәм йогынтысыннан гыйбарәт булып кына калдылар, элекке заманда бөек затлар булганын белгәннәре булуы да шөбһәледер. Мәңге үзгәрешсез Аллага барлык мактавыбыз!

Габделвахид ахунның хатыны үз остазы булган Валид бине Сәгыйдь кызы

Хәдичә булып, балалары Мөхәммәдлатыйф, Мөхәммәдсадыйк, Мөхәммәдвәли, Гөлҗәүһәр исемле иделәр. Мөхәммәдлатыйф Минзәләбашында имам булып гомер итте, бу көндә вафаттыр. Мөхәммәдвәли исә Чалпы авылында Галибай бине Ярмөхәммәд хозурында укыганнан соң, Дагыстан тарафына китте вә кире кайтмады.

Шәкертләре: Мөхәммәдмөкыйм бине Гаделшаһ вә башкалар. Шәкертләре кыш көннәрендә биш йөз кешеләп булыр иде; дәресе гүзәл вә тәрбиясе файдалы иде; фарсы теленә булган осталыгы шулкадәр иде ки, Исбаһанда [Исфахан] тәрбия алган бер кемсә кебек һич хатасыз язар вә озак уйлап тормыйча тугры сөйләр иде; карендәш кабиләсен бик сөяр, шуның өчен // [74] аларның ерак вә якында булганнарының хәлләреннән хәбәрдар булып торыр, кирәк ярдәмнәрен бирер итәр иде, дип сөйлиләр.

### 225. Зәйнулла бине Улмазкол бине Хуҗамкол

Верхнеурал өязе Калкан авылында имам вә мөдәррис булып, 1259 ел зөлхиҗҗәдә (1844 ел, 3 гыйнвар) 68 яшендә вафат булган. Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавый тарафдарларыннан булып, бөтен гомерен шәкерт укыту белән кичерде, диләр.

### 226. Нигъмәтулла бине Биктимер бине Тукай бине Үтәгән әс-Салавычи

Эстәрлетамак өязе Эстәрлебаш авылында имам вә мөдәррис булып, 72 яшендә 1260/1844 ел мөхәррәмендә вафат булган. Асыллары Малмыж өязе Салавыч авылыннан булып, бабасы Тукай бу тарафка күчкән. Атасы Биктимер кәсеп әһеле һәм билгеле сәүдәгәрләрдән булган, имеш. Нигъмәтулла хәзрәтләренең тууы һәм үлүе Эстәрлебаштадыр. Кабер ташында гарәпчә: «Бу кабер шәех, нәкышбәндия тарикатенең олуг шәехе Нияз Мөхәммәд Ниязколый әт-Төрекмәни әл-Бохарыйның дәвамчысы, Әбү Мөхәммәдхарис Мөхәммәд Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрлибаши кабередер. Аллаһның рәхмәтендә булсыннар», – дип язылган. Фарсыча шигъри юллар да язылган. Кабере билгеле, аңа зиярәт кылалар.

Остазлары: Фазлулла бине Сәйфулла әл-Кизләви, Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни вә башкалар. Шәехе

дә Бохарада Әбу Салих Ниязколый әт-Төрекмәни булып, аның даирәсендә күп заман аерылмыйча йөрде вә тарикатьтә рөхсәт алды.

Шәкертләре: Габдессаттар бине Габдулла әт-Туймазый, Сәед бине Нурмөхәммәд әл-Орый, Әхмәдшаһ бине Габдулла әс-Сарлы, Фазлулла бине Фәйзулла әт-Тактавый, Ибне Габделхәмид вә башкалар.

Балалары: Мөхәммәдхарис, Мөхәммәдхаррас, Мәрзыя. Мәрзыя Балыклы Күл авылында ахун Хөснеддин бине Шәмседдин никахында иде. Уллары алда телгә алыныр.

Туганнары: Гобәйдулла, Гыйсмәтулла, Сиражеддин, Сәгъдеддин, Хәмидә. Боларның балалары вә нәселләре күп вә төрле җирләрдә таралган һәм Тукай фамилиясе белән билгеле.

Нигъмәтулла хәзрәтнең дөньясы иркен, шәкертләре күп, яраны хисапсыз, игътибары олы иде, үзе гади, диндар, зөһед вә тәкъвалык белән шөһрәт казанды; моның заманында Эстәрлебаш авылында хакыйкый бер «дар әл-голүм» – гыйлем йорты булды. Күпчелек дәресе тәфсир, хәдис, әхлак булыр, // [79] тәфсирдән Бәйдавиның «Әнвар әт-тәнзил»не вә тәүхид һәм [Аллаһның] сыйфатлары гыйлемендә Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавыйның «Шәрх гакаид нәсәфия»сен укыта иде, дип әйтәләр. Шулай ук моның балаларының да халык арасына гыйлем вә гүзәл холык тарату хакында булган иҗтиһадлары вә калдырган әсәрләре аз заманда гына онытылмас дип уйлыйм. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Галим вә заһид иде, гыйбадәте күп вә рухи үсүе камил иде, мәҗлесе һәр фазыйль вә галимнең барып баш иячәк урыны иде, заманасында булган шәехләрнең олугы вә имамнарның игътибарлысы иде, һәркем моның хакында яхшы фикердә булыр вә мактап сөйләр иде, үзе Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавыйга ихлас бирелгән кеше булып, шәкертләренә аның китапларыннан дәрес укытыр вә аның мәсләген таратыр иде», – ди. Пәйгамбәребез рәсүл әкрам галәйһи әс-саләту вә әс-сәлам һәм әсхабы юлында булганнар өчен Әбеннасыйр мәсләгендә булу лазем килер. // [93]

### 227. Хәсән бине Габделмәҗид

Бөре өязендә Йәркәй авылында имамлык, дәрес бирү белән шөгыльләнеп, 1260

елның сәфәр аенда (1844 ел, 2 март) вафат булган. Яше 65 иде. Укыткан китаплары: «Пәнд Гаттар», «Гөлестан», «Кальбестан», «Мәсләк әл-мөттәкыйн», «Ширгать әл-ислам» булган, имеш. «Ширгать әл-ислам» китабын бик белеп укыгыз! Бу китап дөньягызга да җитәр, ахирәтегезгә дә!» – дип, шәкертләренә нәсыйхәт иткәне риваять кылына.

# УНЫНЧЫ КИСӘК

## اونونچی جزء

// [96]

## 228. Габделхалик бине Габделкәрим

Уфа тирәсендәге Торна Сынташтамак авылында имам вә мөдәррис. 1260 (1844) елның рабигыль-әүвәл аенда 75 яшендә вафат булган. Кaберендә таш булса да, язуы юк. Хатыны Күскәй авылында Әхтәм исемле бер имам кызы, Мөһризад исемле иде. Габделкадыйр ахун бине Сөләйман кызы Бибихәбибәнең кызы буладыр. Уллары: Габдеррәкыйб, Әхмәд, Мостафа. Кыйраәт гыйлемендә иҗазәт бирелгән шәкертләре: Мозаффар бине Габделгаффар әт-Торышый, Исмәгыйль бине Тимергали әс-Сөләймани һәм башкалар.

Габделхалик хәзрәт Уфа тирәсендә Агарды авылында 1185 ел ахырында дөньяга килеп, шунда башлангыч гыйлемнәрне алганнан соң, мәгърифәт кәсеп итү максатыннан Казанга сәфәр кылды. Соңында Аккирмәнгә барды, аннан соң 1211 (1798) елда Хиҗазга юнәлеп, Төркиягә чыкты һәм шул елда Хадим шәһәрендә берни кадәр вакыт сәед Мөхәммәдәмин мөфти исемле бер зат (риваятьләргә күрә, «Тарикаи Мөхәммәдия»не шәрехләүче Әбу Сәгыйдь Мөхәммәд бине Мостафа бине Госман улы, имеш) хозурында булды, кабат хаҗ кылды. 1223 (1808) елда ватанына кайтып имамлык өчен рәсми рөхсәт [указ] алды, мәдрәсәләр оештырып, шәкертләр тәрбияләде. Күпчелек дәресе дә Коръән шәрифне матур итеп күчертү булган, имеш. Әхмәд исемле улы моның тәрҗемәи хәлен болай // [97] яза: «Әткәбез Габделхалик Габделкәрим улы, укыр өчен ислам илләренә сәфәр итеп, Хадим авылына барган. Бу вакыт Хадими хәзрәтләренең Мөхәммәдәмин, Ногман, Мостафа исемендә өч уллары булган иде. Атабыз исә Мөхәммәдәмин хәзрәтләренә шәкерт булып, аның хозурында алты ел калган. Соңыннан Мәккәгә барып ике ел вә Мәдинәдә дә бер ел торган. Соңыннан Мисырга килеп Салих әз-Зүҗәҗи хәзрәтләреннән гыйлем кыйраәт укыган, иҗазәт тә алган. Мисырда бер ел, Коддес шәрифкә [Иерусалим] килеп бер ел, Шам шәрифтә [Димәшкъ] алты ай вакыт кичергән».

Кайбер язуларында имзасын Әбу Хәбибә рәвешендә вә кайберләрендә Әхмәд әл-Бохарый дип язганлыгы риваять кылына. Моның берәр сәбәбе булдымы? Юкса фәкать бер модага иярү булдымы?.. Кешеләргә биргән иҗазәтнамәләре бар.

Искәрмә: ошбу иҗазәтнамәләр асыл нөсхәләреннән күчерелгән булсалар да, исемнәр хакында кайбер шөбһәләр кала. Күпчелек моның кебек иҗазәтнамәләр әүвәлдән тезелгән бер нөсхәдән чит кемсәләр каләмнәре белән // [100] күчерелеп, шәехләр тарафыннан фәкать имза куелыр, кайбер вакыт имза урынына исемнәре язылган мөһерләрен салырлар. Хәтта кайбер вакыт шәехләр үзләре һич белмәгән хәлдә, янында йөрүчеләр тарафыннан мөһерләре басылганы риваять ителә. Шул сәбәптәндер ки иҗазәтнамәләр күп хаталы булыр һәм тиешсез кешеләргә бөек-бөек хөрмәт-дәрәҗәләр бирелер. Бер кемсә кулында күпсанлы иҗазәтнамәләр булуы ул кемсәнең камиллек иясе икәненә тугры вә ачык бер дәлил булмаганы кебек, иҗазәтнамәләрдән мәхрүм булганнарның да адәм санынннан булмаулары мәҗбүри түгел. Хосусан бу заманнарда бирелгән иҗазәтнамәләр хакында язачак сүзем күп булган кебек, дәгъвамны исбат итәр өчен китерәчәк дәлилләрем көчле. Фәкать боларны язарга бу юлы икътидарым юк. Дөньяда яшәгән кемсәләр өчен бер-ике булса да дуска мохтаҗ булу табигый хәл булганга күрә, әгәр дә гыйлемнең берсеннән берсенә күчүе яки тугры юлдан бару турындагы фикерләремне язарга булсам, бөтенләй бер иптәшсез калырга тиеш булачак. Моңа охшаган кайбер сәбәпләр өчен бөек вә заһид сахабәләрдән булган Әбу Һөрәйрә дә (Аллаһ аннан разый булсын) кайбер хәдисләрне күңелендә саклап тотарга мәҗбүр булганлыгы мәгълүм.

Язган китаплары: 1) «Мәҗами‘ әл-хакаикъ»; 2) «Әд-дәкаикь әл-мүхкәмә». Моның ахырында гарәпчә: «Китап 1219 елның рамазан ае урталарында Мисырда тәмамланды. Язучысы Мәккә-и мөкәррәмәдә гыйлем эстәгән Әбу Хәбибә бине Габделкәрим әл-Агардавый», – дип язылган. Болардан башка // [101] «Бәхр әл-каләм», «Халхали», «Шәрх әл-мәвакыйф», «Каһистани» исемле китаплар язган.

Сәяхәте вакытында язылган гарәп телендәге бер мәктүбе дә күренде.

## 229. Тулунхуҗа бине Муса

Эстәрлетамак өязендә Җиргән авылында указсыз булган хәлдә дәрес биреп, картаеп, 75 яшендә 1260 (1844) елның җөмадиел-ахир аенда вафат булган.

Остазлары: Габбас бине Габдеррәшид әл-Күшәри, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әс-Сәгыйди һәм башкалар. Мәшһүр Җәгъфәр ишан бине Габди

хәлифәсе булган һәм Хәлекәй авылында [яшәгән] Әхмәр исемле кемсәдән рөхсәт алган иде. Үзенә исә Гыйләҗеддин бине Кәнҗә Фулад исемле кемсә урынбасар булды. Сәхиулла исемле улы шул Гыйләҗеддиннән рөхсәт алып мөридләр тәрбияләде. Җиргәндә рәсми имам булып җитмеш бер яшендә 1315 (1897) елда рабигыль-ахир аенда вафат булган. Гыйлеменә караганда аңлылыгы артык бер зат иде, дип сөйлиләр.

**230. Хөснеддин бине Ибраһим бине Бикмөхәммәд**

Бәләбәй өязендә Әнәч авылында имам вә мөдәррис булып, 1260 (1844) елның 17 рәҗәбендә вафат булган. Остазы Казан шәһәрендә Салих бине Сәгыйдь әл-Кили иде.

// [103] Шәкертләре: ахун Хөснеддин бине Шәмседдин әл-Әҗдани, Тимербәк бине Вилдан әл-Куганакый, Габдеррахман бине Мөхсин әл-Ашкадарый, Габделхалик бине Кәттаб әт-Тукаи һәм башкалар.

Балалары: Зыяэддин, Фәттахеддин, Кәшшафеддин, Гыйсамеддин, Сәяхеддин. Гүзәл холыклы, гадел вә инсафлы бер зат булганын риваять итәләр.

**231. Хисамеддин бине Мөэмин бине Будач бине Айтуган бине Кудаш бине Апач бине Мирас**

Бөгелмә өязендә Әлкәй авылында имам вә мөдәррис булып, 86 яшендә 1260 (1844) елның рамазан аенда вафат булган. Хатыны Габделҗәббар бине Габдеррахман әт-Тайсуганый кызы Гайшә иде.

Балалары: Шәрәфеддин, Фәхреддин, Фәттахеддин, Садреддин, Хәйдәр һәм башкалар.

Остазлары: Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни һәм башкалар.

Шәкертләре: Рәмкол бине Максуд әл-Иштирәки, Фәхреддин бине Сөбханкол әл-Кичүчатый, Мөхәммәдшаһ бине Мөхәммәдрәхим әл-Якый, Борһанеддин бине әл-Мөхәммәд бине Нурмөхәммәд, Хәбибулла бине Рәфыйк эн-Надири, Сабит бине Вәлид әл-Мәсгуди, Габделгафур бине Сәйфулла әл-Балтачый һәм башкалар. Ошбу

шәкертләре үз заманнарында белем һәм хөрмәт әһелләреннән саналалар иде. Мәдрәсәсендә гадәттән тыш дөрес вә гүзәл язу белән язылган «Тәлхыйс әл-мифтах» китабының нөсхәләре күрелгәннән, шул фән белән шөгыльләнгән дип уйлыйбыз.

// [104] Үзе бер ара барлык шәкертләрне таратып тәфсир язарга тотынды вә моны исә язып тәмам итү, чагыштырып хаталарын төзәтү, тиешле аңлатмаларны сәхифәләр читенә язу алты елга сузылды. Моннан соң кабат шәкерт җыеп әүвәлгечә дәрес укытты, диләр. Телгә алынган тәфсир ике җилд [том] булып үз Вафатында башка китаплары белән бәрабәр сатылып, кулдан кулга йөреп, вә моннан унбиш еллар элек Бөгелмә өязендә Кәшер исемле авыл имамы Әхмәд бине Котлыкадәм бине Исмәгыйль бине Мөнасиб бине Йосыф бине Надир исемле кемсә милегендә икәнен ишеткән идем. Бу көндә исә кемнәргә күчкәндер, мәгълүм түгел. Асыллары Мамадыш өязе Сатыш авылыннан; Мөэмин бине Будач шул авылда имам булып, вафат булган. Халык арасында Хисамеддин хәзрәт дип мәшһүр булган хәлдә рәсми кәгазьләргә үзе «Ихсан бине Әмир» дип имза иткәне мәгълүм булды.

### 232. Габделгафур бине Габделмәннан бине Аблай

62 яшендә 1260 (1844) елның рамазан аенда (17 сентябрь) вафат булган. Асылы Бөгелмә өязе Габдерахман авылында булып, Габделвахид бине Габделмәннан ахунның бертуганы. Анасы Кәшер авылыннан Гөлназик бинте Ибраһим иде. Хатыны Ормышлы авылында Юлдаш бине Иманкол кызы Сахибҗәмал 1311 елда рамазан аенның 9 да вафат булган.

Остазлары: Сәйфеддин бине Әбүбәкер әш-Шыңарый, Әбеннасыйр // [105] Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавый һәм башкалар.

Шәкертләре: Габделгафур бине Сәйфулла әл-Балтачый, Мөгыйнеддин бине Габдеррәшид әш-Шөкри, Фәхреддин бине Мөхәммәдсадыйк әс-Сүни, Хәсән бине Зөбәер әл-Килими, Хәбибулла бине Хансөяр әз-Зиминҗәви, Мөхәммәдшаһ бине Мөхәммәдрәхим әл-Йакый, Габделгали бине Гобәйдулла әл-Бәйрәкәви, Мөхәммәд әл-Әмин бине Мөстәкыйм әс-Сәпәи, Вәлиулла бине Габделгафур әл-Эстәрли һәм башкалар.

Балалары күп булса да, гомумән гыйлемнән мәхрүм булганнары сәбәпле үзенә

алмашка килүче була алмадылар. Гаишә исемле бер кызы Петербургта гаскәри ахун Кәмаледдин бине Габдулла исемле кемсә никахында иде. Мәхбүбә, Хәдичә исемле кыз кардәшләре берсе вафатыннан соңында икенчесе бабабыз Сәйфеддин бине Сөбханкол белән никахлашканнар иде. Шул яктан атабызга ул абый була. Дәресе гүзәл, иҗтиһадлы, нәсыйхәт бирүче бер зат булып, хисап гыйлемендә аерым сәләтле булганлыгы риваять ителә. Шәкертләрне алып чыгып, тауларның биеклекләрен алып, аларга күрсәтер, шулай итеп үзләреннән дә тәҗрибә һәм практика ясата торган булган. (Алай да һәндәсә [геометрия, инженерлык] гыйлемендә булган осталыгы землемерный училищеда укучы балалар кадәр булыр.)

1223 елда Бохарага барып андагы хөрмәтле затлардан укып, ничә еллардан соң бу мәмләкәткә кайтты һәм башта Минзәлә өязендә Туйгилде авылында Хәбибулла бай бине Хәмид чакыруына күрә килеп мәдрәсәләрендә дәрес укытты. Соңында моннан күчеп 1236 елда Мамадыш өязе Шайтан Елга авылында имам вә мөдәррис булды. 1237 елда Чистай шәһәрендә булган мәчеткә имам булып килде һәм зур мәдрәсәләр бина иттереп шәкерт җыйды. Бу шәһәрдә якынча унбиш еллар торып, кисәк үлем белән вафат булган. Йорты бүгенге агач // [106] мәчет каршысында, урамның икенче тарафында иде, дияләр. Бер чук китапларын вә кайбер мәктүпләрен Петербург шәһәрендә гаскәри ахун Хәмидулла бине Габделхәмид әл-Халиди китапханәсендә күргән идек. Бер хаты Шайтан Елга авылыннан Бөгелмә өязе Шөгер авылы имамы Габдеррәшид бине Мөхәммәдкә язылган булган. Мөгыйнеддин исә Габдеррәшиднең улы булып, Таҗеддин дә Кичүчат авылындагы Фәсыйхеддин Сөбханкол улыдыр.

Бу кемсә хакында әтиебез: «Чистай шәһәренә барган вакытымда Габделгафур хәзрәт хозурына кердем, Бөгелмә өязендә булган якын һәм туганнарымны дикъкать белән берәм-берәм сорашты, моннан соң үз хәлләрен хикәят итте, балаларының җитешсезлекле галәмәтләрен бик тәэсирләнеп, кайгырып сөйләде. «Авылларда булган рәхәт вә тыныч тереклекләрне ташлап биек урын вә шөһрәтле дәрәҗәләргә күз тотып килгәнемнең юкса җәзасымы булачактыр, дип, үз-үземә бөек шелтәләр әйтәмен, сезнең аталарыгыз фазыл әһелләре булган хәлдә авылларга канәгать иттеләр, дөньяда булган суларны уч белән генә эчәргә ризалык күрсәттеләр, бәлки шуның

әҗере булыр ки Аллаһ аларга тәрбияле балалар насыйп итте, үзләре дә ким-хур калмадылар», – диде. Моннан соң гыйлем турында сөйләп, // [107] беркадәр мәгълүматны бәян итте.

Габделгафур хәзрәт вафат булганнан соң Чистай шәһәрендә имам вә мөдәррис булыр өчен Әхмәд бине Халид әл-Мәңгәри сайланып, 1845 елның 15 март көнендә Уфа шәһәренә килеп имтихан булса да, указ алу алдыннан булса кирәк, Троицки шәһәренә китеп, имам вә мөдәррис булды. Габделгафур хәзрәт вафат булгач, мәхәллә хезмәтен Наратлы авылы имамы Баһаведдин Зәйнелгабидин улы башкарып торган иде. 1846 елдан башлап Габделмәннан бине Гадел бине Котлуг әл-Әдәмсувый да бер ара шул вазыйфаны башкарды. Шул елның 8 октябреннән соң Мөхәммәдеззакир бине Габделваһһаб әс-Саснавый рәсми имам булып хөтбәләр сөйли вә уку-укыту гамәлләрен үти башлавы риваять кылына. // [108]

**233. Туабил бине Сәбәкъ бине Сарман бине Күчтан бине Тимерфулад бине Сиюш бине Тимаш**

Бөре өязендә Югәмеш авылында 82 яшендә 1260 (1844) елның шәүвәл аенда вафат булган. Бу җирдә булган нәсел-нәсәбе үз каләменнән бер генә арадашчы аркылы китерелде. Күбәк авылында хаҗи Ишмөхәммәд бине Заһид мәдрәсәсендә 1208 елда вә Чалпы авылында Габделкәрим бине Габдулла мәдрәсәсендә 1214 елда китаплар язып тәмамлаганы мәгълүм булды. Болардан башка Вәлид бине Мөхәммәдәмин әс-Сәгыйди хозурында да белем алган. 1216 (1801) елда Югәмеш авылына имамлык өчен указ алды. Тырышып дәрес укытканын, хозурында күп могтәбәр затлар файда алганны риваять итәләр. Кәмаледдин исемле улы шәкерт булган вакытында Бохарада, Җәлаледдин исемле улы Төркестанда вафат булганнар, һәр икесе бу мәмләкәттә Шаһиәхмәд бине Рәфыйк әс-Симәки әсхабыннан иделәр. Таҗеддин исемле улы шәкерт вакытында Казанда вафат булган. Үзе урынына Садрелислам исемле улы имам булып, шул авылда 1296 елда вафат итте, дияләр.

## 234. Мөхәммәдрәхим бине Әмир бине Җәгъфәр әт-Таршынавый

Казан өязе Таршына авылында имам булып, шәехлек итеп, 1260/1844 елда вафат булган. Бохарада хәлифә // [109] Ниязколый әт-Төрекмәни хозурында тәрбияләнеп рөхсәт алган иде. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Тәкәллефсез, диндар иде, риваятьләргә күрә догасы әсәрле булыр, ул өшкергән мәҗнүннәр тиз вакытта сәламәтләнерләр, имеш, үзенә Габденнасыйр ахун бине Рахманколый әл-Казаный ихлас бирелгән булып хәтта ки мөридләре хисабына кермеш. Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри: «Улы юклыгыннан шикаять итеп догасын алган вә шуннан соң улы Мөхәммәднәҗиб дөньяга килгән», – дип яза.

## 235. Фәхреддин бине Ибраһим бине Хуҗаш әл-Казаный

90 яшенә ирешеп 1260/1844 елда Бохарада вафат булган. Казанлы Ибраһим әфәнденең Мөнәввәр бинте Йосыф әл-Ашытый исемле хатынынннан туган. (Ибраһим әфәнденең тәрҗемәи хәлен карагыз.)

Остазлары: Үз атасы Ибраһим бине Хуҗаш, Гатаулла бине Һади әл-Бохарый һәм башкалар.

Шәкертләре: Фәхреддин бине Вәлид әл-Казаный, Шаһиәхмәд бине Әбу Йәзид әл-Мәмәши, Фәхреддин бине Мостай эн-Норлатый, Габдеррахман бине Вәлид әл-Казаный һәм башкалар.

Балалары: Мөхәммәдрәхим һәм башкалар.

Фәхреддин әфәнде Бохарага барып беркадәр укыганнан соң Казан шәһәренә кайтып бер ара вакыт торды, соңыннан кабат Бохарага барып анда калды, Коръән шәрифне матур итеп күчерү белән мәшгуль булды. Бохара әмире Хәйдәр бине Мәгъсүм бу заттан Коръән шәриф укыганы риваять ителә. Моның хәленнән хәбәрдар булган затлар: «Кыйраәт гыйлемендә хак галим иде, Ибраһим әфәнде Дагыстан вилаятьләреннән китергән гыйлемнең бер өлешен Бохарага алып барып, ул // [110] тарафка таратты вә Бохарада торып борынгы грек традициясенә бирелгән бичара бер төркем шәкертләрнең игътибарын Коръән шәрифкә юнәлтте», – диләр.

// [113]

Әсәрләре: «Җамигъ әр-румуз» шәрехе «Гавас әл-бәхрәйн» (бу елларда Казанда

басылды). «Хашия Әхмәд әл-Җүнди», «Хәваш әл-җәмал әш-Ширази», «Шәрх ахун Йосыф әл-К(а)р(а)багый», «Хашия әт-Тәүзыйх», Шатыйби касыйдәсенең кыскартылган варианты һәм башкалар. Әсәрләреннән ялгыз «Минһаҗ әл-хутаба ви шәрх хутаб ал-фусаха» исемле китабының кайбер урыннарын күрдек. Бу китап исә 163 бит булып үткән елларда Казан шәһәрендә басылды.

### 236. Таһир бине Габделхаликъ әт-Түнтәри

Малмыж өязе Мәчкәрә авылында икенче мәчеттә имам булып, 1260/1844 елда вафат булган. Каберлектән читтә берьялгызы күмелгән. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Диндар вә тәкъва иде, байлар белән катнашы аз вә алардан кисәтә, саклана иде, аз сүзле вә сабыр һәм заһид иде, ишан исеме белән шөһрәте бар иде», – ди.

### 237. Ибраһим бине Габдулла бине Мөслим

Мәшһүр Габдулла ахун улы. Чиләбе өязе Атҗитәр авылында 1260/1844 ел ахырында вафат булган. Бохарада укып, шәех Хөсәен бине Йосыф исемле бер заттан Тарикатьтә рөхсәт алган. Асыл ватаны булган Ахун авылына кайтканында ни өчендер авыл халкына хәтере калып, кайтып килмәс өчен ант итеп, Атҗитәргә китте һәм анда яшәде. Вафатыннан соң Габделкәрим исемле берсе аңа алмаш булды.

### 238. Мөхәммәд бине Габделҗәлил бине Мирсәлим

Атасы Габделҗәлил [югарыда] телгә алынды. Троицки өязе Муйнак авылында // [115] 1260/1844 ел ахырында вафат булган. Юлык авылында укыганнан соң бер башкорт авылында

Иманкол исемле бай иганәсе белән дәрес укытып торды, соңыннан Бохарага сәфәр итте. Бохарада укып, зирәклек белән шөһрәт казанды вә бер маҗара сәбәпле алты ай кадәр бер вакыт зинданда калды. Үз иленә кайткач, елына өч йөз сум акча алу шарты белән Бузгәй улларының мәдрәсәләренә мөдәррислек итте. Ун ханәдән гыйбарәт мәдрәсәләре вә хисапсыз шәкерте булыр иде, дип сөйлиләр. Монда исә фәкать дүрт ел дәвам итеп яшьлегендә вафат булган. Галим вә фазыйль иде,

мәдрәсәләрендә булган хәлфә вә пишкадәм шәкертләрне җыеп иман вә исламның нидән гыйбарәт икәнен гаять җиңел итеп нотык рәвешендә сөйләр; азан, кунут, җеназа догаларын; әт-тәхият, сәна [намазда укыла торган догалар] вә шулар кебек мөселманнар өчен мөһим булган әйберләрне дөресләп укытыр, мәгънәләрен дә төркичә белдерер иде, дип сөйлиләр. (Тулысынча ысуле җәдидә белән укытыр, имеш, фәкать бу көннең заһид мөдәррисләре һәм сәләф юлында булган байлары аның гасырында булмаганга күрә, арбасына тормоз салынмады!..)

Моның «вау дивана!» дип шөһрәте булган бер акыллы мәҗнүн дусты булганы сөйләнә.

**239. Галим хуҗа бине Каландар хуҗа**

Әстерхан шәһәрендә унберенче мәчеттә имам иде. Вафат елы мәгълүм булмады. 1260/1844 елда исән иде.

**240. Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуәт**

Бөгелмә өязе Бәйрәкә авылында имам булып, 60 яшьләренә ирешеп, 1261 елның 1 мөхәррәмендә (1844 ел, 29 декабрь) вафат булган.

Балалары: Габделгали, Әхмәдгали, Улкәй. Соңгы икесенең аналары Искәндәр бине Гали әл-Бәйрәкәвинең Сәйидә исемле кызы иде.

Остазлары: Искәндәр бине Гали әл-Бәйрәкәви, Мөхәммәдгали бине Мөхәммәделәмин әл-Минзәләбашый, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади һәм башкалар.

Шәкертләре: Габделхәким бине Габделхәлим әр-Раи, Зәйнелгабидин бине Исхак әл-Кирлегәчи һәм башкалар. Язып тәмамлаган «Шәрх әл-Викая» ахырында болай язган: «[гарәпчә] Остазыбыз Мөхәммәдгали бине Мөхәммәдәмин // [119] әл-Бәйрәкәви мәдрәсәсендә 1809 елда тәмам булды». Бу кемсә хакында үзенең улы Габделгали әл-Бәйрәкәви хәзрәтләре безгә болай язган иде: «Әтиебез Сәгыйдь бистәсендә тугыз елга якын торып, Габдеррахман әл-Кирмәнинең пишкадәм шәкертләреннән булды; Вәлиэддин әл-Бәгъдадидән гыйльме кыйраәттә рөхсәтнамә

алды; 1315 елда Бәйрәкә авылына кайтты; дамелла Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви күчеп киткәндә [№213] үз урынына имам булу һәм шәкертләр укыту өчен әтиебезне билгеләде. Ул заманнар тыныч булганга күрә указсыз гына имам булып, дәрес укытса да, соңрак, 1833 елда, указ алырга мәҗбүр булды. Гомере ахырында шәех Нигъмәтулла Биктимер әл-Эстәрлигә бәйгать [ант]. Фарыз-ваҗибларны үтәп, сөннәт вә мөстәхәбләрне кайгыртып, кешеләргә кирәк булган әйберләр турында ихлас калебе белән вәгазь сөйләр иде. Дөнья әһелләре белән аралашмады, күпчелек вакыт ялгызлыкта булыр иде. Фикъһны яхшы белү белән мәшһүр иде».

**241. Шаһиәхмәд бине Йосыф бине Котлыгмөхәммәд бине Тәүкил**

Оренбург өязе Рәдүт авылында 88 яшендә 1261/1845 елның 18 сәфәрендә вафат булган. Русия мәмләкәтендә мәшһүр булган Тәүкил (Тәфкилев) фамилиясеннән булып, Шаһингәрәй мирза бине Йосыф белән бертуган булса да, анасы белән Йосыф мирза арасында булган никах дворянлык вә башка рәсми кәгазьләргә язылмаганын сәбәп итеп күрсәтеп, башка варислар тарафыннан әйтелгән дәгъвага таянып, Йосыф мирза вафат булгач, мирзалыгына вә башка күчемле вә күчемсез малларына // [120] варис булудан мәхрүм калган. Һәр ни кадәр бу тарафтан никах укыган имам вә шаһидләрне дәлил итеп күрсәтеп каршы дәгъва белән чыкса да, хөкем вакытында имам вә шаһидләр Шаһиәхмәд зарарына шәһадәт бирүләреннән бер файда күрелмәде. Мирзалыктан мәхрүм булганы белән атлы казак гаскәрендә дәүләт хезмәтендә булды. Соңрак хезмәтеннән чыгып Хиҗаз тарафына сәфәр итеп, биш-алты еллар гомерен уздырган. Сәгыйдь бистәсенә барып Вәлид бине Мөхәммәделәмин түгәрәгенә кереп тәрбия алган вә мөрид тәрбияләргә рөхсәт алган. Рәдүт авылында үзе төзегән мәчете әле дә сәламәт хәленчә, имеш.

Балалары: Шаһмөхәммәд һәм башкалар. Йомшак, тәкъва, юмарт бер зат иде, дип сөйлиләр. Зиминчә авылыннан Хәбибулла бине Хансөяр бине Нугай, бу кешегә ант биреп, суфыйлар юлына баскан иде. Зират ташында «Шаһиәхмәд хаҗи бине Йосыф мирза Тәфтилев» дип язылган. Габделхак әфәнде бине әш-шәйх Һибәтулла хатыннан аңлашылды. Улы Шаһмөхәммәд Мәчкәрәдә укып, Рәдүт авылында бер

вакыт укытып, яшьлегендә вафат булган. Атасы янында күмелгән.

**242. Гатаулла бине Габденнасыйр бине Гайсә әш-Шәрифи**

40 яшендә 1261/1845 елның рабигыль-әүвәл аенда Бохарада вафат булган.

Остазлары: Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый, Салих бине Надир әл-Хөҗәнди, Хәсән бине Хәл әл-Бохарый. Гыйлем юлында тырышучы бер зат иде, дип сөйлиләр. // [121]

**243. Нигъмәтулла бине Мөнасиб әл-Бубый**

Сарапул өязе Бубый авылында имам вә мөдәррис булып, 57 яшендә 1261 елның рабигыль-әүвәл аенда (1845 ел, 26 февраль) вафат булган. Асылы Казан өязе Бәрәскә авылыннан. Хатыны – үзенең остазы булган Габделкәрим бине Хәлил кызы Газизә – 42 яшендә, 1258 елның рабигыль-әүвәл аенда вафат булган.

Балалары: Гобәйдулла, Габделгалләм, Габдулла.

Остазлары: Әбүбәкер бине Йосыф әл-Казаный, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый, Габделкәрим бине Хәлил әл-Бубый. Дәресе куәтле, үзе шәригатьтә тугрылыклы бер зат иде, диләр. Үз урынына имам вә мөдәррис булган улы Габделгалләм 1319 елның җөмадиел-ахир аенда вафат булып, тәдрис вә тәгълим ягыннан үзенә игелекле алмаш булган балалар калдырып китте. Бу гыйлем йортын Аллаһ сакласын!

**244. Рәхмәтулла бине Гобәйдулла бине Җәгъфәр әл-Кизләви**

Мәшһүр Кизләү-Курманай авылында имам вә мөдәррис булып, 1261/1845 ел рабигыль-әүвәл аенда вафат булды. Үзенә алмаш булачак һәм гыйлеменә дә варис итеп саналачак баласы калмады. Токымы өзелмәгән, бәлки, киләчәктә берәрсе күренер.

Остазлары: Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, атасы шәех // [122] Гобәйдулла бине Җәгъфәр әл-Кизләви, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади һәм башкалар. Шәкерте күп вә дәресе файдалы булганын сөйлиләр. Бу кемсә хакында

фазыйль Мәрҗани: «Заманында булган шәехләрнең берсе, кыйраәт гыйлеменең имамы иде; гыйльме кыйраәттә Габделҗәббар бине Габделкәрим әл-Әлмәтидән маһиррак вә яше кечкенә исә дә туганы шәех Нигъмәтулла әл-Әлмәтидән белемлерәк иде; мөрид тәрбиясе белән дә шөгыльләнде», – дигән.

### 245. Гыйсмәтулла бине Габдеррахман бине Туймөхәммәд әт-Тайсуганый

Бөгелмә өязе Түбән Шәлчәле авылында мөхтәсиб вә ахун булып 1261 (1845) ел 18 рабигыль-ахирдә, җомга көн вафат булды. Хатыны Шыгай авылында мәшһүр сәүдәгәр Үтәгән әл-Казан кызы Хәбибә иде.

Балалары: Хәбибулла, Сафиулла, Габделкаюм, Габделхәлим, Һидаятулла, Фәрхежәмал, Фәхрелҗамал, Бәлкыйс, Зөләйха, Сәрви. Хәбибулла, Сафиулла озын маҗаралар сәбәбеннән бу мәмләкәтне ташлап Ташкентка барырга карар кылдылар. Анда вафат булдылар. Туганнары калдымы-юкмы, белмим. Сафиулланың Ташкенттан язган бер әсәрле хатын күрсәм дә, кызганычка каршы, күчереп алмадым. Вәлиәхмәд Себергә сөрелеп вафат булды. Габделкаюм үз авылында имам иде. Фәрхежәмал – Рәмкол бине Максуд әл-Иштирәки никахында булып, минем анам тарафыннан булган әбиемдер. Фәхрелҗамал – Могыйнеддин бине Габдеррәшид әш-Шөкри никахында, Бәлкыйс – Зәйнелгабидин бине Бикчәнтәй әл-Балыклы никахында, Зөләйха – хаҗи Зәйнелгабидин бине Әбүбәкер әл-Иштирәки никахында, Сәрви – Габдеррәхим бине Салих әл-Казаный вә аның вафатыннан соң Габдеррәхим // [123] бине Гайсә әл-Имәни никахында булдылар. Остазы Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле иде. Бу кемсә Тайсуган авылында булган гыйлем йортында укып, фикъһ гыйлемендә яшьтәшләре арасында өстен булып, язуга маһир иде. Үз тирәләрендә булган шәргый дәгъваларны хәл иткән, имеш.

### 246. Ягъкуб бине Яхъя бине Җәгъфәр әт-Төбъйазый

Казан өязе Кышкар авылында имам вә мөдәррис булып, 1261/1845 елның шәгъбан аенда вафат булды. Яше илледә иде. Хатыны Шәрифә бинте Габдеррәхим бине Бикчәнтәй бине Ибраһим әл-Бәрәскәви иде.

Балалары: Сабир, Шакир, Әсма. Сабир Күшәр авылында имам булып, соңында хезмәтеннән китте, зиярәт кылу максатыннан Бохарага барып, 1310 елда вафат булды. Әсма исемле кызы – Ташкичү авылында имам Садреддин бине Баһаведдин әл-Мәрҗани никахында. Сахибе тәрҗемәнең остазы Габдеррәхим бине Бикчәнтәй әл-Бәрәскәви иде. Бохарага барып эшләде. 1245 ел ахырында үз иленә кайтып Бәрәскә авылында имам булды, Фәйз бине Габделгазиз бине Гайсә әл-Кенәри вафатыннан соң Кышкар авылына күчте, һәр ике авылда күп шәкерт җыеп дәрес укытты.

Шәкертләре: Ягъкуб бине Нигъмәтулла әл-Әлми, Фәхреддин бине Мортаза әл-Пәшләви, Рәхмәтулла бине Йосыф әт-Таравый һәм башкалар.

**247. Галибай бине Ярмөхәммәд бине Ногайбак**

Бөгелмә өязе Чалпы авылында имам вә мөдәррис булып, 48 // [129] яшендә 1261/1845 елның шәгъбан аенда вафат булды. Габделфәттах һәм Габделлатыйф исемле уллары, Кичүчат авылында Нәҗмеддин бине Фәсыйхеддин бине Сөбханкол никахында Биби исемле кызы калды.

Остазлары: Әмирхан бине Кучкар әл-Үтәки, Әхмәдҗан бине Әмирхан бине Кучкар, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый һәм башкалар. Тарикатьтә булган шәехе Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли иде.

Шәкертләре: Фәхреддин бине Сәйфеддин әл-Кичүчатый, Әхмәдҗан бине Габделҗаббар әл-Көекли һәм башкалар. Дәрес китапларын белеп вә белдереп укытырга осталыгы булса да, шәкерте аз иде. Үзеннән: «Хәзрәт! Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ кавемнәре ни җирдә һәм ни заман чыгачаклар?» – дип сорагач, «Бу турыда артык гыйлемем юк, фәкать ахырзаман билгеләренең берсе буларак барлыкка килүе хәбәр ителгән Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ кавемнәре үзебез булу ихтималын күрәм вә бу яктан куркуым бөектер!» – дип җавап биргәне мәшһүр. // [135]

**248. Җиһангир хан бине Бүкәй хан бине Нургали бине Әбелхәер хан**

42 яшендә 1261/1845 елның шәгъбан аенда Бурса исемле урында вафат булып урдага китерелеп күмелә. Казакъ ханнарының соңгысы. Атасы Бүкәй хан (Нургали

хан бине Әбелхәер тәрҗемәи хәлен карагыз) вафатында унике яшендә булганга күрә, ханлык хезмәтен атасының туганы Шөгай бине Нургали хан үтәде. 1249 (1833) елның сәфәр аенда, 22 июньдә, Җиһангир егерме яшен тутырганда, Русия тарафыннан ханлык хезмәте аңа тапшырылды. Русия дәүләтендә булган генерал-майор дәрәҗәсенә ия булды.

Хатыны Мөхәммәдҗан мөфти ибне әл-Хөсәен кызы Фатыйма иде (моның тәрҗемәсе бар, шунда мөрәҗәгать итегез). Шушы хатыныннан Сәхибгәрәй, Ибраһим, Әхмәд, Гобәйдулла исемле уллары, Зөләйха, Хәдичә исемле кызлары бар иде.

Сәхибгәрәй 1263/1847 елның 25 июнендә (рәҗәб аенда) хан исеме алып, ике елдан соң, 1265/1849 елда вафат булды. Минемчә, өйләнмәгән иде, балалары да юк.

Ибраһим 1269/1853 ел сәфәрендә, февраль аенда, ханлык исемен алып Оренбург шәһәрендә торды, яшьлегендә вафат булды. Кабере Оренбургта, балалары юк иде.

Әхмәд Петербургта Пажеский корпуста укып хезмәткә керде вә гвардейский полковник дәрәҗәсендә хезмәттән чыкты. Туган елы – 1834. 1287 (1870) елның 30 августында (рәҗәб) Русия дәүләте тарафыннан «князь Чингиз» дип дәрәҗә вә моның өчен өч ел соңрак герб бирелде. Дәүләт иганәсе белән энесе Гобәйдулла белән берлектә Хиҗазга барып хаҗ сәфәрендә дә йөреп килделәр. Әүвәлге хатыны – полковник Пәйдәсов исемле кемсәнең Зөһрә бинте Шаһингәрәй бине Йосыф әт-Тәүкили исемле хатыныннан булган кызы Хәдичә. Моның вафатыннан соң мирза Баһадиргәрәй бине Шаһингәрәй бине Йосыф әт-Тәүкили кызы Зөһрәгә өйләнде (моның анасы Гөлсембикә бинте Сөләйман – Дәүләткилди фамилиясенә карый иде). Әхмәдиең исә әүвәлге хатыныннан князь Исмәгыйль исемле улы булып, бүген гаиләсе һәм балалары бар, диләр.

Гобәйдулла дәүләт хезмәтендә булып генерал дәрәҗәсенә иреште, бүген исә Петербургта сәламәт вә хезмәтеннән чыккан. Балалары юк, диләр.

// [137] Хәдичә Сәедгәрәй мирза бине Шаһингәрәй бине Йосыф әт-Тәүкили никахында вафат булды. Өммегөлсем, Мәдинә исемле кызлары бар һәм һәр икесенең балалары күп.

Зөләйха казакъ түрәләреннән Сәедсолтан бине Җантуар исемле майорда кияүдә

булып вафат булды. Аның Сәлимгәрәй исемле улы бүген сәламәт, гаиләсе, балалары бар.

Моннан аңлашылганча, Җиһангир хан хәзрәтләренең нәселе Әхмәд исемле улы белән Хәдичә һәм Зөләйха исемле кызларыннан таралган.

Хан үз идарәсендә булган мөселманнар арасына указлы имамнар билгеләгән, имам дәрәҗәсе белән берлектә аларга күп хезмәтләр дә йөкләгән. // [139]

Петербург шәһәренә чакырылып барганында хан үзенең остазы булган Хаҗитарханлы Гаедмөхәммәд бине Ишмөхәммәд бине Мостафа бине Кышлаумөхәммәд исемле кемсәне үзе белән альт барган, аның ишарәсенә туры китереп, остазына дәүләт тарафыннан алтын медаль бирелгән, диләр.

Моның турында фазыйль Мәрҗани: «Диндар, галимнәрне яратучы, яхшы күңелле, юмарт бер зат иде», – дигән. Үз балалары һәм оныклары белән якыннан таныш булмаганыма күрә, тәрҗемәи хәлен читләрдән ишетеп вә бер кадәр җирләрдән тикшереп бу җирдә яздым. Кайбер хата вә ялгышлыклар булса, белгәннәр тезәтерләр. // [140]

**249. Шәрәфеддин бине Зәйнеддин бине Ибраһим бине Җаукай бине Уйбакты бине Мәнгеш бине Собай бине Җомай бине Нугай**

Эстәрлетамак шәһәрендә имам вә мөдәррис булып, 77 яшендә 1262 (1846) елның шәгъбан аенда вафат булды. Асыллары Кирмәннән булып, атасы Зәйнеддин бине Ибраһим Бәләбәй өязендәге Муллагөлем исемле авылда дөнья кичереп вафат булды.

Хатыны Хәмидә бинте Биктимер әл-Эстәрли булып, шәех Нигъмәтулла әл-Эстәрли белән бертуган иде.

Балалары: Кәмаледдин, Хәнифә, Гобәйдә, Гафифә. Хәнифә Сәгыйдь бистәсендә мәшһүр сәүдәгәр Гобәйдулла бине Хәбибулла никахында, Гобәйдә Габдессәлам мөфти улы Әхмәди никахында, Гафифә Рәми фамилиясеннән Бәхетгәрәй бине Габделкәрим никахында иде. Кәмаледдин тәрҗемәсе алда булыр.

Остазлары: Фазыл бине Сәйфулла әл-Кизләви, Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни һәм башкалар.

Шәкертләре: Хисамеддин бине Габделкәрим әт-Таупазый, Габделхәким бине Корбангали әл-Чардаклый, Габделҗәббар бине Ибраһим әл-Әхмәди, Мөхәммәд бине Салих әл-Гомәри һәм башкалар. Бохарага барып Ниязколый әт-Төрекмәнигә иярде, Тарикатьтә рөхсәт алып үз иленә кайтканнан соң мөридләр тәрбияләде; Габделхәким бине Корбангали әл-Чардаклый исемле укучысы аның урынбасары булды. // [143]

**250. Фәхреддин бине Габдеррахман бине Морадым бине Җиһанмөхәммәд бине Акмөхәммәд бине Ярмөхәммәд бине Назар бине Юныс**

Казан өязе Бәхтияр авылында имам булып, 74 яшендә 1262/1846 елның рамазан аенда вафат булды. Анасы Шәрифә бинте Мөэмин бине Мөхсин бине Сәфәр бине Юныс булып, атасы белән анасы мәшһүр Юныс әфәндедә берләшә (Юныс әфәнденең тәрҗемәсе югарыда язылды).

Остазлары: Мөхәммәдрәхим бине Юныс әл-Ашытый вә Габид бине Габделгазиз әл-Кенәри. Күп мәсьәләдә Морад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри белән низаг, бәхәсләре булганын сөйлиләр.

**251. Габдеррәхим бине Бикчәнтәй бине Ибраһим**

Казан өязе Бәрәскә авылында имам булып, 1262/1846 елда вафат булды. Күп еллар дәрес укытты, дөньясы иркен булып каллиграфик остаханәләр тотты. Остазы үзенең атасы иде.

Шәкертләре: Габделгафур бине Габделбакый әл-Исәки, Баһаветдин бине Сөбхан әл-Мәрҗани, Ягъкуб бине Яхъя әт-Төбъйазый әл-Кышкарый һәм башкалар.

**252. Таҗеддин бине Мостафа бине Рамазан бине Ишнияз әл-Әшнәки**

62 яшендә, 1262/1846 // [143] елда хаҗ сәфәреннән кайтып килгәндә, Янбәгъ [Янбо] тирәсендә Кызыл диңгездә батып вафат була. Казанда Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри мәдрәсәсендә торып вә Адай авылында Таһир бине Сөбханнан кыйраәт гыйлемен укып Чиканас исемле авылда имам булган иде. Соңыннан 1250 елда дәүләт тарафыннан Тифлис шәһәрендә булган Идарәи исламиягә мөфти итеп

билгеләнде. Бу хезмәтендә исә бер ара калганнан соң ни сәбәпледер эшеннән чыгарылды. Мөфти булган вакытында югары дәрәҗәдә иде, дөньясы тәрәккый итеп, замандашлары арасында хөрмәте дә зур иде. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Хисап, фикъһ, кәлям, мантыйк гыйлемнәренә игътибар итә иде, боларның һәрберсе хакында күпсанлы рисаләләр язган булса да, рисаләләре фәкать иярү юлы белән язылган, көчсезлеген күрсәтәләр...» – дип яза.

**253. Фәезбәхеш бине Габделкоддус әл-Гомәри әс-Сирһинди.**

Казан шәһәрендә 1262/1846 елның шәүвәл аенда вафат булды. Асылы Һиндстан вилаятеннән булып, шәех Әхмәд әс-Сирһинди нәселеннән иде. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Үз сүзләренә күрә, Сахибзадә ишан буларак билгеле иде, гыйлем әһеленнән булмыйча, шөһрәте фәкать нәсел-нәсәбе белән иде», – дигән.

**254. Зөлкарнәйн бине Хәлил әл-Кактамакый**

Себернең билгеле шәехләреннән берсе. 72 яшендә // [145] 1262/1846 елның зөлкагдә аенда вафат була.

**255. Ногман бине Әмир бине Госман әс-Сәмәни**

Уфа өязе Сәмән исемле авылдан. Вафат булган елы мәгълүм түгел. Анасы Назым, аның анасы Бибисолтан иде. Бибисолтан исә мәшһүр Мортаза Хаҗи (тәрҗемәсе язылды) белән бертуган, имеш. Сахибе тәрҗемә Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавый хозурында белем алып, камиллеккә ирешеп, якын тарафдарлары төркеменә кергән. Остазы хаҗ сәфәренә киткәндә бөтен мәдрәсәсен идарә итеп торган. Габелхаликъ ишан бине Ибраһим кызына өйләнгән. Кайбер гарәп телендәге әсәрләре булган кебек, Һәфтияк шәрифнең төркичә бер тәфсире булганын сөйлиләр.

Гадәттән тыш фазыйль һәм камил булган хәлдә, тәрҗемәи хәле лаек дәрәҗәдә язылмаганга күрә, надан халык арасында югалды; исеме-фәләне дә үзе хаклы вә лаеклы булган дәрәҗәсе белән калмады, дип кайгыручылар бар.

Остазы Курсавыйның «Әл-иршад ли-л-гыйбад» исемле әсәре хакында язылган мактау рисаләсе бар.

**256. Габделҗәббар бине Габдеррахман бине Туймөхәммәд**

Бөгелмә өязе Тайсуган авылында имам вә мөдәррис булып, 96 яшендә 1262/1846 ел ахырында вафат булды. (Атасы Габдеррахман бине Туймөхәммәд телгә алынды).

Балалары: Мөхәммәдзариф, Мөхәммәдлатыйф, Баһаведдин, Мөхәммәдшәриф, Мөэминҗан, Шәмгыҗиһан, Гаишә, Сәгъданә. // [152]

Мөхәммәдзариф, әтисе хозурында вә Әлкәй авылында Хисамеддин бине Мөэмин мәдрәсәсендә укып, Тайсуган авылында указлы мулла булды; 53 яшендә 1263/1847 елның рабигыль-әүвәл аенда вафат булды. Балалары һәм оныклары күп. Әхмәд исемле берсе фәһемле, зирәк вә кятиб иде, бу көннәрдә вафат булганын ишеттем. Мөхәммәдзариф вафатыннан соң бу авылга Габденнасыйр бине Габдеррәхим исемле мөдәррис күчеп килеп, рәсми рәвештә имам, хатыйб вә мөдәррис булды.

Баһаведдин Бәләбәй өязендә Кыругъ Йатмаз исемле авылда имам булды, инде вафат. Мөхәммәдшафигъ, Мөхәммәдҗан, Әхмәдҗан исемле балалары бар иде. Мөхәммәдҗан исемле улы Туйнаш авылында имам булып, күп еллар сәламәтлеге юк хәлдә дөнья кичерә.

Гайшә Әлкәйдә Хисамеддин бине Мөэмин никахында иде. Фәттахеддин, Садреддин, Хәйдәр, Зәкүан исемле уллары һәм берничә кызлары бар иде. Кызларының берсе – Азалакта ахун Җәгъфәр әс-Садыйк бине Миңлебай, ә икенчесе Тайсуганда Габделмәннан бине Фазлулла бине Габделмәннан бине Габдерахманда кияүдә иде.

Сәгъдәнә Богырослан өязе Мөэмин авылында Корбангали бине Мөэмин никахында вафат булды. Гаделгәрәй исемле улы голямадан булып, бу көндә сәламәт, балалары һәм оныклары бар.

Габделҗәббар хәзрәтнең остазлары Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле һәм башкалар булып, тарикатьтә булган шәехе – Сәгыйдь бистәсендә Вәлид бине

Мөхәммәдәләмин әс-Сәгыйди. Габдессәлам хәзрәтнең иң соң вафат булган шәкерте, ихтимал, шушы сахибе тәрҗемә [Габделҗәббар хәзрәт] булыр. Үзе зиһенле, зирәк, // [153] фазыйль, вәкарьле, мәгълүматлы, ислам гыйлемнәреннән дә, дөньяви фәннәрдән дә хәбәрдар бер зат иде, диләр.

**257. Габделгаффар бине Габделхәмид бине Үтәгән**

Казан өязе Иске Тазлар авылында имам булып, 1263/1847 елның мөхәррәм аенда вафат булды.

Остазлары: Вәлиэддин әл-Бәгъдади, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Гата бине Йосыф әл-Бохарый, Гыяз бине Заһир әл-Хукандый, Шир бине Габдулла әл-Хукандый, Салих бине Надир әл-Хөҗәнди һәм башкалар. Шәехе Габделкадыйр бине Әхмәд әс-Сирһинди иде. // [163]

Шәкертләре: улы Фәйзеррахман, Фәтхулла бине Бикчәнтәй әл-Куяный, Нигъмәтулла бине Габдеррәшид әт-Талкышый, Мөхәммәдгалим бине Сабит бине Габделхәмид әт-Түнтәри һәм башкалар.

Бохарада укып, үз мәмләкәтенә кайткач, гомерен дәрес вә тикшеренүләр белән уздырды, кыйраәте сыйфатлы вә ягымлы, башкаруы гүзәл, тавышы мөлаем иде, диләр. Атасы Габделхәмиднең тәрҗемәи хәле телгә алынды.

**258. Гыйсамеддин бине Ибраһим бине Хуҗаш әл-Казаный**

Казан шәһәрендә 64 яшендә 1263/1847 елның рабигыль-әүвәл аенда вафат булды. Балалары юк, нәселе өзелгән. Атасы Ибраһим әфәнде картайгач әфәнде хәзрәтләренә урынбасар булып, имамлык хезмәтләрен үтәп, мәдрәсәсендә дәрес бирү белән шөгыльләнсә дә, беренчедән, тормышы гүзәл булмаганга күрә, икенчедән, сәламәтсезлеге аркасында, әфәнде урынына чит кемсәләр сайландылар. Бер хаты «Мөстафадел-әхбар»дә китерелгән (2 нче кисәк, 35-36 б.)

**259. Нияз бине Хәйдәр бине Ярымсәед бине Хәйдәр бине Гали**

Себердә Тара шәһәрендә яшәп, 75 яшендә 1263 (1847) елның җөмадиел-әүвәл

аенда (22 апрельдә) вафат булып, Сәбаләк исемле авыл каберлегендә күмелгән. // [164]

Балалары: Габделфәттах, Рәхмәтулла, Насреддин, Нәҗмеддин һәм башкалар. Бу кемсә имамлык хезмәтендә булмаса да, чыннан да галим вә фазыйль бер зат булып, милләтен сөяр, мәчет-мәдрәсәләргә тиешле иганә, ярдәмен күрсәтер, укырга теләгән, сәләтле булган шәкертләргә үз кесәсеннән ярдәм итәр, уң кулы биргәнен хәтта сул кулы белмәс; мәҗлесләрдә һәркемнең сүзен тыңлар, бөтен мәҗлес әһелләренең барысыннан ничә мәртәбә гыйлемле булган хәлдә, һичнәрсә белмәүче кемсә кебек белмәмешкә салышып утырыр; форсат табылган вакытларда Коръән шәрифне матур итеп күчерер, хакыкый галимнәргә чын мәхәббәт итәр, зиһене тугры, акыллы, үзе вәкарьле, эшне уйлап эшләүче, аралашуда хуш бер зат иде, диләр. Үзе бөек сәүдәгәр булып, фабрика тоткан, Себернең мәшһүр мәркәзләрендә сәүдәханәсе тәртипкә салынган рәвештә эшли иде. 1236 елда Сабанчы бине Ярмөхәммәд, Мөхәммәд бине Салих бине Шәех исемле юлдашлары белән бергә Хиҗазга барып хаҗ кылдылар; Мәккәдә хәнәфиләр мөфтие булган Габдулла бине Габеррәхман әс-Сираҗ әфәнде белән очраштылар (бу мөфти 1264 елда Мәккәдә вафат булды). Бу сәфәрендә Каһирәдә туктап, фазыйль голяма белән аралашып, мәшһүр галимнәр хозурында кыйраәтен төзәтеп, яхшыртып, иҗазәт алды. Себергә бөек гыйльми камиллекне бүләк итеп алып кайтты. Шуның өчен Себер мөселманнары бу затны үзләренең бабалары санап горурланалар, олысы-кечесе, ирләре-хатыннары исемен кадерләп, хәер-дога белән искә алалар.

Искәрмә: әгәр дә Нияз хаҗи хакыйкатьтә шушында язылган сыйфатта бер кеше булса, фәкать Себердә булган мөселманнар кардәшләребезнең генә бабалары булмыйча, бәлки барыбызның, бөтен милләтебезнең бабасы булачак. Мондый затларны Аллаһ хисап вә җәза көннәрендә мәрхәмәте күләгәсендә рәхәт-рәхәт // [165] тотсын!.. Моның кебек мөхтәрәм бәндәләр, бөтен халкыбыз өчен бетмәс-төкәнмәс горурлык, боларга бөтен дөньябыз фида вә газиз җаннарыбыз корбан булсын!.. Дөньяда хаҗилар, байлар, муллалар, мөдәррисләр, язучылар, укучы-укытучылар хисапсыздыр, әмма чынлыкта милләт бабалары булган затлар – шушының рәвешендә булганнары. Хәтеремдә ки, муллалар җыелышы булган бер мәҗлестә өстәл башында

ак сакаллы, бәһале киемле бер зат утыра иде. Хиҗаз тарафыннан яңа гына кайткан булган. Дөячеләрнең намаз укымауларын, бар нәрсә өчен түләү, өлеш сорауларын, садака сораучы фәкыйрьләрне, үзләренең ниләр ашап-эчеп йөрүләрен, төрекләрнең тәмәке тартуларын, Истанбул урамында булган этләрне сөйләп, ни мөнәсәбәт белән, белмим, укыту мәсьәләсенә күчеп: «Бүген яңа форма белән укыту тиешле дип сөйләгән затлар күренә, сүзләренең атасы вә анасы юк!.. Пәйгамбәребездән мирас булып бүгенгә кадәр килеп җиткән форманы үзгәртмәк булалар, АЙ АХМАКЛАР, АЙ АХМАКЛАР!..» [төп нөсхәдә шулай. – *Төз.*] – димәсенме. Бер яктан, бу кемсәнең гарәп сүзләрен гаять бозып вә җимереп сөйләвеннән, икенче яктан, һичбер кемнән тартылмыйча, мактану һәм кыюлык белән сөйләгәннәреннән гаҗәпләнеп, хәйран булып тордым. Ни булса да, бер сулыш алганын форсат санап, үзенә туры карап: «Гали зат кайда белем алырга өнди соң? Мәрхәмәт итеп бәян кылса, шат вә рәхмәтле булырбыз», – дидем. Мәгәр дә хаҗи әфәнденең колаклары бик тә ишетмәс, дөресрәге дә, саңгырау, имеш. Янымда булган кеше: «Бу бит фәлән кемсә, миллионер, гаять акыллы бер адәм!» – диде. Мин дә: «Үзе // [166] мондый җаһил булган хәлдә, бердән, тәрбия мәсьәләсенә керешүе вә икенчедән, дин вә тарих исеменнән сүз сөйләве акыллы кемсә һөнәреме булыр?!.» – дип уйладым да дәшми калдым. Мәгәр дә ысуле җәдидә тарафдары булып китсә, мәхәлләдә булган мәктәпләрне идарә иттерү вә кирәк урыннарга мал сарыф итү, фәкыйрь шәкертләргә китап вә кәгазь бирү ошбу миллионер хаҗи әфәндегә йөкләнәчәк бит. Һәм дә гаять дәрәҗәдә мал җыярга комсыз булганнынан, өлеш чыгаруны җан чыгару бәрабәренә күргәне сәбәпле, ысуле җәдидә шәригатькә каршы дигән яңа уйлап табылган мәсләккә кергән һәм бу җәһәттән барлык куркулардан котылган кебек булып утыра иде. Хәтта мәхәлләсенә бер мәдрәсә бина кылу кирәк булганнан миллионер хаҗиның парәсе кузгалмады, һәрвакыт «ахмаклар»га ярдәм итә торган, Урал тауларында алтын казучы мөселман байлары кирпечтән мәдрәсә бина салганнар, имеш. Менә шундый миллионер карт хаҗилар хәлләрен күргән, белгән вакытыбызда, Нияз хаҗиларны исебезгә төшерәбез вә рухларының тынычлыгы өчен догалар кылабыз. Никадәр аз булсалар да, һәр җирдә вә һәр заманда Нияз хаҗиларыбыз, күп шөкерләр булсын, бардыр. Боларның тәрҗемәи хәлләре бу китабыбыз өчен гүзәл зиннәт булачак. «Асар»ебезгә «Өстәмә»

яки «Кушымта» язачак яңа буын галимнәренә Нияз хаҗи кебек милләт бабалары турында бер дә калдырмыйча язуларын һәм дә исемнәрен хөрмәт белән телгә алуларын күңелем белән өмет итәм. Иншалла, бу өметебез тулысынча тормышка ашар. Искәрмәбез шушы урында тәмам булды.

// [175]

## 260. Фазлыссаттар бине Габделҗәлил бине Мирсәлим

Атасы белән бергә, аның вафатыннан соң да берничә ел дәрес биреп, 63 яшендә 1263 (1848) елның зөлкагдә аенда вафат булды. Кабере Ахун авылында.

## 261. Хәммад бине Гайсә бине Габдүки бине Иштуган бине Иштирәк бине Ишали бине Бурбай

Сәгыйдь бистәсендә 43 яшендә 1264 (1848) елның шәгъбан аенда вафат булды.

Балалары: Габделгалим, Габделгаллә м һәм башкалар. Остазы Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый иде. Орск өязе Юлык авылында ун еллар // [176] чамасы укытканнан соң Сәгыйдь бистәсенең өченче мәчетенә имам булып күчте, шунда ваба авыруыннан вафат булды. Сәгыйдьтә торуы озын вакыт булмады. Туган җире Түбән Чебенле авылында булып, атасыннан ярты яшьлек вакытында ятим калган. Атасының бертуганы булган Морадым бине Гайсә исемле кемсә тәрбия итеп укытты, диләр. Дәресе куәтле, тикшеренүләре тугры, дәрес китапларын һәм белеп, һәм белдереп укытыр; шул сәбәпле шәкерте күп һәм дә күңелләре ачык вә заманасына күрә мәгълүматлы булырлар, имеш. Габделгалим исемле улы да Сәгыйдь бистәсендә бишенче мәчеткә унынчы имам булып билгеләнде. Әхмәд бине Гали әл-Хөсәени белән бәрабәр 1296 елда хаҗ кылды һәм 1315 (1897) елның рабигыль-ахир аенда Сәгыйдьтә вафат булды. Бу кемсә дә Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый шәкертләреннән булып, гомере буенча дәрес белән мәшгуль булды. 1313 (1896) елда шул Сәгыйдь бистәсенә барганымда җәнабларын күрдем, алар белән аралаштым, фәкать колагы ишетмәү сәбәпле, күңелемдә әзерләнгән нәрсәләр хакында сорап, файдалана алмадым. Шуның өчен хат белән кайбер мөһим мәсьәләләрне тулырак

аңлатуны сорадым. Һәрвакыт хат язар, күпчелегендә яшь имамнарның игътибарсызлыкларыннан зарланыр, моннан башка күп нәрсәләр турында кайгырыр иде. Аллаһы Тәгалә хәзрәте рәхмәт әйләсен!..

**262. Нигъмәтулла бине Габдеррәхим**

Оренбург шәһәрендә имам вә ахун булып, 54 яшендә 1264/1848 елның шәгъбан аенда ваба авыруыннан вафат булды. Асылы Пенза ягыннан булып, // [177] шәех Дәүләтшаһ бине Гаделшаһ хәзрәтләренең шәкерте вә мөриде вә Гаишә исемле кызының кияве иде. Әхмәд исемле улы калды.

**263. Сәед бине Нурмөхәммәд**

Орск өязендә Муллакай авылында имам вә мөдәррис булып, 48 яшендә 1264/1848 елда вафат булды. Габдулла исемле улы калды. Гыйлем вә суфыйчылыкта остазы вә шәехе Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли иде. Тәкъва, динле бер зат булып бөтен гомерен дәрес укытып кичерде, диләр.

**264. Мөхәммәдвафа бине Фазыл бине Сәйфулла**

Казан шәһәрендә имам вә ахун булып, 1264/1848 елда вафат булды. Үз мәмләкәте галимнәреннән белем алганнан соң Бохарага барды вә, үз иленә кайткач, Казанның алтынчы мәчетенә Әмирхан бине Габделмәннан белән бергә имам булып билгеләнде. 1256 елда имамнар тарафыннан сайланып Җәмгыяте шәргыягә әгъза итеп билгеләнде. Соңрак урыныннан чыгарылса да, Шәрәфеддин бине Зәйнеддин вә Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли исемле шәехләр тырышлыгы белән әүвәлге урынына кабат кайтарылды. Вафатыннан соң Әхмәдсафа исемле улы вә Гаишә исемле хатыны калды. Шул тол хатыны исә Зыябаш авылында мәшһүр сәүдәгәр Хөррәмшаһ бине Габдулла бине Акчурага никахланган иде. // [179]

**265. Габделлатыйф бине Сөбханкол бине Рәмкол**

Бәләбәй өязе Корыч авылында имам булып 80 яшен кичеп 1264/1848 ел ахырында вафат булды. Мөхәммәдсадыйк вә башка исемдә балалары калды.

Остазлары: Әмирхан бине Кучкар әл-Үтәки, Ишмөхәммәд бине Заһид әл-Көбәки һәм башкалар. Бәләбәй өязе Кыска елга авылында дөньяга килеп, гыйлем алу максаты белән Адай авылындагы Әмирхан хәзрәт мәдрәсәсенә барган. Соңрак хаҗ кылу нияте белән сәфәргә чыгып, Каһирәдә беркадәр еллар калган, анда кыйраәт гыйлемен үзләштереп, хаҗ кылганнан соң Бохарага барган. Бохарада шәех Ниязколый әт-Төрекмәнидә тәрбияләнеп, иҗазәт алган. Безнең җирләрдә бу кемсәнең шөһрәте шәехлеге вә кыйраәткә осталыгы белән бәйле. Тавышы һәм башкаруы шул дәрәҗәдә гүзәл булган, имеш, нинди генә хәсрәтләргә дучар булган кешеләр дә аның укыганын ишетсәләр, күңелләренә шатлык вә рәхәт килер, имеш. Ир вә хатыннарны аермыйча барысын кабул итеп, тәрбиясенә алыр иде, диләр. Мәшһүр кешеләрдән Гайнелкамал бине Габделвахид әл-Карани, Насреддин бине Габделхәким әл-Борайи аның якыннары. Сөләйман бине әл-Калмашый һәм Фәттахеддин бине Габделмәҗид әс-Сарсазый аннан рөхсәт алганнар.

// [180]

**266. Габденнасыйр бине әл-Мөхәммәд**

Тау ягында Барыш авылында имам, 1264/1848 елда вафат булды. Шул авыл имамлыгыннан Җәмгыяте шәргыягә әгъза булып Уфа шәһәренә китте һәм аннан Казан шәһәрендә Барудия мәхәлләсенә имам булып кайтты. Моннан тагын икенче мәртәбә Җәмгыять әгъзалыгына китте һәм аннан үзенең асыл авылы булган Барышка кайтты вә шунда вафат булды. Алты-җиде хаты күз уңыбызда булса да, язулары гүзәл түгел, эчтәлекләре дә гыйбрәт алырлык түгел, шуңа күрә бу җирдә китерелмәделәр.

**267. Нигъмәтулла хуҗа бине Зөннун хуҗа**

Хаҗитархан шәһәрендә имам булып 52 яшендә 1264/1848 елның шәүвәл аенда вафат булды. Габдеррәхим исемле улы калды. Хаҗитарханда Бабай ахун дип билгеле

һәм бу елларда вафат булган зат Габдеррәхим әфәнде үзе булса кирәк.

Сахибе тәрҗемәнең имам Гобәйдулла бине Сәпкол вә имам Әбүшәхмә бине Муса белән берлектә төзегән бер хөкемнамәсен күрдек, гыйлем вә фазыл иясе бер зат булганын аңладык. // [184]

# УНБЕРЕНЧЕ КИСӘК

# اونبرنچی جزء

**268. Вәлишаһ бине Мәхмүд бине Госман бине Биктимер**

Зөя өязе Берле Баш авылында имам булып, 1227 (1812) ел ахырында вафат булды. Янайдар исемле морзалар фамилиясенә мөнәсәбәте барлыгы риваять кылына. Оренбург Җәмгыяте исламиясендә әгъза булып хезмәт итте. Сәгъдеддин исемле улы 59 яшендә 1285 (1868) елның рәҗәб (октябрь) аенда вафат булды. Бу кемсә хакында ахун Мөхәммәд Әкмәледдин бине Габделкадыйр әл-Борындыкый: «Вәлишаһ казыйның вафат елы ачык сурәттә мәгълүм булмаса да, вафат булган вакытында улы Сәгъдеддин бер яшь ярымда калган иде, Сәгъдеддин тарафыннан бүген нәселе күп һәм күпчелеге игенчелек белән мәшгуль», – ди.

**269. Сәйфулла бине Фәйзулла бине Габделгазиз бине Габдеррахман**

Тәтеш өязе Исәк авылында имам булып, 1242 (1826) елда вафат булды.

Балалары: Фәхреддин, Габделвахид, Бикчәнтәй. Фәхреддин 1238 (1823) елның 5 зөлкагдәсендә (2 июль) дөньяга килеп, 1308 (1891) елның 5 нче җөмадиел-ахирендә (4 гыйнвар) // [185] вафат булды. Биги авылында Таҗеддин исемле кемсә мәдрәсәсендә укып, бөтен гомерен балалар укыту белән кичерде һәм төрле авылларда булган мәктәпләрдә мөгаллим булып торды. Садреддин исемле улы бүген Исәк авылында сау-сәламәт. Бикчәнтәй белән Габделвахид гади халыктан булып, беренчесе – Урал тарафында Мөлек авылында, икенчесе Исәк авылында вафат булдылар.

Әлеге зат Оренбург Җәмгыяте шәргыясендә әгъза булып бер ара вакыт хезмәт итте. 1806, 1809, 1810, 1811, 1812, 1819 елларда имза кылган кәгазьләрен без күрдек. // [187]

**270. Мөхәммәделәмин бине Нәүрүзгали бине Габделкәрим бине Үтәгән бине Корбангали**

Зөя өязе Түбән Урысбага авылында имам булып, 1260 (1844) елның 1 мөхәррәмендә (10 гыйнвар) 80 яшендә вафат булды. Мөхәммәдкәрим, Мөхәммәдсадыйк исемле уллары, Биби, Мәймүнә, Хәдичә исемле кызлары бар иде.

Мөхәммәдкәрим шул авылда имам булып вафат итте, аның улы Мөхәммәдшаһ бүген шунда имам. Хәдичә исемле кызы Әбүбәкер исемле бер затка никахланып, Шәрәфеддин исемле улы дөньяга килде. Бу кемсә дә шул авылда бүген имам.

Сахибе тәрҗемә, Габдүш бине Габдессәлам әл-Кавалыйда укыганнан соң, Урысбага авылына имамлык өчен 1227 (1812) елның 3 июнь көнендә рәсми рәвештә указ алды. Соңрак Оренбург Җәмгыяте шәргыягә әгъза булып барып, бер ара вакыт торды. 1813, // [188] 1814, 1815 елларда Җәмгыяте шәргыядә хезмәт иткәне мәгълүм. 1815 елда төзелгән тәрҗемәи хәл кәгазенә күрә, шул елда 34 яшендә булган. Иптәшләре булган казыйларның берсе – Лаеш өязе Балыклы авылының имамы Нигъмәтулла бине Габдессәлам 25 яшендә, икенчесе – Спас өязенең бер авылы имамы Габденнасыйр бине Гаед 34 яшендә иде. Атап үтелгән еллардан башкасында имза иткән кәгазе күрелмәгәннән, ялгыз бер нәүбәт хезмәт иткәне аңлашылыр. Риваятьләргә күрә, 1830 яки 1831 елда бер вакыйга сәбәпле урыныннан чыгарылды.

### 271. Габдеррәхим бине Гашур

Хаҗитархан шәһәрендә тугызынчы җамигъ мәчетендә имам вә мөдәррис булып, 1264 (1847) елда вафат булды. Шабаталы [Чабаталы] мулла дип билгеле булган кемсә. Асылы Пенза өязе Мачали исемле авылдан иде. Сәгыйдь бистәсендә Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни хозурында укыды, соңрак Каһирәгә барды, анда унике ел калып, гыйлем кәсеп итте. Мостафа әфәнде әл-Мисрый исемле Коръән укучы хозурында белем туплап, кыйраәт гыйлеменнән рөхсәт алды. Туган җиренә кайткач, Хаҗитарханда имам вә мөдәррис булып, гыйлем белән шөгыльләнде, аның хозурында күп затлар Коръән вә тәҗвидне өйрәнделәр. Габделваһһаб бине Гали әл-Хаҗитарханый моның мәдрәсәсендә укыды, диләр. Язуы дөрес, гүзәлдер, кайбер язуларын күргән идем.

//[289]

**272. Габдессалих бине Габдул бине Шәриф бине Көек бине Күчкән бине Борак бине Исәнхан бине Дәүләтбай би бине Дәүләтйазый бине Ходаяр би бине Ходайколый би бине Дүрман би бине Колман би бине Чулман би бине Ибдал би бине Әхмәдшәех би бине Каратабын би бине Болгаер би бине Иләк би бине Майкый би**

Риваятьләргә күрә, шушы Майкый би Чыңгызхан әмирләреннән булып, һиҗри җиденче гасыр адәмнәреннәндер. Чыңгыз исә бөтен мәмләкәтен дүрт өлешкә бүлеп, дүрт улына биргәндә, Майкый би дә Җүчи хан өлеше булган җирдә калган. Җүчи хан вафат булганнан соң, Чыңгыз хөкеме белән Бату хан өлешенә бирелгән.

Майкый бинең Юлдаш, Аккош, Кормаш, Иләк исемле уллары булып, Иләк бинең Акйар би, Такйар би, Будәнә би, Ябынчы би, Алчак би исемле уллары булган. Болгаер улы Каратабын би Кара Газиз мулла дип мәшһүр булган, имеш. Кара Газизнең Балыкчы би, Рәсүл, Таймас, Әхмәдшәех исемле уллары булган. Әхмәдшәех Ирәктә дип билгеле булып, Минзәлә өязе Мәллә суы буенда бүген дә Ирәктә волосте булган җирләр бер заманнар гүя ошбу Әхмәдшәех милкендә булган вә исеме дә бүгенгә кадәр калган. Ирәктә бинең Ибдал би, Яхшы би исемле уллары булган, вә Чулман би дә, атасы Чулман елгасына күчеп килгәннән соң дөньяга килеп, шул мөнәсәбәт белән Чулман дип аталган. Күчкәннең асыл исеме Госман булып, Күчкән исә соңыннан бирелгән кушамат, имеш. Ошбу затларның ни вакыт исламга кергәннәре безгә мәгълүм булмады.

// [190]

Сахибе тәрҗемә Габдессалих Бөре өязе Чокыр авылында яшәп, 1265 елның рамазан аенда вафат булды. Укыган остазы Габденнасыйр бине Торымтай иде. Рәхмәтулла бине Габдүш исемле шәехнең суфичылыкта ярaны [мөриде] булды. Галимнәр төркеменә караганнарның күпчелегеннән аермалы буларак, үз кул кәсебе белән ризыкланып көн кичерде, шулай байлык белән гомер итте, диләр. Башкортлар гадәте буенча урманда агач башларына умарталар куеп чолыклар ясап хәрәкәтләнер, җомга көннәрдән башка вакытларын умарталарны күзәтеп урманда кичерер, имеш. Тәкъва бер зат булганнан, умарта кәсебендә йөргәненнән башка бөтен буш сәгатьләрен намаз укып, зикер белән мәшгуль булган, имеш. Үз акчасына мәдрәсә

салып, шәкерт җыеп, аларга дәрес укытыр өчен Табын авылында укыган Мәһрехәйдәр бине Рәхмәтулла бине Габдүш исемле шәкертне // [191] чакырган, үзенең Мөэминә исемле кызын аңа кияүгә биргән. Фәкать бу кемсә, аз вакыттан соң хасталыкка дучар булып, яшьлегендә вафат булды. Шул кызыннан башка Мөхәммәдфазыл, Мөхәммәдгали исемле уллары да бар иде. Соңгысының тәрҗемәсе алда китерелер.

**273. Габделҗәббар бине Габделкәрим бине Габделмәннан**

Чистай өязе Иске Әлмәт авылында 60 яшендә 1265 (1849) елның рамазан аеның ахыргы көнендә вафат булды. Кабере шул авылда. Җәмалия, Камәрия, Мөхәммәдгата, Габдеррахман исемле балалары калды. Җәмалия, Хәбибулла бине Әхмәд әл-Ләбитигә никахланып, бер елдан соң аерылды; Камәрия Үргәгарда Фәхреддин исемле бер кешегә никахланып, Шәһид исемле улы дөньяга килде. Шушы Шәһид бине Фәхреддин, Чистай шәһәрендә имам булып, яшьлегендә вафат булды.

Остазлары: Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади, Вәлид бине Мөхәммәделәмин әс-Сәгыйди һәм башкалар. Үзеннән Гыйззетулла бине Габделвахид әл-Кирмәни вә башкалар, һәм дә исемнәре аталган кызлары кыйраәт гыйлемен үзләштерделәр, дип риваять кылына.

Юмарт, кунакчыл бер зат иде, диләр.

**274. Байморад бине Мөхәррәм бине Мөэмин бине Мөслим бине Бутай бине Ишкенә бине Ишбулад бине Шаһбулад бине Бохарбулад бине Җангазый**

Казан шәһәрендә алтынчы җамигъта // [192] имам вә мөдәррис булып 63 яшендә 1265 (1849) елның шәүвәл аенда (август) вафат булды. Җәмилә исемле кызы Казанда Габделвәли бине Йосыф бине Мөхәммәд никахында булып, моннан башка тагын бер кызы бар иде. Мөхәммәденнәҗип исемендә фазыйль улының тәрҗемәи хәле язылачак. Абыйсы Мохтар бине Мөхәррәм мәшһүр сәүдәгәр, аңлы, алдан күреп эш итүче затлардан булып, 70 яшеннән кичеп, 1292 (1875) елның 20 сәфәрендә Мәңгәр авылында вафат булды.

Остазлары: Габид бине Габделгазиз әл-Кенәри, Габбас бине Габдеррашид әл-Күшәри, Исхак бине Сәгыйд әл-Казаный, Бохарада Гайсә бине Рәхмәтулла, Гаяз бине Заһир, Салих бине Надир әл-Хөҗәнди һәм башкалар.

Шәкертләре: Әхмәд бине Габделкадыйр әт-Тактавый, Габделвахид бине Габдеррахман әл-Буавый, Габделкәрим бине Ишбай әл-Чутайи, Сираҗетддин бине Сәйфулла әл-Кызылъярый, мөфти Таҗеддин бине Мостафа, Таҗеддин бине Бәшир әс-Суыксувый, Фәхреддин бине Мостафа ән-Нурлатый, Ризван бине Әсәдулла әл-Итәвеши әл-Уфавый һәм башкалар.

Илебездә гыйлем вә фазыл, зирәклек вә байлык кебек сыйфатларны үзендә туплаган мәшһүр затларның берседер. Олы сәүдәсе, хәтта заводлары булып, җитештергән товарларын мәшһүр базарларга җибәреп саттыра вә күп кенә вәкилләр тота иде. Бу сәбәптән Казан шәһәре муллаларының берсе 1839 елның 15 февралендә моның өстеннән «имам була торып сәүдә кыла» дип шикаять итте. Ул вакытның закон китапларында мәхәллә имамнырының сәүдә итүләре хакында мәгълүм бер маддә булмаганнан вә иң тугрысы да мөселманнарга кагылышлы тәртип-кануннар бөтен бөтенгә законга кертелмәгәннән // [193], мәзкүр эш тә мәхкәмәдән мәхкәмәгә күчеп йөргән вә ахыр чиктә эчке эшләр нәзарәтенә җиткән. Эчке эшләр нәзарәте исә бу хосуска бәйле булган мәгълүматны җыеп, Мәхкәмәи исламиягә 1841 елның 25 апрелендә 1036 нчы санлы түбәндәге эчтәлекле бер бәяннамә язган: «Имам Байморад бине Мөхәррәм, имам булган хәлдә сәүдә итүе рөхсәт ителмәсә дә, ләкин бу гамәлен үзе идарә итмичә, бәлки вәкилләр аркылы башкарганыннан, тәртипкә каршы эш күрелми».

Мөхәммәдйосыф әфәнде бине Дибирди: «Безнең авылыбызда Байморад хәзрәтнең бер шәкерте имам иде, озын гомер сөреп бу көннәрдә вафат булды. Шул шәкерт исә Байморад хәзрәтнең «Исагуҗи китабын язучы зат бу илә бер китап язып шөгыльләнгәнче, безнең Казан шәһәренә килеп тә күлмәген салып Печән базарында йөрмеш булса иде, әлбәттә, яхшырак булыр иде» дип сөйләгәнен һәрвакыт риваять итә иде. Исагуҗи китабын ни өчен бу илә рәвештә яратмау сәбәбен белергә теләсәк тә, мәзкүр шәкертнең безгә моны бәян итәргә көче җитешмәс иде», - ди.

Байморад хәзрәтнең якыннарыннан булган Фәхреддин бине Мостафа ән-

Норлатый хәзрәтләрен күрсәм дә, тәрҗемәи хәле хакында һичнәрсә сорамадым вә ишетмәдем, чөнки ул вакытта мондый әсәр язачагым хыялымда да юк иде.

Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Бохарада укыганнан соң 1228 ел ахырында үз мәмләкәтенә кайтып, Казан өязендә Мәмсә авылында имам, хатыйб вә мөдәррис булды; моннан соң 1254 ел ахырында Казан шәһәренә күчте; һәр ике урынында зур мәдрәсәләр // [194] тотып, күп шәкерт җыйды; дәресе куәтле булган, бигрәк тә «Сүлләм әл-голүм» китабын белеп укытуы белән шөһрәте чыкты; кыска төннәрдә ястү намазы фарыз түгел икәнен дәлилләп һәм дә Аллаһның сыйфатлары хакындагы рисаләләр вә «Хәлл әл-мәгакыйд» исемле бер китап язды. Әйтеп узган мәсьәләләр хакында Мөхәммәделәмин бине Сәйфулла ән-Наласавый белән телдән дә, язма рәвештә дә бәхәсләре бар иде. Бер-берсен сүгеп, хурлаганнар, ләкин сахибе тәрҗемәнең [Байморадның] рисаләләре зәгыйфь, хаталы, әйтергә теләгән әйберләре дә буш, мәгънәсездер», – дип яза.

// [201]

## 275. Таҗеддин бине Мансур

Лаеш өязе Сарыалан авылында имам вә ахун булып 70 яшендә 1265 (1849) елның 24 зөлхиҗҗәсендә (29 октябрь) вафат булды. Никадәр вакытлардыр Җәмгыяте шәргыядә әгъза булып хезмәт итте. 1806, 1807 елларда имза кылган кәгазьләре күренде. Йосыф бине Исмәгыйль бине Апанай үтенече белән 1820 елда мөфти Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәен тарафыннан Мәкәрҗә базарына әһле ислам өчен имам булып җибәрелгән иде. Мансурның анасы Гөлшан исемендә // [202] булып Келәнче авылында Гает мулла исемле кешенең кызы иде. Гает мулланың Назыйфә исемле икенче кызы Яңасала авылында Сәгыйдь мулланың хатыны вә Халид бине Сәгыйдьнең анасы иде. Таҗеддин ахунның остазы Халид бине Сәгыйдь яки аның атасы Сәгыйдь мулла булса кирәк. Таҗеддин ахунның Габделгани, Мөхәммәдҗан, Мөхәммәдшаһ исемле уллары калса да, бүген барысы да вафат булдылар, нәселләре дә калмады. Шул җәһәттән Таҗеддин ахунның нәсел җебе өзелде. Таҗеддиннең Хәбибулла исемле бертуганы булып, Күки авылында имам булып торды.

**276. Габделхәбир бине Синҗаб бине Салих бине Сәлүк бине Бикчура бине Бикәй бине Җанъегет бине Җанибик бине Балтач**

Бәләбәй өязе Богады авылында имам булып, 66 яшендә 1266 (1849) елның 7 мөхәррәмендә (22 ноябрь) шул авылда мәрхүм булды.

Остазлары: Фәйзулла бине Габдессәлам әл-Карйаудый, Габденнасыйр бине Торымтай әл-Ирсайи, Әмирхан бине Кучкар, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни.

Балалары: Хәйрулла, Галиулла, Вәлиулла, Әхмәд. Хатыннары: Сафуателкәмал бинте Хәмид һәм Хәнифә бинте Хәнәфия.

// [203]

**277. Габделхәким бине Исламкол**

Казан янындагы Хәсәншәех авылында имам булып 85 яшендә 1266 елның рабигыль-ахир аенда (1850 елның февраль ае) вафат булды.

Балалары: Мөхәммәдессадыйк, Зәкиҗан, Әхмәдессадыйк, Әхмәдҗан, Һадиҗан. Асылы Бәләбәй өязе Кандракүл авылыннан иде. Казан янындагы Олы Бәрәскә авылында Габделваһһаб исемле мөдәррис хозурында укыды. Остазы хаҗ сәфәренә киткәч, аның имамлык вә укыту хезмәтләрен башкарып торды. Хаҗ сәфәреннән сәламәт кайткан остазының рөхсәте белән Бохарага сәфәр кылып, анда унбиш еллар гомерен уздырды, соңыннан Кабул шәһәренә барып бер шәех хозурында суфый-чылык гыйлеменнән иҗазәт алды. Үз иленә кайткач, Хәсәншәех авылында имам булды. Ләкин мәхәллә әһелләреннән булган кайбер кемсәләрнең рәнҗетү вә золымнарына түзә алмыйча бу авылны ташлап, Арбаш авылына күчте. Шул авылда биш еллар торып, Урбар авылына күчеп китте. Хәсәншәех халкы кабат барып үтенгәннән соң, янәдән Хәсәншәех авылына килде. Мөхәммәдсадыйк исемле улы Хәсәншәехтә имам булып вафат булды, балалары һәм оныклары бар. Зәкиҗан, Түнтәрдә шәех Гали бине Сәйфулла хозурында укып, Балтач авылында имам булды, шунда вафат. Сөләйман бине Давыд әс-Саснавый: «Габделхәким хәзрәт заһид, гыйлеме белән эш йөртүче, фазыйль һәм камил иде, диләр», – дип безгә язган иде.

**278. Габделҗәлил бине Бирмөгаллә бине Мортаза бине // [204] Морадгали бине Мәнгеш**

1266/1850 елда вафат. Бохарага барып Әбу Салих әл-Хәлеҗи хәзрәтләреннән тарикатьтә рөхсәт алып, мөрид җыеп шәехлек итте.

**279. Әхмәд бине Гаеткол**

Урал вилаятендә Богдан авылында торып, 60 яшьләренә ирешеп, 1266/1850 елда вафат булды. Бу кеше хакында Әхмәдфәрид әфәнде әш-Ширвани: «Әхмәд хәзрәт безнең Урал вилаятендә ислам үсешенә, гыйлем таралуына хезмәт иткән галимнәрнең берсе, укыту өлкәсендә бөек бер иҗтиһад кылганын риваять итәләр, һичкемнән өмет итмичә, үз кул көче белән ризыкланыр иде, шуның өчен кайбер һөнәрләргә өйрәнгән вә шулай фәкыйрь вә мохтаҗ булып дөнья кичергән», – ди.

**280. Хәбибулла бине Рахманколый бине Габдеррахман**

Абыйсы Габденнасыйр ахун бине Рахманколый соңында аның урынына имам булып, 55 яшьләрендә 1266 (1850) елның зөлхиҗҗә аенда (12 октябрь) вафат булды. Кабере Казанда. Анасы Җәмилә бинте Сөбхан бине Йосыф бине Арыслан иде.

Балалары: Гыяседдин, Габдеррахман, Исмәгыйль, Хәдичә, Мәликә, Мәхмүд. Хатыны Сафия бинте Әхмәд әл-Бакырчый иде.

Остазлары: Нигъмәтулла бине Монасиб әл-Бубый, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф // [205] әл-Кирмәни, Габденнасыйр ахун бине Рахманколый, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади.

Шәкертләре: Фәхреддин бине Мостафа эн-Норлатый, Габдессаттар бине Габелгаффар, Шаһиәхмәд бине Йосыф әл-Кавалый, Габделгаллэм бине Салих әл-Чыршывый һәм башкалар.

Казанда ун елдан артык бер вакыт укытты. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Зирәк, күркәм, кара сакаллы иде, галим һәм фазыйль, Коръән укучы иде, абыйсы Габденнасыйр ахунга караганда гыйлемлерәк вә затлырак булганын риваять кылалар», – дигән. Исмәгыйль исемле улы фазыйль Мәрҗани хозурында укыган.

**281. Гыйсмәтулла бине Вәлид бине Нәзир бине Бикәнәй**

Оренбург өязе Чебенле авылында имам булып 64 яшендә 1266/1850 ел ахырында Болак авылында вафат булды.

Остазы Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый иде. Асыллары Малмыж өязе Сасна авылыннан булып, бабасы Бикәнәй Сәгыйдькә килгән вә шунда төпләнеп калган. Бу кешене Габделхак бине Һибәтулла әс-Сәгыйди: «Гүзәл галим вә укыту өлкәсендә иҗтиһадлы, бәхәсләрдә оста һәм тәкәллефсез бер зат булганын риваять итәләр», – дип сыйфатлаган.

**282. Габдешшәкүр бине Габдеррәхим бине Габдеррәшид бине Госман бине Симуш бине Тимергази бине Рузчыпчак // [206] бине Ишмәт бине Бәхтияр бине Аюхан**

Чистай өязе Биккол авылында имам вә старший ахун булып 64 яшендә 1267 (1851) елның рабигыль-әүвәл аенда (гыйнвар) вафат булды. Җәмгыяте шәргыядә әгъза булып хезмәт итте. 1825, 1826, 1827, 1828 елларда имзалаган кәгазьләрне күрдек. Бөтен Чистай өязенә ахун булганына күрә бер ара вакыт шул шәһәрдә торды.

Остазы: Кизләү авылында шәех Гобәйдулла бине Җәгъфәр бине Ибраһим иде.

Хатыны: асылы Сәгыйдь бистәсендә булып та, Тәхтәле авылында имам булган Рәхмәтулла кызы Хилмеҗәүһәр 81 яшендә Каменка авылында 1300 ел ахырында вафат булды. Моннан башка тагын Зөһрә Рәхмәтулла кызы, Мәрфуга шәех Нигъмәтулла әл-Әлмәти кызы, Мәхбүбҗәмал Гомәр кызы исемле хатыннары булса да, Зөһрә һәм Мәрфуга талак булдылар. Нуреддин исемле улы Каменка авылында имам булып 61 яшендә вафат булды. Хилмеҗәүһәр Рәхмәтулла кызыннан дөньяга килгән кызы Шәмсеруй Кизләү авылы имамы Әхмәдшәех Мөхәммәд бине Гобәйдулла никахында булып, бүген исән-сау.

**283. Кәмаледдин бине Мирас бине Юзай**

Казан шәһәрендә Печән базарында указсыз имам булып, 60 яшендә 1267 (1851) елның 4 рабигыль-ахир дә вафат булды. Элек Казанда булган ислам гаскәренә имам

иде. // [208] Балалары булмады. Асылы Мамадыш өязе Бигәнәй авылыннан иде. 1843 елда император тарафыннан алтын медаль белән бүләкләнгәне рәсми кәгазьләрдән мәгълүм.

**284. Һибәтулла бине Тимергали бине Габделкәрим бине Габдерраззак бине Саби бине Атаби бине Кырым бине Әлмән**

Чабаксар өязе Әлмән авылында имам булып, 1234 ел ахырында Җәмгыяте шәргыя әгъзасы буларак Уфа шәһәренә китсә дә, анасы риза булмаганнан, кире кайтты. 1234 (1818) елда имза кылган кәгазьләре бар.

Уллары: Фәйзулла, Сираҗеддин, Хөснеддин. Атасы Тимергали 1240 елда хаҗ сәфәреннән кайтканында вафат булды.

**285. Мөхәммәдeләмин бине Мөхсин бине Гали**

Казан өязе Норма авылында 100 яшендә 1267 (1851) елның 12 рабигыль-әүвәлендә (3 февраль) вафат булды. Асылы Казан өязе Наласа авылыннан.

Остазлары: Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни һәм башкалар.

Норма авылында имам булган, мәдрәсәгә нигез салып, шәкерт җыеп укыткан. Уфа шәһәрендә Җәмгыяте шәргыя ачылгач, иң элек барган әгъзалар өч нәүбәт торып кайтканнан соң дүртенче нәүбәт өчен сайланган өч әгъзаның берсе. // [209] Җәмгыяте шәргыядә бер нәүбәт әгъза булды. 1799 елда үз кулы белән язылган имзалары күренде. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани дә яза. 1838 елның 26 гыйнварында язылган бер хатын күрдек. Язуы гүзәл.

**286. Габделкаһһар бине Габдессаттар бине Сәгыйдь бине Әхмәд әш-Шырданый**

Казан шәһәрендә имам булып 40 яшьләрендә 1267/1851 елның шәгъбанында вафат булды. Балалары юк. Бохара вилаятендә, Гыйҗдуванда дөньяга килеп, соңыннан Казанга килгән вә Габденнасыйр ахун бине Рахманкол эшеннән алынгач,

аның урынына ахун булып билгеләнгән. Фарсы телен гүзәл белгән, дөрес сөйләгән, имеш.

**287. Сәйфулла бине Мортаза бине Мөхәммәдкол бине Мәмтәй бине Туйтик**

Казан шәһәрендә 95 яшендә 1267/1851 елның җөмадиел-әүвәлдә вафат булды. Казан өязе Мөндеш авылында имам булып, соңыннан Җәмгыяте шәргыягә әгъза булып сайланган. 1800-1802 елларда имза кылган кәгазьләре бар. Шуннан кайткач, кайсы еллардадыр, имамлык вазыйфасыннан читләштерелгәч, Казан шәһәренә килеп торды. Ахыр гомерендә күзләре сукырайды. Мостай хаҗи, Фәйзулла, Вәлид, Сәгыйдь әл-Әстерханый исемле кемсәләр моның абыйлары, имеш.

**288. Фәйзулла бине Мортаза бине Мөхәммәдкол бине Мәмтәй бине Туйтик**

Казан өязе Мөндеш авылында имам булып, 1267/1851 елда вафат булды. Гобәйдулла исемле улы калды. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани дә язган.

**289. Хәбибулла бине Ишдәүләт бине Байгилде бине Котлыгөммәт**

Оренбург ягындагы Хуҗабик авылында имам булып, 60 яшьләрендә 1267/1851 елда вафат // [212] булды. Гыйльме нәхүдә [грамматика] осталыгы вә гүзәл рәвештә шәкертләр укытуы турында сөйләнә. Шәех Дәүләтшаһ бине Гаделшаһ хәзрәтләренең чордашларыннан, имеш.

... [төп нөсхәдә шулай. – *Төз.*] **Мөхәммәдшаһ бине Мирас**

Троицки шәһәрендә икенче җамигъ мәчет хозурында имам булып, өченче мәртәбә хаҗ сәфәрендә 1267 (1850) ел ахырында Мәдинәдә вафат булды. Кабере Җәннәт әл-бәкыйгда билгеле. Оры авылында мәшһүр сәүдәгәр Мөэмин бай бине Таһир бине Нәзир ошбу мәчетне 1836-1838 елларда бина иткәннән соң беренче имам булып указ белән билгеләнде. Хозурында булган мәдрәсәләрендә дәрес укытуы риваять кылына. Мәдрәсә биналарын шәһәр сәүдәгәрләреннән Мөнасиб бине Уразай таштан 1846 елда төзеткән. Бу зат Верхнеурал өязе Сәед исемле авылдан иде.

**290. Әбүшәхмә бине Муса бине Габдеррахман**

// [214] Хаҗитархан шәһәрендә беренче мәчеттә имам булып, 63 яшендә 1267 (1851) елның мөхәррәмендә вафат булды. Хисамеддин исемле улы үз урынына имам булып, Хиҗаз сәфәреннән кайтканында Истанбулда вафат булды. Бу кемсә хакында Габдеррахман әфәнде бине Исмәгыйль бине Гомәр: «Әбүшәхмә хәзрәт Ханкирмәннән бу шәһәргә килеп имам булган иде, үз каләме белән имам Газалиның «Минһаҗ әл-габидин» исемле китабын күчергән.

**291. Ибраһим бине Мәдйар бине Ярмәк**

Бөгелмә өязе Чалпы авылында имам вә мөдәррис булып, 73 яшендә 1268 (1852) елның җөмадиел-әүвәлендә (февраль) вафат булды. 1814 елда указ алган иде.

Уллары: Габделхәким, Әхмәдҗан һәм башкалар. Кызларыннан берсе Габдулла бине Габделгафур никахында, икенчесе Габделгали бине Гобәйдулла әл-Бәйрәкәви никахында вафат булдылар.

Остазлары: Әмирхан бине Кучкар әл-Үтәки, Әхмәдҗан бине Әмирхан һәм башкалар.

Шәкертләре: Ризаэддин бине Вәлид һәм башкалар. Мәдрәсәсендә язылган китаплардан гаять гүзәл вә дөрес язылган әсәрләр күренде. Заманасында булган галимнәр арасында игътибарлысы вә халыкка аңлатып вәгазь сөйләү ягыннан иң остасы булып саналырга лаек бер зат икәне риваять кылына.

// [216] Габделхәким исемле улы, Чалпыда имам вә мөдәррис булып, бу көннәрдә вафат булды. Әхмәд исемле улы да, Чалпы авылында имам булып, 80 яшендә вафат булды. Һәр икесенең балалары вә оныклары күп, диләр.

**292. Габделвахид бине Габдеррахман бине Колый әл-Буавый**

Буа шәһәрендә имам булып, 44 яшендә 1268 (1852) ел 27 җөмадиел-ахирдә, якшәмбе көн вафат булды.

Остазлары: Байморад бине Мөхәррәм, Бохарада Салих бине Надир әл-Хөҗәнди, Нияз әл-Бәлхи һәм башкалар. // [217]

Шәкертләре: Әхмәд бине Мөхәммәдшаһ бине Әхтәм әс-Суыксувый, Әхмәд бине Ильяс әл-Каенлыкый, Габдулла бине Шәмседдин бине Әбу Сәгыйдь бине Мансур бине Уразмәт һәм башкалар.

Анасы шәех Хәбибулла бине Госман бине Юныс бине Чиручи кызы Гарифә иде.

Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани дә язган. Балалары калдымы, монысы безгә мәгълүм булмады. Казанда Борнай мәчетендә имам булган Мөхәммәдешшакир әфәнде бине Габделҗаббар бине Габдеррахман моның абыйсының улы була.

### 293. Габдулла бине Әмирхан бине Хуҗамкол

Верхнеурал өязендә Илче авылында имам булып, 88 яшендә 1268/1852 елның рәҗәбендә вафат булды. Зәйнулла бине Улмазкол бине Хуҗамкол белән бер кабиләдән буладыр. Остазы Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавый иде. Гомере буе тәгълим белән мәшгуль булганы риваять кылына.

### 294. Морад бине Йосыф бине Аккош бине Күгәрчен

Златоуст өязе Габдеррәшид авылында имам булып, 70 яшендә 1268 (1852) елның 15 шәгъбанында (9 май) вафат булды.

Балалары: Мөхәммәдшакир, Гыйбадулла, Гатаулла, Вәлиулла, Мөхәммәдзакир һәм башкалар. Мөхәммәдзакир исемле улы, Бохарада укуын тәмамлаганнан соң, Хиҗазга барып берничә мәртәбә хаҗ кылды һәм шунда вафат булды.

Остазлары: Сәгъди бине Максуд әт-Туймый, Сәйфулла бине Үтәгән әс-Сәрдәви, Сәйфеддин бине Әбүбәкер әш-Шыңарый.

Шәкертләре: Юламан бине Габделмән әт-Түләки, Мөхәммәдмөҗавир бине Габделкадыйр әл-Муйнакый, Хәбибулла бине Исмәгыйль әс-Сарылый, Фәхреддин бине Үтәгән әл-Мунайи һәм башкалар.

### 295. Шәрәфеддин бине Сәгыйдь әл-Юкәли

Әй елгасы буенда Юкәле авылында имам булып, 1268 // [219] (1852) елда вафат булды. Салҗут авылыннан ахун Габделмөгыйн Габделгалим улы хәбәренә күрә, 1271

(1854) елның мөхәррәмендә (сентябрь) вафат, имеш. Остазы Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый вә шәехе Сәгъди бине Вилдан әт-Туймый иде. Бу кемсә хакында Гайнан бине Сәгъди: «Үткен зиһенле, гыйлемнәрдә оста вә яхшы белүче, авыр мәсьәләләрне хәл итүдә башкалардан өстен иде; хозурыннан киткәннән соң хәтта үзенең остазы булган Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый үз шәкертләренә: «Бу бәхәсне Шәрәфеддин менә болай хәл итәр иде», – дип әйтә торган булган. Остазының аны шулай мактавына һәм үзеннән күчерелеп телдән телгә йөргән вә риваять кылына торган сүзләргә таянып, «ислам кергән вакыттан башлап бүгенгә кадәр Әй белән Үзән елгалары буенда булган мөселманнар арасында ошбу зат кебек бер галимнең дә пәйдә булуы мәгълүм түгел» дип уйлыйбыз. Атабыздан ишеткән кайбер сүзләр дә бу фикерне куәтли», – дип язган.

Балалары: Мөхәммәдрәхим, Мөхәммәдхәлим һәм башкалар.

### 296. Фәйзулла бине Галиәсгар

Хаҗ сәфәренә барганында вә, икенче бер риваятькә күрә, хаҗ гамәлен тәмам итеп кайтканында, 60 яшендә 1268/1252 елда Адис [Одесса] шәһәрендә вафат булып, шунда җирләнгән. Башта Себердә, Тара шәһәрендә мөәззин булган. Берзаман, хатыны вафат булгач, ике сабый баласын, берсен – үзе, икенчесен абыйсының улы – Сөләйман исемле бер егет, кулларына күтәреп, гыйлем туплау максаты белән җәяүләп Бохара шәһәренә киткәннәр. Шунда ун еллар торып, гыйлем үзләштергән. // [220] Кабат Тара шәһәренә кайтканында, абыйсы Дәүләтбакый бине Галиәсгар урынына мөдәррис булып сайланган. Нияз хаҗи бине Хәйдәр Аиткин үзенең кызын аңа никах итеп хатынлыкка биргән. Монда 3-5 еллар торгач, Кыргаб авылына күчкән, шуннан Хиҗазга сәфәр кылган. Тара, Тубыл якларында булган имамнарның күбесе моның шәкертләредер. Шулар арасында мөхтәсиб Мәһди бине Сәедик, Насреддин бине Корбан һәм башкалар. Гаять тугрылыклы, диндар, фазыйль, гыйлеме белән бөтен җирдә шөһрәт казанган иде, диләр. Үзенә юлдаш булган китаплары Одессадан йортына кайтарылган, ноктасыз булып язылган бер нөсхә «Ихъя әл-голүм», варислары тарафыннан Нигъмәтулла хаҗи бине Карамшакка сатылып, бүген шул хаҗи әфәнденең Манчыл авылында булган китапханәсендә саклана. Балалары калган

булса да, бу фазыйльнең гыйлеменә вә камиллегенә варис була алмадылар. Шул яктан бу мескен мәрхәмәткә лаек!..

Бу кемсә хакында Хөҗҗәтелхәким әфәнде бине Мәхмүд: «Фәйзулла хәзрәт Бохарадан кайткач, Тара халкы гаять ихлас рәвештә аны мөдәррис итеп билгеләделәр, хәтта Нияз хаҗи үзенең кызын да бирде, ләкин безнең Тара әһеленең ихласлары һичбер затның гомеренә җитәчәк дәрәҗәдә булмый, бәлки 3-5, иң күбе 10 елдан соң тәмам киресенә алмаша. Шул сәбәпле Тара халкы бу заттан ихласларын алдылар вә ул үзе дә, начар мөгамәләне күтәрә алмыйча, авылга күчеп китте», – дип яза. // [221]

**297. Гаделгаффар бине Гаделшаһ бине Хәлил бине Тукай**

Казан тарафында Балтач авылында имам булып, 1268 (1852) елның зөлхиҗҗә ахырында (сентябрь яки октябрь) вафат булды.

Балалары: Баһаведдин, Сәгъдеддин, Гыйззенниса, Бәдигылькәмал, Хөббенниса. Баһаведдин Бохарада укыса да, имамлыкны сайламыйча, Балтач авылында торып 1288 елның рабигыль-әүвәлендә (1871 елның май ае) вафат булды. Аны Шәмседдин бине Рәхмәтулла әт-Түнтәри мактаган, имеш. Сәгъдеддин Балтач авылында имам булып вафат китте. Сабир исемле улы бүген шул авылда имам.

Гыйззенниса – шәех Гали бине Сәйфулла әт-Түнтәри никахында, Бәдигылькәмал – Карадуган авылында Мифтахеддин исемле имам никахында, Хөббенниса Сәрдек авылында Мөхәммәдҗан исемле имам никахында иде. Атасы Гаделшаһ Балтачта имам булып вафат китте. Анасы Бәдигыльҗәмал Мәмәш авылында Рәхмәтулла бине Иманколның кызы вә Нигъмәтулла бине Рәхмәтуллаән-Наласавыйның туганы була. Остазлары Казан шәһәрендә Сәгыйдь бине Әхмәд әш-Шырданый, Рәхмәтулла бине Иманкол әл-Мәмәши, Нигъмәтулла бине Рәхмәтуллаән-Наласавый иде. Халык арасында исеме Габделгаффар дип мәшһүр булган хәлдә, үз каләме белән Габделгафур бине Гаделшаһ дип язылганын күрдек. Шаян сүзгә оста, ягымлы, әдәпле бер зат иде, кайбер шаяртулары телдән телгә сөйләнә. Яхшы холыклы, гүзәл нәсыйхәтле булган. Балтач авылының галимнәргә итагатьле вә башкаларга карата әдәпле булганыннан шулай уйлаучылар бар. // [222] Әмма соңгы вакытта боларның шундый гүзәл хәлләре шактый бозыла башлады. Әгәр дә

иҗтиһадлы вә гыйлем ягыннан гүзәл хезмәтле бер адәм җитешмәсә, башка авыллар кебек боларда да бозык әхлак, наданлык, ялкаулык вә сүлпәнлек, кирелек вә тупаслык мәйдан алыр, диләр.

**298. Фәтхулла бине Сәфәргали бине әл-Хөсәен әл-Мәнәвези**

Казан өязе Казаклар авылында имам, мөдәррис, ахун булып, 80 яшендә 1269 (1852) елның рабигыль-әүвәлендә (декабрь) вафат булды. Җеназа намазын Нәҗмеддин хафиз бине Шәриф укыды. Асылы Бәләбәй өязе Мәнәвез авылыннан.

Остазлары: Салих бине Сәгыйдь әл-Кили һәм башкалар.

Шәкертләре: Сәедбаттал бине әл-Мөкарри, Заһид бине Мөхәммәдрәхим әл-Юртышый, Сәгыйдь бине Хәмид әл-Кавалый, Габденнасыйр бине Габдеррәхим әт-Тайсуганый, Хәммад бине Халид әл-Кавалый, Зөбәер бине Исхак әл-Айбашый, Фәхреддин бине Шәмседдин әл-Каратмәни, Мөхәммәдфатыйх бине Габделхаликъ бине Хәлил әл-Уралый, Мохтар бине Гомәр әс-Суыксувый, Хөснеддин бине Гомәр әс-Суыксувый һәм башкалар. Дөресе гүзәл, шәкертләре күп булуы белән шөһрәт казанды. Мәккә-Мәдинәгә зиярәт кылып, Хиҗаз вә Рум галимнәре белән аралашты, шәех Халид бине Әхмәд эш-Шәһрезурый алмашчысы булган Габдулла әл-Әрзинҗаный хәзрәтләреннән суфыйчылык гыйлемен, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдадидан кыйраәт гыйлемен өйрәнеп, рөхсәт алган.

Берникадәр вакыт ахун булса да, замандашларының кайберләре аркасында бу урыныннан куылды, шул хәлендә яшәп // [223] дөньяга сул кулын селкеп ахирәткә сәфәр итте. Ләкин моны кудырган затлар да дөньяда мәңге калмадылар!.. // [226]

**299. Габдеррәшид бине Габдулла бине Мөхсин**

Казан өязе Әтнә авылында имам булып, 1269/1853 елның җөмадиел-әүвәл аенда вафат булды.

**300. Нигъмәтулла бине Гобәйдулла бине Җәгъфәр**

Чистай өязе Әлмәт авылында имам булып, 82 яшендә 1269 (1853) елның 22

җөмадиел-ахирендә (22 март) вафат булды.

Балалары: Гатаулла, Хәйрулла.

Остазлары: Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни һәм башкалар. Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдадидан – кыйраәт гыйлемен, атасы шәех Гобәйдулла бине Нигъмәтулладан тарикать гыйлемен алган.

Шәкертләре: Телгә алынган уллары, Габделҗәббар бине Җәгъфәр әл-Пәрәви, Габделваһһаб бине Иманколый әр-Рәҗәби, Габид бине Габделҗәлил әл-Кармышый һәм башкалар.

Хәлифәсе: Габделҗәббар бине Җәгъфәр әл-Пәрәви иде. Хәбибулла бине әс-Сенбери исемле затның моның хакында сөйләнгән мәрсиясе бар. // [229]

## 301. Рәмкол бине Максуд бине Мөхсин бине Шәех

Бөгелмә өязе Шушма елгасының сул тарафында булган Иштирәк авылында имам булып, 63 яшендә 1269 (1853) елның 15 рамазанында (10 июнь) вафат булды. Васыяте таләбенчә Мөхәммәдшәриф бине Сөләйман бине Чикә исемле кемсә янында күмелгән. Асылы Богыруслан өязе Байтуган авылыннан иде. Фәкыйрь бер гаиләдән булганыннан, сабый вакытында гыйлемгә мәхәббәте сәбәпле, җәяү Казан якларындагы Саба авылына сәфәр тоткан, шунда, һич ватанына кайтып килмичә, унике ел рәттән торган. Хатыны Фәрхеҗәмал бинте Гыйсмәтулла бине Габдеррахман үзеннән бер ай // [230] кадәр соңрак, 54 яшендә 25 шәүвәлдә (20 июль) кинәт кенә вафат булды.

Балалары: Мәүһүбә, Һәдия, Мәрфуга, Мөхәммәд, Мостафа. Мәүһүбә без фәкыйрьнең анасы булып, 51 яшендә, 1290 (1873) елның 9 рәҗәбендә вафат булып, 10 рәҗәбтә җирләнде (август 20-21, чәршәмбе вә пәнҗешәмбе көннәр). Кабере Кичүчат авылында. Һәдия үзенең уллары белән бергә Оренбург шәһәренә күчеп, беркадәр вакыт торды, 1311 (1893) елда ваба авыруыннан вафат булды. Балалары шунда. Мәрфуга Шөгер авылында бер кемсәгә никахланып, вафат булды. Бер улы бүген сәламәт. Мөхәммәд, Габдессаттар бине Габдулла әт-Туймазый хозурында укып, Иске Иштирәк авылында имам булды. 1311 (1894) елның рамазан аенда ястү

намазының дүрт рәкәгать сөннәтен укып тәмамлагач, фарыз укырга камәт төшерергә вакыт җиткәндә мәчет эчендә рухын тәслим кылды. Язуы гүзәл вә дөрес иде. Мөхәммәд бине Гобәйдулла әл-Кизләви хозурына барып, тарикать юлына басты. Иштирәк авылында балалары вә нәсел дәвамчылары бар. Мостафа исә мәзкүр авылда мөәззин, бүген сәламәт.

Остазлары: Сәйфеддин бине Әбүбәкер әш-Шыңарый, Фәхреддин бине Сөбханкол әл-Кичүчатый, Хисамеддин бине Мөэмин әл-Әлкәи һәм башкалар. Гәрчә мәдрәсә тотып дәрес бирмәсә дә, шөгыле даими китап өйрәнү, кадерле һәм кыйммәтле китап нөсхәләрен җыю, аларны чагыштырып дөресләү булды. Заманына күрә байлыгы да яхшы булганыннан, күп кешеләргә күрергә насыйп булмаган әсәрләрне табуга ирешә алган. Ләкин үз вафатыннан соң мондый кадерле әсәрләре кадерсез булды, күпчелеге // [231] чистайлы шәех Мөхәммәдзакир бине Габделвәһһаб әс-Саснавый китапханәсенә җыелды, диләр. Тәкъва, диндар, гүзәл холык һәм гүзәл нәсыйхәт белән билгеле иде. Шәех Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрлигә дус булган. Җәнаб Аллаһ мәрхәмәтле булсын, гафу әйләсен!

**302. Сәйфулла бине Үтәгән бине Надир бине Сөбкә бине Сафәр бине Уразай бине Гаедхуҗа бине Шәмсехуҗа**

Кызылъяр (Петропавел) шәһәрендә 87 яшендә 1269/1853 елның зөлкагдәсендә вафат булды.

Балалары: Габденнасыйр, Сираҗеддин, Габделлатыйф, Габделмәннан, Әхмәд, Бәдреддин, Сахибҗәмал, Мәхбүбкәмал. Габденнасыйр Ханкирмән тарафында Курски исемле авылда имам вә мөдәррис булып вафат. Аңа хаҗи Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади тарафыннан 1234 елда язылган бер иҗазәтнамәсен күрдек. Мәхбүбкәмал Төхфәтулла бине Габдеррахман никахында булып, Әхмәдвәли ахунның анасы иде.

Остазлары: Габдеррәшид бине Габделкәрим әс-Сәгыйди, Дагыстанда Хәсән әфәнде әл-Кәдали. // [232]

Шәкертләре: Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый, Сәгыйдь бине Хәмид әл-Казаный, Хәммад бине Халид әс-Салавый, Фәйзулла бине Җомгакол әл-Кисильями, Морадым бине Йосыф әл-Уфавый һәм башкалар.

Асылы Казан вилаяте Комыргуҗа авылыннан булып, шул җирдә дөньяга килгән. Тирә ягындагы мөгаллим вә мөдәррисләрдән укыганнан соң, Сәгыйдь бистәсенә барган, соңыннан Дагыстан якларына сәфәр кылган. Үз иленә кайтканнан соң Сәрдә авылында мәдрәсә тотып, уку-укыту белән шөгыльләнде, соңрак Ханкирмән өязендә Курскигә килеп өч ел вакыт торды вә шуннан Кызылъярга имам вә мөдәррис булып күчеп китте. Гомере озын булганга, гасырдашларыннан исән калып, игътибар вә хөрмәттә гомер кичерде, диләр. Аның турында фазыйль Мәрҗани дә язган.

**303. Сәйфулла бине Юрткәй бине Габдекәй бине Хатим бине Ишбулад бине Баймәт бине Байкилде бине Ябынчы бине Юлхуҗа**

Бөре өязендә Минҗар авылында имам булып, 90 яшендә 1269/1853 елда вафат булды.

Балалары: Сәйфеддин, Сәйфелмөлек, Әхмәдҗан, Гыйлемхан һәм башкалар.

Остазлары: Габденнасыйр бине Торымтай әл-Ирсайи, Габделмөэмин бине Чупай, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни.

Шәкерт вакытында гаскәр хезмәтенә алынып, бер ара вакыт шунда гомер кичергән. Үз ватанына кайтканнан соң, Наҗи Тамак, аннан соң Биш Курай, соңрак Минҗарда имам булган. Гомере буенча китап язган бер адәм булып, үзенең дәрес китапларын үзе язган кебек балаларына да дәрес өчен китап язып җитештереп торган. Һәр ел Бөгелмә ярминкәсенә барып ике туп кәгазь алып кайта вә икенче ел ярминкәсенә кадәр язып бетерә торган булган. Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавый белән Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим әл-Бәйрәкәвиләргә каршы ястү намазы хакында, Дәүләтшаһ ишан бине Гаделшаһка умарта корты мәсьәләсе хакында каршы булып гарәп телендә рисаләләре булса да, барысы да зәгыйфь нәрсәләр. Язуы да гаять кызыксыз, хаталы. Башкорт җирләре мәмлүк [милекләнгән] булу-булмавы хакында Нигъмәтулла бине Максуд әл-Күккуяный белән бәхәсләшкән. Моңа исә хәтта остазлары Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни дә катышып, хөкем чыгару сурәтендә кайбер нәрсәләр язган. Бу өч кемсәнең ничә еллар // [335] барган бәхәсләрен, сарыф ителгән кәгазь вә караларын

җиңел генә санап бетерерлек түгел. Шуның белән бергә, Каф тавы, җирне күтәргән үгез вә балык бәхәсләренә караганда беркадәр булса да ярарлык!

**304. Гайнеддин бине Галиәкбәр бине Морад бине Сөләйман**

Лаеш өязе Сингел авылында имам булып, 1269/1853 елда вафат булды. Гомерендә ике мәртәбә хаҗ кылган, бер нәүбәт Җәмгыяте шәргыйдә әгъза булган. 1835 елда имзалаган кәгазьләрен күрдек.

**305. Минуш бине Мостай бине Исмәгыйль бине Әхмәд бине Уразлы бине Уразай бине Уразгилде**

Сембер ягында Үтәмеш авылында имам булып, 1269/1853 елда вафат булды. Бу кемсә үз тәрҗемәи хәлен болай яза: «Атабыз Мостай 1791 елда купең булып Казанга күчте, 1796 елда Буага кайтты, 1810 елда вафат булды. Мин 1793 ел апрелендә Сары Кокшай өязе Шинбер авылында имам булдым, 1812 елда имамлыкны ташлап кайттым вә шул елда Сембер өязе Үтәмеш авылында имам булдым. 1830 елда Уфа шәһәренә барып Мәхкәмә шәргыйдә имтихан кылындым. Исмәгыйль бабайның Исхак, Мәүлүд, Мансур, Мостай исемле уллары булган, Исмәгыйль вафат булганда, атабыз Мостай бер яшендә калып, анасы Гаишәбикә тәрбиясендә тәрбияләнгән». Сахибе тәрҗемәнең төрле мәсьәләләрдә осталыгы булып // [236] үз кулы белән күп китап вә Кәләм шәриф язган, күчергән, ләкин язылган әсәрләре барысы янгыннарда янып югалып беткән, диләр. Үзе вафат булгач, урынында Хөснеддин исемле улы имам булып калды, аның улы – бүген Самара шәһәрендә имам вә ахун Шиһабеддин әфәнде.

**306. Гобәйдулла бине Сәпкол**

Әстерхан шәһәренең җиденче мәчетендә имам булып, 63 яшендә 1269 елның зөлхиҗҗә башында (1853 елның 23 августы) вафат булды.

Остазлары: Хәсән бине Мансур әс-Сәрдәви һәм башкалар. Яшьлегендә Әстерхан шәһәренә барып, аннан Бохарага сәфәр итте. Анда исә күп еллар укып, могтәбәр галимнәр төркеменә керде. 1829 елда Әстерханга кайтып Фәтхулла бине

Уразмәт исемле имам кызына никахланды, Молтан Сарай исемле мәхәллә байларының ихлас баглап чакыруларына күрә, мәхәлләләрендәге мәчеткә имам булды. Мәдрәсәләр оештырып, күп шәкерт җыйды. Имамлык, хөтбә сөйләү, укыту белән мәшгуль булудан башка шәһәрдә кибет ачып сәүдә кылды. Соңрак мәхәллә әһеле белән аралары салкынаеп, 56 кемсә тарафыннан оештырылган гариза нәтиҗәсендә вилаять мәхкәмәсе тарафыннан 1840 елда эшеннән алынды. Ләкин вилаять мәхкәмәсенең хөкеме 1842 елның 11 июнендә юкка чыгарылып, кире хезмәтенә кайтты. Соңрак исә бу мәхәлләдән җиденче мәхәллә мәчетенә күчте, шул вазыйфаны башкарганда ваба авыруыннан вафат булды. Мәшәехле зиратында җирләнгән. Казан шәһәрендә Мостай хафиз бине Муса вафатыннан // [237] соң бу кемсәне алу хакында Габдессәлам мөфти бине Габдеррәхим Казан байларына аның яклы бер хат язганы риваять кылына. Нурмөхәммәд мөхтәсиб бине Ибраһим әфәндегә бу турыда язылган хаты бар. Дәресе бик ачык, китабы бик күп, хозурында күп затлар файда күрде, диләр.

**307. Габбас бине Габдеррәшид бине Әхмәд бине Шөкер бине Хәсән бине Хөсәен бине Котлымөхәммәд бине Ишмөхәммәд бине Дустмөхәммәд бине Багыш бине Явыш әл-Күшәри**

Казан өязе Күшәр авылында имам вә мөдәррис булып, 90 яшендә 1270/1853 елның сәфәр аенда вафат булды.

Балалары: Гата, Габделбарый.

Остазлары: Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Җәгъфәр бине Габид әл-Арысланый һәм башкалар.

Шәкертләре: Габделваһһаб бине Имамколый әр-Рәҗәби, мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим, Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри һәм башкалар. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани дә язган.

// [239]

**308. Сабанчы бине Ярмөхәммәд**

Тубыл янында булган Коллар авылында имам булып, 94 яшендә 1270/1853 елда вафат булды. Бу җирләрдә булган мәдрәсәләрдә башлангыч белемне үзләштергәннән соң, Бохарага барып укыган.

Шәкертләре: Фәхреддин бине Ярлыкаш, Нәүрүз бине Сабанчы әт-Тубылый, Рузмөхәммәд бине Гомәр, Таштимер бине Биләл һәм башкалар. Вафат булган көненә кадәр дәрес белән мәшгуль булган, күп шәкерт җыеп гыйлем тарату өлкәсендә күп тырышкан. Астрономия гыйлемендә осталыгы булып, кояш һәм ай тотылу хакында күп вакыт алдан хәбәр бирер, шәкертләренә күрсәтеп торыр иде, диләр. Ул төзегән тәкъвим [календарь] вә айларның беренче көннәрен билгеләү җәдвәле бүгенгә кадәр Себердә төп кулланма булып торганын // [240] Нигъмәтулла бине Карамшактан ишеткән идем. Себер рус кулы астына кергәннән соң иң беренче булып Хиҗазга барып хаҗ кылган кемсәләр ошбу Сабанчы һәм иптәшләре булган.

**309. Габделвахид бине Исмәгыйль бине Давыдхан**

Касыйм шәһәрендә Хан мәчетендә имам булып, 90 яшен кичеп 1270 (1854) елның 20 шәүвәлендә (4 апрель) вафат булды. Балалары: Фазлулла, Гыйззәтулла.

Асылы Йылатма өязе Бостан авылыннан иде. 1200 ел ахырында шул мәчеткә имам булды. // [241] Моның белән бергә бу җирләрдә булган почталарны йөртер иде. Касыйм халкы тәммүз (июль) аеның егерменче көнендә бер бәйрәм ясап, сарык вә куйлар суяр иде, ир вә хатын бөтенесе бергә катышып туй [бәйрәм] вә кунакта йөрерләр (Ильин празднигы кебек), вә кайбер вакыт келәү [Келәү] исеме белән казлар чалып җеннәрне ризаландырыр уенда булырлар, имеш. Әлеге зат бу бидгать гадәтләрне бетерүгә иреште, диләр. Бу мәчеттә моннан алда булган имамнар кем булганнары безгә беленмәде, Касыйм ханнарының ахырлары булган Фатыйма солтан бинте Акмөхәммәд 1094 елда вафат булганнан соң, император тарафыннан 1768 (1180) елның 9 апрелендә (зөлхиҗҗә) булган әмеренә күрә бер елдан соң Биктимер сәед, Борһан сәед, Ибраһим мирза Чанышев, Габдулла мирза, Муса сәед, Мостафа сәед, Сөләйман мирза, Тимербулат сәед, Йосыф мирза Чанышев, Мортаза сәед, Мөхәммәд сәед, Ибраһим мирза Максудов, Ягъкуб мирза Дәүләткилдиев, Йосыф

мирза, Ибраһим мирза Максудовлар, Мостафа мирза, Тимербулат мирза Шаһкулов исемле кемсәләр бина кылганлыгы мәчетнең диварына язылганы риваять кылына. Бу вакыйга хан чорыннан соң бер гасыр узгач, 86 нчы елда була. Сахибе тәрҗемә соңында Фазлулла исемле улы имам булды.

### 310. Мөхәммәдкәрим бине Исхак бине Исмәгыйль

Минзәлә өязе Мәчтәй авылында имам булып, 68 яшендә 1270/1854 елда вафат булды.

Остазлары: Габделлатыйф бине Сөбханкол әл-Корычый, Әхтәм бине Әхмәр // [242] әс-Сарлый, Габделхәлим бине Зәйнелгабидин әл-Мортышый, Шаһиәхмәд бине Рәфыйк әс-Симәки.

Шәкертләре: Төхфәтулла бине Мөхәммәдшәриф әл-Әлмәни әл-Эчкени, Мөхәммәдҗан бине Нигъмәтулла әл-Кыйгывый, Гыймадеддин бине Сәгъдеддин әс-Салихый, Нуреддин бине Шаһиәхмәд әс-Симәки һәм башкалар. Асылы Бәләбәй өязе Сүн елгасындагы Югары Ташлы авылыннан. Минзәлә өязе Олы Имән вә аннан соң Мәчтәй авылында күп шәкерт җыеп укытты. Таң атканчы дәрескә килеп укытыр иде, аннан мәчеткә иртә намазына китә, намаз тәмамлангач шунда ук «Гайн әл-гыйлем», «Мишкат әл-Масабих» китапларыннан дөрес бирер иде. Ишрак намазын укыгач өенә кайтып бераз ял иткәннән соң мәдрәсәгә барыр, аннан өйлә намазына чыгар, имеш. Икенде белән ахшам арасында Тәфсир Җәләләйн, ястүдән соң гарәп теле, кәлям вә башка дәресләр укытыр, имеш. Өстәмә сөннәтләргә игътибары тулы булып, хәтта сәфәрендә дә калдырмас иде, диләр. Йортының ихатасы чыбыктан булып, өенең тәрәзәләре җирдән чарык аршын югары иде, диләр. Таһарәт вакытында битне тугыз мәртәбә юу сөннәт булып, өч мәртәбә белән генә сөннәт башкарылмаганын дәгъва кылса да, шәкертләренә моны йөкләмәс иде, диләр. Хатыны Шаһиәхмәд бине Рәфыйк әс-Симәки белән бертуган иде.
// [243]

**311. Мөхсин бине Мәхмүд бине Габдулла бине Габделхәй бине Ишкинә бине Ишмәк бине Агый бине Нүкәш**

Бөре өязе Каенлык авылында имам булып, 1270/1854 елда вафат булды. Галәведдин исемле улы калды.

Остазлары: Габденнасыйр бине Торымтай әл-Ирсайи, Җәгъфәр бине Имай әл-Бикмәти, Шәмседдин бине Дәванай [Диванай] әл-Бикмәти. Гүзәл тавышлы, гүзәл язулы, яхшы холыклы бер зат иде, диләр.

**312. Шәмседдин бине Зөбәер бине Җәгъфәр**

Казан шәһәренең унөченче мәчетендә имам булып, 83 яшендә 1270 (1854) елның зөлкагдә ахырында вафат булды. Ятим Шәмседдин буларак билгеле иде. Асылы Борнак Иле авылыннан.

Остазлары: Хәбибулла бине әл-Хөсәен әл-Орый, Салих бине Сәгыйдь әл-Кили, Габделгаффар бине Сәгыйдь әш-Ширданый һәм башкалар.

Ибраһим исемле бер улы калып, 52 яшьләрендә Казан шәһәрендә 1282 елның рамазанында вафат булды, Исмәгыйль һәм Габделвәли исемле уллары калды. Юныс уллары фамилиясеннән [Юнусовлар] мәшһүр Ибраһим бине Гобәйдулла, Габделгаффар бине Сәгыйдь мәдрәсәсендә торганында, ошбу сахибе тәрҗемәдән укыган. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани дә яза.

// [244]

**313. Таиб бине Заид бине Колмөхәммәд әл-Уралый**

Мәдинә шәһәрендә укучы булып торганда, 1270/1854 елда вафат булды. Верхнеурал өязе табын башкортларыннан. Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавый хозурында укыганнан соң, Түнтәр авылының Хәлил бине ... [төп нөсхәдә шулай. – *Төз.*] исемле зат белән бергә 1235 ел ахырында хаҗ нияте белән Хиҗазга юнәлделәр. Истанбулга баруында хаҗи Мөхәммәдъяр Габдулла әл-Ахуниның кызына никахланды. Хаҗ гамәлләре тәмам булганнан соң, Габдулла әл-Дәһләви хәлифәсе булган Мөхәммәджан әл-Мәккигә бәйгать-ант биреп, тарикатькә кереп берникадәр

вакыт үткәч рөхсәт тә алды. Хатыны – Мөхәммәдъяр хаҗи кызы вафат булганнан соң, солтан Мәхмүд тарафыннан азат ителгән бер җариягә өйләнде. 1249 елда шәех Әбу Сәгыйдь бине Сафиелкадер бине Газизелкадер Хиҗазга килгәнендә аның белән очрашып аралашкан. (Әбу Сәгыйдь исә 1250 елда вафат.) Мәшһүр Минһаҗ әфәнде әл-Мәдәни белән кайбер бәхәсләре булды. Дөрес гыйлемнән байтак кына өлеш алган зат иде, диләр.

### 314. Габделҗаббар бине Сәйфелмөлек бине Мортаза бине Сәлим бине Исмәнән бине Чуракай

Бөре өязе Лаешты авылында имам булып, озын гомер сөреп, 1270/1854 // [245] ел ахырында вафат булды. Галим, сабыр, диндар, китап укырга һәвәсле, язуга оста зат иде, диләр. Моның хакында Габделкәбир бине Габделмөнир әл-Ишкаравый: «Габделҗаббар хәзрәт укыту белән мәшгуль булып, иман вә ислам хөкемнәрен ачык аңлатыр, кунут, азан, кыйраәт догаларын, әт-тәхият, азан вә камәт рәвешләрен, ашаганнан соң, яткан вә торган вакытларда укылачак догаларны, «Аятел Көрси», «Әлхәм» һәм башка кыска сүрәләрне, тәсбих вә тәхмид кебек зикерләрне олылардан башлап сабыйларга кадәр үзе дөрес вә игътибар белән белдереп ятлатыр, мәгънәләрен дә куәтле сурәттә аңлатыр иде. Намаз укырга өйрәткән вакытында чынлыкта да үзе укып, соңыннан шәкертләрне укыганын карап торыр вә һәрберсен үзе өйрәтер иде. Сабый вакытларында бу заттан укып калган күп кешеләрне күрдек, билгеле догаларны вә Коръән шәрифне дөрес укуларына хәйран калдык. «Ислам вә иман нәрсәдән гыйбарәт?» дигән сорау бирелгәндә, тиешле дәрәҗәдә вә сабырлык белән ачык җавап бирәләр. Боларның җавапларын игътибар белән тыңлаучылар гомерләрендә мәктәп вә хәлфә күрмәгән булсалар да, аңлый алалар дип уйлыйбыз», – дигән.

Бу кемсә Бөре өлкәсендә мәшһүр бер гыйлем ханәсенә караган. Атасы Сәйфелмөлек 1200 ел ахырында вафат булып, кабере Коры Алачык авылында. Бөек галимнәрнең берсе иде. Абыйсы Габделкадыйр бине Сәйфелмөлек тә могтәбәр, фазыйль кеше санала иде, диләр. Кайберләре киләчәктә телгә алыныр.

**315. Шәмседдин бине Бәшир бине Морад әл-Кишети**

Казан өязе Яңа Кишет авылында имам булып, 1270/1854 // [246] ел ахырында вафат булды. Печмәнтау авылында имам булган вакытында Җәмгыяте шәргыягә әгъза булып сайланып, Уфа шәһәренә барды. Аннан исә 1251 елда кайтып, Казан шәһәрендә Барудия мәхәлләсендә [Пороховая слобода] имам булса да, эшеннән алынып, Яңа Кишет авылына китте. 1264 елда хаҗ кылды. Вафатыннан соң Сәгъдеддин исемле улы аның урынына имам булды. Улы бүген инде вафат, балалары калмады. Сәгъдеддин белән бертуган бер кызы Юзәй мирза бине Хөсәенгә никахланып, Салих, Гали, Госман исемле уллары дөньяга килде.

// [247]

**316. Корбангали бине Мортаза бине Исмәгыйль бине Йосыф бине Исәнәй бине Исәнкол бине Борнагыл**

Казан шәһәрендә Ибне Борнай дип билгеле булган сәүдәгәр иде. Казанда 1270/1854 елда вафат булды. Асылы Бәрәскә авылыннан булып, Казанга күчкән, мәшһүр байлар хисабына кергән. Яшь вакытында Бохарада укып, мәгърифәт һәм аң-белем кәсеп иткән. 1266 елда хаҗ кылып, Мәдинә шәһәрендә тәкия алып, аны вакыф итеп калдырды. Улы Садыйк та могтәбәр байлардан булып Казан шәһәрендә бүген өченче номер саналган мәчетне таштан төзетте. Үзе 77 яшендә 1315 (1898) елның 23 зөлхиҗҗәсендә (3 май) вафат булды.

**317. Мостафа бине Йосыф бине Давыд әл-Казаный Ибнеззаман**

70 яшендә Казан шәһәрендә 1270/1854 ел ахырында вафат булды. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани дә язган. // [248]

**318. Җәләледдин бине Әхмәд бине Габделҗәлил бине Ибраһим бине Балтай бине Нурмөхәммәд бине Айбакты бине Байбакты бине Яхъя бине Муса әл-Багышый**

Тәтеш өязе Багыш авылында имам булып, 1271 (1854) елда вафат булды.

Җәмгыяте шәргыягә әгъза булып сайланып, ничә еллардыр хезмәт иткән. 1833 елда имзалаган кәгазьләре күренде. Бик яшь вакытында бу хезмәттә булды.

### 319. Гайнан бине Ихсан бине Рәйхан

Бохарада мөдәррис булып, 1271/1854 елда вафат булды. Асылы Бөгелмә өязе Баулы авылыннан иде.

Остазлары: Габделгаффар бине Сәгыйдь әл-Казаный әш-Шырданый, Габденнасыйр бине Габдеррәхим әт-Тайсуганый.

Уллары: Лотфулла, Кәрамәтулла. Бохарада Мәдрәсә-и Җәгъфәр // [249] хуҗада мөдәррис булып, «Мохтасар әл-Викая», «Шәрх әл-Викая», «Һидая» китапларыннан укыткан.

### 320. Бәшир бине Җомгаколый

Тау ягында (...) [төп нөсхәдә шулай. – *Төз.*] авылында 1271/1854 елда вафат булды. Остазы Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек. Гобәйдулла бине Җәгъфәр әл-Кизләви хозурында тәрбия кылынып, тарикатьтә рөхсәт алып, мөрид җыеп шәех булды.

### 321. Габдессаттар бине Габдулла бине Солтанкол

// [250] Бәләбәй өязе Туймазы авылында имам вә мөдәррис булып, 1271/1854 елда вафат булды. Асылы Әй буе башкортларыннан. Нигъмәтулла бине Биктимер якыннарыннан булып, Бохарада хәлифә Ниязколый әт-Төрекмәни хозурында тәрбияләнеп, [тарикатьтә] рөхсәт алган.

Шәкертләре: Җәлаледдин бине Сәйфеддин әл-Кичучатый, Мөхәммәд бине Рәмкол әл-Иштирәки, Фәттахеддин бине Габделмәҗид әс-Сарсазый, Фәхреддин бине Корбангали әл-Каратайи һәм башкалар. Таһарәттә даими, мәчет вә җәмәгатьтә ихлас, диндар, заһид бер зат иде. Зәкят, гошер, фитыр кебек важиб садакаларны кабул итмәс. Дөнья зиннәтләренә кызыкмас, һичкем белән дәгъвалашмас. Хөсетлек вә үч алуга катнашмас. // [252]

**322. Сөләйман бине Ибраһим бине Йосыф бине Исәнәй**

Казан өязе Бәрәскә авылында 1271/1854 елда вафат булды. Балалары: Әхмәд, Исмәгыйль, Йосыф, Мостафа, Фатыйма, Латыйфа. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Зирәк, аңлы, матур телле иде. Җиһангир хан бине Бүкәй хан белән күп вакыт аралашты. Хиҗазга сәфәр итеп хаҗ кылды», – дип әйткән.

**323. Муса бине Габид бине Дәвеки бине Заһид**

Бөгелмә өязе Динис авылында имам булып, 49 яшендә 1272 (1855) елның мөхәррәм (сентябрь) башларында вафат булды.

Балалары: Габделфәттах, Әхмәдкәрим. Атасының тәрҗемәи хәле югарыда китерелде.

Остазлары: Исхак бине Сәгыйдь әл-Кенәри, Габделгафур бине Габделмәннан әл-Чистайи һәм башкалар. Шәкертләре күп булса да, үзенә алмаш булырлык бер кемсә калмаганнан, мәдрәсәләре таралып бетте.

**324. Хөсәен бине Муса бине Ягъкуб бине Ишмәмәт**

Казан сәүдәгәрләреннән булып, 58 яшендә 1272 (1855) елның 111 рабигыль-әүвәлендә (10 октябрь) Казан шәһәрендә вафат булды. Атасы Муса 80 яшендә 1252 елда, анасы Салихә бинте Мортаза 1271 ел зөлкагдәсендә, хатыны Мәхбүбә бинте Бәшир бине Гаид бине Заһид 1284 ел рамазанында вафат булдылар. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Казан шәһәренең юмартлык вә ирлек белән билгеле байлардан булып, Ямаширмә, Кизләү, Юлга, Әсән авылларында булган мәчетләрне төзеткән», – дип әйткән.

**325. Сәгыйдь бине Хәмид бине Солтан**

Казан шәһәренең беренче мәчетендә имам вә мөдәррис булып, 1272 (1856) елның рәҗәб ае башында вафат булды. Бохарада булган хатыны Хөршид бинте Габделвәлидән Мөхеддин исемле улы калды.

Остазлары: Габдеррәзим бине Бикчәнтәй әл-Бәрәскәви, Фәтхулла бине әл-

Хөсәен әл-Орый һәм башкалар.

// [254]

Шәкертләре: Хәбибулла бине Әхмәд әл-Ләбити, Фассахеддин бине Зиннур әл-Марасавый һәм башкалар. Асылы Казан өязе Бәрәскә авылыннан иде. Үз иленең галимнәреннән белем алганнан соң Бохарага барып, анда берничә ел калды, аннан кайткач, берникадәр вакыт Түнтәр мәдрәсәсендә торып, аннан Кызылъяр шәһәренә китте. 1252 елда Казан шәһәренә килеп имам булды. 1265 елда имамлык вазыйфасыннан чыгып, урынына имам алырга кирәген мәхәллә халкына белдертеп, хаҗ сәфәренә китте. Аннан йөреп кайткач кинәт вафат булды. // [256]

**326. Әсфәндияр бине Ибраһим бине Йосыф бине Айтуган**

Казан шәһәрендә тугызынчы мәчет имамы булып, 1272/1856 елда вафат булды.

Остазлары: Габдүш бине Габдессәлам әл-Кавалый. Казан имамнарыннан // [257] булганга күрә телгә алынды. Моннан башка әхвале безгә мәгълүм түгел.

**327. Баһаведдин бине Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани**

Казан өязе Ташкичү авылында имам вә мөдәррис булып, 72 яшендә 1273 (1856) елның рабигыль-әүвәлендә вафат булды. Атасы турында яздык, анасы Загыйфә бинте Габделбакый бине Мөслим бине Мостафа.

Хатыннары: Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек әл-Ашытый кызлары Хәбибә вә Хөбәйбә булып, әүвәлгесе вафат булгач, икенчесенә никахланды.

Остазлары: Бикчәнтәй бине Ибраһим әл-Бәрәскәви, Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек әл-Ашытый, Бохарада Гайсә бине Рәхмәтулла әл-Хукандый, Салих бине Надир әл-Хөҗәнди һәм башкалар.

Шәкертләре: Фәхреддин бине Әбүйәзид әл-Әтнәви, Таҗеддин бине Габделҗәлил әт-Төбъязый, Сәгыд бине Әхтәм әл-Буавый, Әхмәд бине Габделҗәлил әт-Тимерҗаный. Бу кемсә фазыйль Мәрҗанинең атасы була.

// [258]

### 328. Габделгафур бине Мәхмүд бине Мөхәммәделәмин бине Ярмөхәммәд

Казан шәһәренең җиденче мәчеттә имам булып, 1273/1857 елның җөмадиел-ахирендә вафат булды.

Остазлары: Таһир бине Сөбхан әл-Адайи, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый. Бер хаты Габделвахид мөфтинең тәрҗемәи хәлендә телгә алынды.

### 329. Гайсә Ибраһим әл-Мәңгәри

Сими [Семипалат] шәһәренең өченче мәчетендә имам булып, 63 яшендә 1273 (1857) елның рәҗәб (февраль) аенда вафат булды. Асылы Казан өязе Мәңгәр авылыннан булып, Бохарада укыган. Бу кемсә хакында ахун Әхмәдвәли бине Гали: «Гайсә хәзрәт тәкъва вә булганына риза булучы бер адәм, хәтта гошер вә садакаларны кабул итмәс иде. Моның // [259] вафатыннан сон урынына Әхмәдсафа әл-Мөхәммәд улы имам булды», – ди.

### 330. Динмөхәммәд бине Габделбакый бине Морадым бине Шыгай

Кызылъяр өязе Манҗаш авылында имам булып, 1273 (1857) елның 21 шәгъбанында (4 апрель) вафат булды. Яше 84 иде. Асылы типтәр таифәсеннән булып, Хәбибулла бине әл-Хөсәен әл-Орый мәдрәсәсендә укыганнан соң, тарикать юлына басып, остазыннан рөхсәт алган. Хөсниҗиһан бинте Халид исемле хатыныннан Мөхәммәдфазыл, Хәлифә бинте Ташбулат исемле хатыныннан Мөхәммәдсафа, Мөхәммәдгалим, Мөхәммәдсадыйк исемле балалары бар иде. Бу кемсә хакында Гайнан бине Вилдан әт-Туймый: «Мәҗлесенә галимнәр вә фазыйльләр // [260] җыелалар иде. Гасырында булган бөек затлардан, хосусан Мәчкәрәдә укыганнардан Габделмөҗиб бине Габдулла Алахуный, Низамеддин бине Вәйс әс-Сазый, аның улы Шакир әс-Сазый һәм башкалар моңа бәйгать-ант иткәннәр иде. Шәригать юлында тугрылыклы булуы белән шөһрәт казанган иде. Мөридләре, якыннары күп иде. Атам Вильдан бине Сәгъдинең шәехе иде, шул сәбәпле мин дә сабый вакытымда аны күреп калдым», – ди.

**331. Габделгафур бине Сәйфулла бине Гаделшаһ бине Ибраһим бине Нурай бине Җурай бине Илбакты**

Минзәлә өязе Туйгилде авылында имам булып, 66 яшендә 1273 (1857) елның җөмадиел-ахирендә (8 февраль) вафат булды. Хәмидә бинте Чуашай исемле хатыныннан Сабит, Тайибә исемле балалары калды.

Остазлары: Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Хисамеддин бине Габделмөэмин әл-Әлкәйи һәм башкалар.

Шәкертләре: Хәбиберрахман бине Таһир әс-Саклавый, Хәбиберрахман бине Ихсан һәм башкалар. Асыллары Сембер ягындагы бер авылдан булып, Бөгелмә өязе Мактамабаш исемле авылга күчеп килгәннәр. Атасы Сәйфулла бине Гаделшаһ Бөгелмә янында булган Балтач исемле авылда имам булып, сахибе тәрҗемә исә шул авылда дөньяга килгән. Бу кемсә хакында Минһаҗеддин бине Әбелмәгалим әл-Максудый: «Габделгафур хәзрәт заманында игътибарлы бер зат булып, үзен олылык белән вә тыныч тота иде. Сабыр, аз сүзле, тәкәллефсез, риясыз иде. Дәрес бирү, укыту ягыннан // [261] бик иҗтиһадлы булса да, ни хикмәттер, камиллеккә ирешә алмады, шәкертләре мәйданга чыкмадылар. Зөһедлегеннәнме яки саранлыгыннанмы дөнья зиннәтләренә омтылышы юк иде», – ди.

## УНИКЕНЧЕ КИСӘК

## ۱۲ نچی جزء

**332. Каракай бине Исәнгали әл-Кундыравый**

Сакмар елгасы буендагы Кундырау авылында имам булып, 1227 (1812) елда вафат булды. Бохарада шәех Төрекмәни хозурында тәрбия кылынып [мөрид булып] рөхсәт алды. Каракай ишан дип шөһрәте булды. Шул авылы өчен алган указы 1805 елга карый. Үзе төзегән мәчете авылда һаман да тора. Указы белән шәехеннән алган иршады Утар авылында имам булган оныгы Гыйззәтулла бине Гыйсмәтулла бине Каракай милкендә бүген дә саклана.

Шәкертләре: Чирубай бине Яхъя, Шаһиәхмәд бине Турдычин, Юзәй бине Акколый бине Кояш, Каһарман бине Куәт һәм башкалар. Хатыны Рәдүт авылыннан Әхмәд әт-Тәүкили кызы икәнен риваять кылалар.

**333. Каһарман бине Буранкол бине Куәт**

Ор өязе Сакмар суы буендагы Куәт авылында башкортларга кантон булып, 1264 (1848) ел ахырында вафат булды. Остазы Каракай ишан бине Исәнгали иде. Аның мәдрәсәсендә укыганда, 1808 елда «Мөгъдил әс-саләт» исемле // [265] әсәр язганы турында шул әсәрнең ахырында әйтелә. Мәдрәсәдән чыкканнан соң китап җыю белән кызыксынып, үзенә махсус китап язучы тоткан вә шул гасырның сирәк китапларын яздыртып үзендә булдырган.

Уллары: Әбелмихҗән, Мөхәммәд, Мөхәммәдҗан. Әүвәлгесе үзеннән алда вафат булды. Икенчесе волостьта старшина булып бу көннәрдә дөньядан китте.

**334. Бикмөхәммәд бине Ташбулат бине Алуш бине әл-Мөхәммәд бине Йосыф бине Җансәед**

Златоуст өязе Әлкәзи исемле авылда имам булып, 65 яшендә 1272 (1855) елда вафат булды.

Егерме яшьләренә җиткәннән соң, Кызылъяр өязе Имән Елга авылында Гаделшаһ ахун мәдрәсәсенә укырга кергән, 1226(1811) елдан туган авылында имам булган. Соңрак имамлыгын ташлап Казан өязе ... [төп нөсхәдә шулай. – *Төз.*] авылында Сәйфулла бине Үтәгән мәдрәсәсенә барган. Ул зат Кызылъяр шәһәренә

күчеп киткәнгә күрә, Саба авылына Сәйфеддин бине Әбүбәкер әш-Шыңарый хозурына киткән. Анда күпмедер вакыт кичергәннән соң Бохарага барып унике ел укыган. Үз иленә кайткач, әүвәлге урынында имам һәм мөдәррис булган. Бохарада хәлифә Хөсәен хозурында тәрбияләнгән.

Шәкертләре: үзенең уллары Әхмәдҗан, Мөхәммәдсафи, Мөхәммәдһади; Мөхәммәдвәли бине Габдессәлам әл-Мәләкәси, Габелкәрим бине Улмазкол әс-Сәлҗүти, Фәрхеддин бине Фадлулла әл-Кызылбабый, Бәдреддин бине Вәйс бине Давыд әл-Акавый һәм башкалар.

Хатыны Сафия бинте Биктимер бине Мөслим булып, бүген Мөхәммәдсафи исемле улы сәламәт. Моннан вә башка балаларыннан оныклары күп. Бу кемсә хакында Гайнан бине Вильдан әт-Туймый: «Урта дәрәҗәдә гыйлеме бар иде, гомерен тәгълим белән уздырды. Башыннан аягына кадәр яхшы холык вә әдәп белән тулган иде», – ди.

Бу өч зат тәрҗемәсе игътибарсызлык сәбәбеннән беркадәр соңга калып язылды.

**335. Хуҗамбирде бине Сөенечбакый**

Себердә Тубыл шәһәреннән унбиш чакрым ераклыкта Саускан авылында 62 яшендә 1273 (1857) елның җөмадиел-ахир (гыйнвар) аенда вафат булды. Бохарада укып Әбү Габдулла Габделкадыйр бине Ниязәхмәд бине Сәфәрәхмәд әл-Фарукый хозурында тәрбияләнеп тарикатьтә рөхсәт алды. Гыйлем вә аңлылыгы, белеме гүзәл иде, диләр. Кыска төннәрдә ястү намазын уку фарыз түгел игътикадында булып гомер сөргәненнән соң, Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавыйның ястү намазы хакында булган фикерләрен күреп, үзенең хата // [267] юлда булганын аңлаган. Балигъ булган көненнән бирле калдырган ястү намазларын тулысынча каза кылып укыган. Дөрес юлга басуына сәбәп булганы өчен Курсавыйны һәрвакыт хәер белән искә алган, диләр.

Себердә кайбер шәкертләре авылларга имам булдылар, Бәшир исемле бер шәкерте укыту вазыйфасын башкарган.

**336. Низамеддин бине Сиражеддин бине Зәйнелгабидин бине Әбүшәхмә бине Габдерраззак бине Дустмөхәммәд бине әл-Мөхәммәд әл-Корычый**

1273 (1856) ел ахырында Бәгъдад шәһәрендә вафат булган дип уйлыйбыз. Асыллары Бәләбәй өязе Килкәбыз авылыннан булып, бабаларыннан берсе балалар укытып, абыз агай булып торыр өчен Коруч авылына килгән, сахибе тәрҗемә 1239 яки 1240 елда шунда дөньяга килгән. Туганнары арасында зирәклек белән шөһрәт казанган кемсә юк, диләр, ләкин анасы, үз дәрәҗәсенә күрә гыйлем иясе булып, күп төрки китапларын ятлаган, имеш. Анасы Мөнәввәрә бинте Габделвахид бине Сәлим бине Ишмөхәммәд булып, мәшһүр Гайнелкәмал бине Габделвахид вә Рауил бине Габделвахид белән бертуган иде. Корыч авылына иргә барганыннан соң шәех Габеллатыйф бине Сөбханкол әл-Корычый карамагына тапшырылып, шәех ханәсендә һәрвакыт авыр хезмәт башкарып йөргән. Монда килгән шәкертләрнең керләрен әҗер-фәләнсез, бәлки савап өчен генә юган, аларга икмәкләрне дә яшереп бирә торган булган, имеш.

Низамеддин дүрт яшенә җиткәнендә язу танып, Коръән шәрифне // [268] укый башлаган. Тугыз яшенә җиткәч, агасы Борһанеддин белән бергә Симәк авылында булган Шаһиәхмәд бине Рәфыйк мәдрәсәсендә булган абыйлары Гайнелкәмал бине Габделвахид янына барганнар. // [279]

**337. Гариф бине Сәламколый бине Фулад**

Низамеддин бине Сиражеддин әс-Сәлиминең сәфәрендә вә укуында иптәше булып, аның белән берлектә 1273 (1856) елда вафат булган дип уйлыйм. Асылы Эстәрлетамак өязе Сәйран авылыннан иде. Шул якларда булган остазы Шәрәфеддин // [280] бине Зәйнеддин әл-Эстәрли булып, аның мәдрәсәсеннән чыгып Бохарага сәфәр итте. Әфганстандагы Һират шәһәреннән соң булган хәле караңгыдыр.

**338. Максуд бине Корбангали бине Әднакол бине Мәскәү**

Казан өязе Күлбаш авылында 105 яшендә 1274 (1857) елның сәфәр аенда вафат булды. Асылы Казан ягындагы Хәерби авылыннан иде. Берлектә дүрт хатыны

булганыннан балалары бик күп булып, Казан тарафындагы Максуд фамилиясе бу затка бәйле. Унике яшендә укый башлап, кырык яшенә кадәр Казанда вә шул тарафларда укыган. Төрле авылларда укыту белән дә мәшгуль булган, диләр. «Рисалә-и Күлбашы» исемле мөстәкыйль бер әсәре барлыгы турында риваять кылына.

Казан шәһәрендә «Йолдыз» газетасын оештырган, гарәпчә һәм төркичә әсәрләр язган Әхмәдһади әфәнде бине Низамеддин шушы затның туганы.

### 339. Әбүбәкер бине Җәгъфәр бине Ягъкуб бине Әднәкол әл-Әгерҗеви

Сарапул өязе Әгерҗе авылында имам вә ахун булып // [282] 76 яшендә 1274 (1858) елның рәҗәбендә вафат булды. Гайнелхәят исемле кызы Фәхреддин ишан бине Мостафа никахында иде.

Остазлары: Габид бине Габделгазиз әл-Кенәри, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни.

### 340. Сабит бине Сәгыйдь бине Салих

Спас өязе Урта Тигәнәле авылында имам булып, 80 яшендә 1274 (1858) елның 19 рамазанында (2 апрель) вафат булды. Җәмгыяте шәргыя әгъзасы иде. 1817-1818 елларда имзалаган кәгазьләрне күрдем. Габделгафур бине Габделмәннан һәм башкалар хозурында укыганлыгы риваять кылына. Асыллары Лаеш өязе Әшнәк авылыннан булып, Сәгыйдь бине Салих кабере шунда. Мәдрәсәдән чыккач, Казан өязе Кенәр авылында имам булган, шул вакыт имамнар тарафыннан сайланып, Уфа шәһәренә Җәмгыяте шәргыядә хезмәт өчен киткән. Хезмәтеннән чыккач, Урта Тигәнәлегә имам булып билгеләнгән. Соңрак үз вазыйфасын Ногман исемле улына калдырып, имамлыктан читләшкән. Соңыннан Ногманны икенче мәхәллә имамлыгына күчереп, үзенең әүвәлге урынында кабат имам булган. Ләкин озак яшәмичә, вафат булган.

Балалары: Ногман, Гыйрфан, Шәрәфеддин, Биби, Җансылу. Ногман 76 яшендә 1308 (1891) елда вафат булды. Укуы Сәрдә авылында Госман хаҗи бине Рәхмәтулла хозурында иде, балалары бар. Гыйрфан исә югалды. Шәрәфеддин // [290] белән

Җансылу сахибе тәрҗемәнең үзеннән алда вафат булдылар.

### 341. Хөсәен Әбүшшәрәф бине Мөхәммәд бине Гомәр әс-Сагыйди әл-Кирмәни

1274/1858 ел шәгъбанында Бохарада вафат булды. Остазлары: Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади, Бохарада Габделгазиз бине Габделгани әл-Бохарый һәм башкалар. Асылы Кирмәннән булып, кайбер бабалары Сәгыйдь бистәсенә күчеп киткәнгә күрә, бу кемсә шул бистәдә дөньяга килгән. Соңрак Бохарага барып беркадәр вакыт шунда эшләде, шунда ук өйләнде, балалары туды.

### 342. Исмәгыйль бине Габдеррахман бине Габдулла әт-Тингәни

Сими [Семипалат] шәһәреннән Казанга килгән вакытта Бөре өязе Байкыйбаш авылында 1274 (1858) елның рамазанында вафат булды. Җеназасын исә авыл имамы Низамеддин Фәйзулла улы укыды. Асылы Кытай мәмләкәтендәге дунган кавеменнән // [298] иде. Күп мәртәбә хаҗ сәфәрендә булып, беркадәр вакыт Истанбулда да торды. Казанга килгәч, Мәскәү имамы Сәйфелмөлек бине Әсхаб исемле кемсәнең Бәдигыльҗәмал исемле кызына никахланды. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани дә язган.

### 343. Габделхаликъ бине Габделмәҗид бине Ибраһим

Эстәрлетамак шәһәрендә 88 яшендә 1274 (1858) елның 4 зөлхиҗҗәсендә вафат булды. Шәһәрнең икенче каберлегендә үзе төзегән таш ихата эчендә шәех Шәрәфеддин бине Зәйнеддин янында күмелгән. Өстендә ташы вә язуы юк. Асылы Ашкадар суы буендагы Өч Бүлек авылыннан иде. Әүвәлге хатынының хәле мәгълүм түгел, икенче хатыны Эстәрлебаш авылыннан Габдулла бине Биктимер әл-Тукайи кызы Хәбибә иде. Ул, 1294 (1878) елның 1 шәүвәлендә (27 сентябрь) вафат булып, ире янында күмелде.

Балалары: Хәсән, Габдулла, Зөләйха, Зәһрә, Мәхбүбә, Мәрзыя, Гобәйдә. Хәсән ... [төп нөсхәдә шулай. – *Төз.*] елларда вафат булды. Ир баласы булмады, бүген бер

кызы сәламәт, // [299] тормышы да тар иде. Габдулла 62 яшендә 1891 елда вафат булды. Моның хатыны Бәхтияр бине Габделкәрим әр-Рәмиви кызы Садрекәмал иде. Габдеррахман, Мәхбүбҗәмал исемле балалары булып, Мәхбүбҗәмал бүген Уфа шәһәрендә мөдәррис вә ахун Хәйрулла бине Госман никахында. Габдеррахман исә 1298 (1881) елларда вафат булды, Габдеррәхим исемле улы һәм Хәнифә исемле кызы калды. Габделхаликъ байның ир балалары тарафыннан булган варисы ялгыз шушы Габдеррәхим бине Габдеррахман булып, бүген сәламәт һәм дә Габделхаликъ байдан калган байлыктан һаман файдаланып тора. Габдеррахман яхшы мәгыйшәт итте, дөньясы иркен иде.

Зөләйха Эстәрлетамак шәһәрендә имам вә ахун Кәмаледдин бине Шәрәфеддин никахында булып, бер генә ел торып вафат булды. Зәһрә исемле кызы Эстәрлебаш авылында шәех Мөхәммәдхирас бине Нигъмәтулла никахында булып, Лотфулла исемле бер улы вә Өммерәбига исемле бер кызы калды. Болардан башка кызларыннан берсе Бозаяз авылында Шаһибәк кантон вә берсе Җанбәк авылында Әбүннәгыйм исемле кемсә никахында булганы риваять кылына. Кызлары күбесенчә кыска гомерле булдылар.

Габделхаликъ байның укый вә яза белмәве турында сөйләнсә дә, китапларының берсендә булган «Ибраһим бабай, Илкә бабай, Кадери бабай, Русай бабай, Мәрҗан бабай, Карлыгач би, Кармыш би, Канкарыш би, Карахуҗа би. Болар бары тугыз бабай мәрхүм. Язылды 4 март 1834 ел» дигән язманы үз кулы белән язган дип уйлыйбыз. Ничек кенә булса да, беркадәр яза белгәне күренәдер.

Габделхаликъ бай шушы тарафта абруйлы сәүдәгәрләрдән берсе булып, // [300] байлыгы бакыр хисабына йөз мең сумнан артык булмаса да, гаять сак вә уртачыл дөнья көткәненә күрә, байлыгы бик бәрәкәтле булган, имеш. Адәмчелек вә шәригать юлында Аллаһ ризалыгы өчен мал сарыф итүдә зур ләззәт тапкан, диләр. Эстәрлетамак шәһәрендә беренче мәхәлләдә таш мәчет, таш мәдрәсә, таһарәтханә вә ашханә, кое вә шулар өчен вакыфлар – барысы да моның хәйрия малыннан. Эстәрлетамак вә Эстәрлебаш мәдрәсәләрендә булган шәкертләр файдасына вакыф иткән китаплары хисапсыз дип әйтсәк, арттыру булмас. //[309]

**344. Габдессәлам бине Габделваһһаб бине Мортаза бине Нурмөхәммәд**

Казан шәһәрендә Бишбалта мәхәлләсендә имам булып, // [310] 1275 (1858) елның сәфәр аенда вафат булды. Ибраһим әфәнде бине Хуҗашның өченче хатыны Хөсни моның белән бертуган иде. Атасы Габделваһһаб шул мәчет хозурында имам булып, 1229/1814 ел ахырында вафат булды.

**345. Гыйсмәтулла бине Рәфыйк бине Мөслим бине Килмәт**

Златоуст өязе Яңа Мөслим авылында имам булып, 1275 (1858) елның сәфәр аенда (4 сентябрь) вафат булды.

Уллары: Сөнгатулла, Гыйззәтулла, Җарулла, Носратулла, Хәлим, Тәкыйулла һәм башкалар. Атасы Рәфыйк тә голямадан булып, мәдрәсә тоткан, тирә-яктагы шактый имамнарны укыткан.

**346. Мөхәммәдвафа бине Гобәйдулла**

Бөгелмә өязе Бикәш авылында имам булып, 68 яшендә 1275 (1859) елның җөмадиел-ахирендә (21 гыйнвар) вафат булды.

Остазлары: Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви, Әхмәдҗан бине Әмирхан әл-Ушмавый һәм башкалар. Күп еллар дәрес укытса да, кеше күзенә күренерлек шәкерте булмады. 1821 елның 11ноябрендә имамлык өчен указ алганын үзе язган бер кәгазьдә күрдем. // [311]

**347. Хаҗи Гали бине Әбүбәкер бине Кинҗәгали.**

Әстерхан ягындагы Сәед авылында имам булып, 1275 (1859) ел рәҗәбендә (9 февраль) вафат булды. Вәлиэддин бине Хөснеддин әл-Бәгъдади хозурында укып, кыйраәт гыйлемен гүзәл рәвештә үзләштергән. Шәехе 1230 елның 12 шәүвәлендә аңа иҗазәт биргән. Әстерхан якларында булган имамнарның күбесенә кыйраәт гыйлемен өйрәткән. Муса, Корбангази исемле уллары калды. Муса 1276 ел ахырында баласыз вафат булды. Корбангази 84 яшендә 1315 елның зөлкагдә аенда вафат. Каберләре Сәед авылында.

**348. Габделвәли бине Габдеррәхим бине Шәриф бине Мөслим бине әл-Мөхәммәд**

Казан ягындагы Норма авылында имам булып, 56 яшендә 1275 (1859) елның шәгъбанында (1 март) кинәт вафат булды. Мөхәммәдзариф, Мөхәммәдшәриф, Мөхәммәдзакир исемле уллары калды. Моның вафатыннан соң Гатаулла бине Мөхәммәд әл-Курсавый имам булса да, аз заман торып, Курса авылына күчеп китте. Асыллары Казан өязе Наласа авылыннан булып, Лаеш ягы Мәтәскә авылында дөньяга килгән. Башта Мамадыш өязе Мичәнбаш авылында имам булып, соңрак, казый Мөхәммәделәмин бине Мөхсин картайгач, аның урынына Нормага күчте. Атасы Габдеррәхим Мәтәскәдә, абыйсы Фазлулла // [312] бине Габдеррәхим Мичәнбаш авылында имам булып, вафат киттеләр. Бу кемсә хакында Сөләйман бине Давыд әс-Саснавый: «Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый хәзрәтләренең бөек шәкертләреннән саналып, фикъһ вә динне белүе белән мәшһүр иде. Мәчкәрә мәдрәсәсендә вакытында Исмәгыйль бине Муса әл-Кышкарый шушы заттан укыган иде», – ди.

**349. Габдулла бине Яхъя бине Мәхмүд бине Максуд бине Сөләйман әл-Чиртушый**

Малмыж өязе Мәчкәрә авылында имам вә мөдәррис булып, 85 яшендә 1275 (1859) ел шәгъбанында вафат булды. Хатыны Рәбига Мөхәммәдрәхим ахун бине Йосыф әл-Ашытый кызы иде. Һади, Зыяэддин, Фатыйма исемле балалары калды. Фатыйма шәкерте Мөхлисулла бине Максуд әс-Сәгыйди никахында булды, Зыяэддиннең Сәгъдеддин исемле улы Янсыбы авылында имам иде. Һади исемле улының да балалары бар. Вафатыннан соң васыяте таләбенчә Мәчкәрә авылыннан Кәмаледдин бине Сөләйман исемле кеше хаҗ кылды. Моның өчен алты йөз тәңкәлек мал билгеләп калдырган булса да, вафаты соңында өч йөз тәңкәсе исраф булганга күрә, шәех Гали бине Сәйфулла әт-Түнтәри үз кесәсеннән өч йөз тәңкә кушты.

Остазлары: Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый, Салих бине Сәгыйдь әл-Кили, Сәйфеддин бине Үтәгән әс-Сәрдәви, Бохарада Габдеррахман бине ... [төп нөсхәдә шулай. – *Төз.* ] әл-Әгъләм һәм башкалар.

Шәкертләре: Габделвәли бине Габдеррәхимән-Нормавый, Габбас бине Гомәр

бине Нәүрүз әд-Дустәми, Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим әт-Тәкәнеши, Гайнеддин бине // [313] Зәйнелбәшәр бине Нәзир әт-Түнтәри, Исмәгыйль бине Муса әл-Кышкарый, Хәсән бине Хәмид әл-Курсавый, Габделҗаббар бине Мөстәкыйм әл-Кайбычый, Нигъмәтулла бине Мөнасиб әл-Бубый, Галибай бине Ярмөхәммәд әл-Чалпывый, Хисамеддин бине Габделкәрим әт-Таупазый, Мөхәммәдзакир бине Габделваһһаб әс-Саснавый, Габдулла бине Габделгафур әл-Чакмакый, Зыяэддин бине Габделҗаббар әл-Кайбычый, Исхак бине Мәхмүд әс-Сәгыйди, Мөхлисулла бине Максуд әс-Сәгыйди, Зияэддин бине Җәлаледдин әш-Шыгайи, Солтанбәк бине Сагындык әл-Бигеши һәм башкалар. // [319]

Габдулла хәзрәтнең асылы Чистай өязе Чиртуш авылыннан булып, соңрак ни сәбәпледер Оренбург өязе Ырысткол авылына башкорт буларак язылган.

## 350. Низамеддин бине Вәйс бине Хуҗамколы

Пермь ягы Саз авылында имам вә мөхтәсиб булып, 63 яшендә 1275 (1859) елның шәгъбан аенда вафат булды. Әхмәдшакир исемле улы калды. Остазы Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый иде. Утыз елдан артык укыту белән мәшгуль булды, күп шәкерт җыйды, үзе галим вә шәригать белгече иде, диләр.

## 351. Миңлебай бине Габдеррәшид бине Йосыф

Казан шәһәрендә Ибне Әхмәд дип билгеле булган сәүдәгәрләрдән булып, 1275/1859 елда вафат булды. Казан шәһәрендә мөселманнарның аерым Ратуша мәхкәмәсенә Ибраһим бине Гобәйдулла бине Мөхәммәдрәхим әл-Юнысыйдан соң 1261 елда мөселманнар тарафыннан сайланып, Ратуша ачылганнан башлап аның сигезенче рәисе булды. Зур тәнле, авыр табигатьле бер кеше булса да, үзенә лаек сурәттә аңы, аек акылы бар иде, диләр. Олы улы Мортаза, 1289 елның 2 нче зөлкагдәсендә 45 // [320] яшендә вафат булып, Казан каберлегендә күмелгән. Маһкәмал бинте Хөсәен бине Йосыф бине Мөхәммәд исемле хатыныннан бер улы калып, тугач Габдулла исеме кушканнар, ул биш яшендә вафат булган. Бу улыннан башка тагын бер кызы калган.

Күпчелек сәүдәсе Бөгелмә өязендә булып, Кичүчат, Габдеррахман, Тайсуган авылларында булган мәчетләрне төзеткән. Моннан башка Тайсуганда булган мәдрәсәләре тулысынча үз кесәсеннән төзелгән. Түбән Шәлчәле авылында да бер мәдрәсәсе бар иде. Вафатында алтмыш мең тәңкә акчасын хәйриягә сарыф өчен васыять итеп, каенатасы Исхак бине Йосыф бине Исмәгыйль белән улы Габделкәрим бине Исхакны моның өчен җаваплы иткән. Шул исәптән Казан вилаятеннән барган мосафирлар өчен махсус Истанбулда бер тәкия алырга дүрт мең тәңкә билгеләгән. Ул 1294 елда алынып, Бәһаведдин исемле кемсә шунда караучы булып билгеләнгән.

### 352. Хәбибулла бине Рәфыйк бине Мәхмүд бине Мөслим

Бөгелмә өязе Зәй елгасы буендагы Нәдер авылында имам вә мөдәррис булып, 82 яшендә 1276 (1859) елның рабигыль-әүвәл аенда вафат булды. Баласы күп калганнан, бүген балалары, оныклары төрле җирләргә таралган. Күп кешеләр хозурында укыган булса да, камиллеккә ирешкәненең сәбәбе булган кеше – остазы Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавый иде.

### 353. Мифтахеддин бине Сәлимҗәүһәр бине Сөбханкол әл-Калмашый

Бәләбәй өязе Калмаш авылында имам вә мөдәррис булып, 65 яшендә 1276/1860 елның рәҗәбендә вафат булды.

Остазлары: Фәйз бине Габделгазиз әл-Кенәри, Әбүбәкер бине Йосыф әл-Җәбәли, Әмирхан бине Габделмәннан әт-Талкышый.

Тирә-яктагы күп затлар аннан укыганнар. Югары Сәед авылында ахун Таһир бине Фәтхулла моның шәкерте иде.

### 354. Әхмәд бине Мөхәммәд бине Габдеррәззак бине Ишмөхәммәд бине Тими

Сими шәһәренең икенче мәчетендә имам булып, Тара шәһәрендә кияве Рәхмәтулла бине Нияз хаҗи Айтикин ханәсендә кунак булып торганда 1276 (1860) ел шәгъбанында вафат булды. Кабере шунда. Хәдичә исемле кызы шул Рәхмәтулла бине Нияз никахында иде. Үзеннән соң Ибраһим исемле улы икенче мәчеттә имам вә ахун

булды. Әхмәд ишан Бохарадан кайтып башта Сими шәһәренең беренче мәчетендә имам булып, соңында икенче мәчеткә күчеп ахун булды. Тарикатьтә рөхсәт алып, мөрид тәрбияли иде. Хаҗ сәфәренә күп мәртәбә йөреп, Казан шәһәренә дә еш килгән. Дәрес бирмәде, байлык вә игътибарда озын гомер кичерде. Шөһрәте дә җирендә иде, диләр.

Остазлары: Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгьдади, Вәлид бине Мөхәммәделәмин әс-Сәгыйди, Бохарада хәлифә Хөсәен бине Йосыф һәм башкалар. Анасы Сәгыйдә Чутай Габделгазиз дип билгеле булган Габделгазиз бине Туктамыш бине Бураш кызы. Габделгазиз исә Казанда гарәби хәрефле матбугат ачылгач, Коръән вә китап бастырып кәсеп кылган кеше иде.

Бабасы Габдеррәззак югарыда телгә алынды. Атасы Мөхәммәд бераз вакыт Казан шәһәренең // [327] дүртенче мәчетендә имам булып торгач, урыныннан чыгып, Яңа бистәдә көн кичерде. 1236 ел ахырында Казанда вафат булды.

### 355. Габделҗәмил бине Үтәкол

Эстәрлетамак өязе Үтәк авылында имам вә мөдәррис булып, 66 яшендә 1276/1860 елның шәүвәлендә вафат булды. Үзенә дәвамчы булырлык баласы калмады. Остазы Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви иде. Шәкерт вә укучылары күп иде, диләр. Ахун Мөхәммәдшафигъ бине Мөхәммәдшәриф моның шәкертләреннән, имеш. Асыллары Мамадыш өязе Купка авылыннан булып, бабалары шуннан китеп Эстәрлетамак өязе Ялгыз Каен авылында торганнар. Сахибе тәрҗемә Үтәк авылында мәдрәсә ачып шәкерт җыйды. Ләкин остазы Үргәнчкә киткәч, бу кемсә, шәкерт вә хатыннарын монда ташлап, үзе дә остазы артыннан Үргәнчкә китте. Анда исә остазы хозурында дүрт ел торып, рөхсәт алгач кабат Үтәк авылында имам булып шәкерт җыйды. Мөрид җыеп шәехлек итте. Бу кемсә хакында Хәбибеннәҗҗар бине Габделкафи әл-Үтәки: «Галим, диндар бер зат иде. Язуы гүзәл вә рәсеме дөрес булды. Үзенә алмаш булырлык варисы калмаганга, Балыклы Күл авылы ахуны Хөснеддин бине Шәмседдин мәдрәсәсендә пишкадәм булган Габделкафи бине Котлыгзаман килеп, имам вә мәдрәсәләренә мөдәррис булды. Бу зат та 66 яшендә 1314 елның рабигыль-әүвәл аенда вафат булды», – ди. // [329]

**356. Нурмөхәммәд бине Ибраһим бине Хуҗаш**

Казан шәһәрендә мөхтәсиб булып, 75 яшьләрендә 1276 (1860) елның зөлкагдә аенда вафат булды. Кабере Казан каберлегендә. Фәхреддин, Зыяэддин исемле уллары калды. Гыйлеме аз булса да, мөхтәсиблек дәрәҗәсен алды, бөек шөгыле сәүдә иде, диләр.

**357. Мөхәммәдҗан бине Мәхмүд бине Максуд бине Габдулла**

Әй суы буенда Туймы авылында 80 яшендә 1277 (1860) елның 1 җөмадиел-әүвәлдә (3 ноябрь) вафат булды. Зөһед вә тәкъвалыгы белән билгеле булган кешеләрдән берсе. Дөньясы тар булса да, канәгате тулы, сөннәт белән эш кыла иде, сүзе ләззәтле, нәсыйхәтләре тәэсирле, үзе саф күңелле бер зат иде, диләр. Вафат булырым яки вакытында тапшыра алмыйча күңел кырырмын дип курку сәбәпле, никадәр мохтаҗ булса да, бирергә әзер торучылар булса да, бурыч сорамас вә һич алмас иде. Үз авылының халкы имамлыкка билгеләп, аңа ант китергән булса да, остазы вә шәехе Котлыгәхмәд бине Габделмәннан әд-Дустымый: «Имам булсаң, ач күзлелеккә дучар булырсың, шөбһә вә мәкруһлардан саклана алмассың, тугры вә хак сүз сөйләргә батырчылык итмәссең, ихтимал ки, ялагайлану вә икейөзлелек белән күңелеңне бозарсың, шул сәбәпле синең өчен бу имамлык дәрәҗәсен мин муафикъ күрмим», – дип киңәш биргәнгә, бу мәхәллә әһеленең сүзен кире какты. Халык арасында торган // [332] хәлдә ялгызлыкка бирелеп яшәде, дөнья вә андагы хәлләрдә эше булмады. Ләкин гаиләсен ризыкландыру кирәклегеннән, хезмәтче тотмыйча бар хезмәтне үзе башкарыр. Тәһәҗҗүд намазын укып, догаларын тәмамлаганнан соң өч ат җигеп урманга китәр, аннан утын төяп кайтып иртә намазына барыр. Аннан ишрак вә духа намазларын укып өенә кайтыр. Үзе сабан сөрер, үзе чәчәр, вакыт җиткәч урып сугар. Кул тегермәнендә кулы белән тартып үзе пешерер. Йә китап өйрәнер, йә язар, йә укытыр вә яки дөнья эше белән мәшгуль булыр. Кыш көне кырга яки сәфәргә чыкканында балтасын алыр, әгәр дә вакыт җитсә, очраган суның бозын ватып таһарәт алыр, шунда ук намазын кар өстендә укыр, имеш.

Безнең динебез иркен, һичкемгә мәшәкать юк дип, карсак вә тиен туннар эчендә йомшарып намаз укучылар вә мәчеттән кайтуларына хатыннары тарафыннан

әзерләнгән чәй вә май ашлары янында «Һе! Һе!» дип, иркәләнеп, Җүнәйд вә Шибли кебек галимнәрнең мактаулы сыйфатларын сөйләп ишанлык итүчеләр дә аз түгел. Аллаһы Тәгалә ни кебек гамәлләрне вә кемнәрнең хезмәтләрен кабул итәчәгенә безнең зиһенебез җитмәс, ләкин ни өчендер күңелләр тел белән түгел, бәлки гамәл белән ишанлык күрсәткәннәр тарафына тарта. Шәригать тышында булган юллар белән нәфесне азаплау ярамаса да, тормыш кирәкләре булган хезмәтләрне үзеңә-үзең башкару Җүнәйд вә Шибли кебекләрнең ишанлыгына каршы да түгелдер.

Остазы Сәгъди бине Максуд әт-Туймый булып, хатыны Гөлхәйран бинте Шаһиәхмәд иде.

Балалары: Гыйрфан, Шаһиәхмәд, Мөхәммәдзакир, Гатаулла.

// [333]

**358. Мөхәммәдйосыф бине Әхмәр әл-Исәки**

Вафат булган вакыты билгеле түгел. Язуыбыз шушы урынга җиткәндә, борадәребез Мөхәммәдзәки әфәнде әл-Исәки тарафыннан язылган тәрҗемәи хәлен бу җирдә китерәбез. Мөхәммәдзәки әфәнде яза: «Мөхәммәдйосыф ишан, Бохарада укып, 1223/1808 ел ахырында Тәтеш өязе Исәк авылына кайткан. Бу кайтуында мәдрәсәдә укыткан булса да, шәкертләре калмаганга, хәлләре тиешлечә беленми. Моннан соң тагын Бохарага сәфәр иткән. Күпмедер анда торып, 1235/1820 ел ахырында тагын Исәк авылына кайтып, мәдрәсә оештырып шәкерт укыткан. 1838 елда Исмәгыйль исемле улын үзе белән алып, кабат Бохарага сәфәр кылган. Анда Каршы исемле шәһәргә барып, урнашып калган. Җәлаледдин бине Әдһәм әт-Тәкәнеши боларга дус булып, алар белән бергә киткән. Исмәгыйль исемле улы башта Бохарада торган имеш, әдәпсез булганына күрә, Исәк авылында бүгенгә кадәр начар исеме бар. Мөхәммәдйосыф ишан мәдрәсәсендә күп шәкерт җыелган, хәтта ки Коръән шәрифне өйрәнер өчен чит мәдрәсәләрдән шәкертләр килгән, диләр. Тарикатьтә булган остазы – Мөхәммәд Ниязколый әт-Төрекмәни. Исәк авылында торган вакытта никах мәҗлесеннән башка мәҗлесләргә бармаган, анда да фәкать җомга көне булса гына барыр, имеш. Иртә вә ястү намазларын гомере буенча мәчеттә укыр иде. Бер күзе сукыр иде, диләр. Шаһиәхмәд ишан әл-Чирмешәни вә дамелла Габденнасыйр әл-

Буавый моның шәкертләреннән булып, Габденнасыйр // [334] әл-Буавый аның хозурында «Әнмүзәҗ», «Мифтах», «Мохтасар әл-Викая» китапларын укыган. Мөхәммәдйосыф ишанның соң көннәрендә безнең бабабыз Хәбибулла бине Габдеррәхим Сәрдә авылында укып кайтканында, тәфсир вә хәдистән башка дәресләрне аңа тапшырып, үзе тәфсир белән хәдис дәресләрен генә укыткан. Йосыф хәзрәт Бохарадан кайткан вакыт абыйсы Ягъкуб байның куәтле вакытлары булганга, мәдрәсәләре төзек булган, бу сәбәптән ишан рәхәтләнеп шәкерт тәрбия кылган, әмма соңрак байның дөньялары бозылып, көч-куәтләре зәгыйфьләнгәнгә күрә, Йосыф ишан Бохарага киткән. Аның Бохарага киткәннән соңгы хәлләре караңгы. Шушы кадәр мәгълүматны да Чирмешәндә шәехлек иткән вә Йосыф ишанның бик сөекле шәкерте, туксан яшендә булган Шаһиәхмәд бине Габбастан файдаланып язып алдым». Мөхәммәдзәки әфәнденең хаты шушының белән тәмам. Кайбер вак нәрсәләр үзгәртелеп, кыскартылды.

### 359. Давыд бине Җәгъфәр бине Биккинә бине Сөбхан

Казан шәһәрендә 1277 (1860) елның 29 җөмадиел-әүвәлдә вафат булды. Галим булмаса да, гаять аңлы, фикер иясе булганы риваять кылына. Анасы Зәһрә бинте Габделгазиз бине Туктамыш булганга күрә, Сими Әхмәд ишан белән туган иделәр.

Балалары: Габдулла әл-Мортаза, Габдеррахман әл-Мостафа, Фатыйха.

### 360. Мөхәммәдзариф бине Габделҗәмил бине Фәйзулла бине Бикмөхәммәд

Троицки шәһәрендә имам вә мөдәррис булып, 75 яшендә 1277 (1861) елның рәҗәбендә (3 гыйнвар) вафат булды. Анасы – Хәнифә бинте Габдулла әл-Ахун әл-Уралый, хатыны хаҗи Фазыл бине Ибраһим әл-Әлмәни әл-Эчкени кызы Галимә исемле иде. Үз илендә галимнәрдән белем алганнан соң Бохарага барган, анда хәлифә Хөсәен бине Йосыф һәм башкалардан укыган. Чиләбе якларында булган күп имамнар моның шәкертләре булган. Мөхәммәд исемле улы бүген Троицки шәһәрендә беренче мәчеттә имам вә мөдәррис, сәламәт.

**361. Сәйфеддин бине Сөбханкол бине Бикмөхәммәд**

Атасы Сөбханкол вә абыйсы Фәхреддин турында инде яздык. Бөгелмә өязе Кичүчат авылында имам булып, 83 яшендә 1277 (1861) елның рәҗәбендә (23 гыйнвар) вафат булды. Кабере Кичүчат зиратында булып, өстендә ташы, вә шунда вафат булган көне язылган. Анасы Сахибә бинте Каракай иде.

Остазлары: Габдеррәшид бине Мөхәммәд әш-Шөгери, Әмирхан бине Кучкар әл-Үтәки, Таҗеддин бине Габдеррәшид әл-Иштирәки, Таһир бине Сөбхан әл-Адайи һәм башкалар. Җәмгыяте шәргыя ачылганнан соң дүртенче кемсә булып имтихан тотты, 1791 елның 2 июлендә указ алды. Мәдрәсә тотып дәрес бирмәсә дә, һәрвакыт гыйлем әһелләре белән аралаша иде, һәрвакыт мәгълүмат туплау, белем алуда тырышлык күрсәтә иде. 1240/1865 елда хатыны Хәдичә бинте Габделмәннан, кызы Садыйка вә кияве Хәбиберрахман // [336] бине Мәхмүд, улы Фәхреддин вә хезмәтчесе Кәлимулланы ияртеп җәй көнендә Биләргә, аннан Болгарга барып, бабаларыбыз калдырган мирасны зиярәт итте. // [338]

**362. Ибраһим бине Мөхәммәдрәхим бине Колыш бине Солтанбәк**

Златоуст өязе Үзән суы буендагы Иделбай авылында имам вә мөдәррис булып, 78 яшендә 1277 (1861) елның шәүвәл ае ахырында (31 март) вафат булды.

Остазлары: Сәгъди бине Максуд әт-Туймый, Әхмәр бине әл-Казанчы, Ягъкуб бине Җәгъфәр әт-Төбъязый әл-Кышкарый.

// [339]

Шәкертләре: Солтангали бине Әхтәм әл-Мәхмүди, Зәйнеддин бине Соракол әс-Сөләйманый, Габделгалим бине Габделмән әс-Сәлҗутый һәм башкалар.

Хатыны Мамадыш өязе Саба авылыннан Хөббенниса исемле булып, балалары Мәүсуфа, Мәстүрә, Гарифә. Әүвәлге ике кызына сарыф вә нәхү [грамматика] укытканы риваять кылына.

**363. Нурулла бине Габдулла бине Баһадир**

Тара өязе Затлы Хан авылында имам булып, 70 яшендә 1277 (1861) елда вафат

булды. Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри шәкертләреннән бер галим кемсә буладыр. Ләкин гыйлем вә тәүфикъ һәм дә намуслылыгыннан балаларына бернәрсә дә мирас итеп калмады, диләр.

**364. Исмәгыйль бине Таһир бине Нәзир бине Туктамыш бине Мөслим**

Цивил өязе Яңа Әҗем авылында имам булып 1277/1861 ел ахырында вафат булды. Ибраһим исемле улы үзенә иптәш имам булса да, үзеннән алда вафат китте. Аннан соң икенче улы Әмирхан имам булды. Асылы Түбән Оры авылыннан булып, мәшһүр сәүдәгәр Габделмөэмин бине Таһир бине Нәзир белән бертуган иде. 1251 елда Җәмгыяте шәргыягә әгъза булып, Уфа шәһәренә китте. 1831, 1833, 1835, 1838 елларда имзалаган кәгазьләрне күрдем.

**365. Габделмөэмин бине Фәйз бине Әхмәр**

Мамадыш өязе Мишәбашы авылында имам булып, 1278/1861 елда вафат булды. Остазы Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавый иде. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Гасырдашлары карашында галим саналмаса да, мәртәбәсе аларның барысыннан да зур иде. Әбеннасыйр әсәрләреннән кайбер нәрсәләре, аны җәберләүләр хакында байтак мәгълүматы бар иде», – дигән.

// [344]

## УНӨЧЕНЧЕ КИСӘК

## ۱۳ نچی جزء

### 366. Шәмседдин бине Мөхәммәдъяр әл-Пәрәви

Лаеш өязе Пәрәү авылында имам булып, 1278 (1862) ел шәгъбанында 80 яшендә вафат булды. Унбер яки унике яшьләрендә, уйнап йөргән вакытларында, атасы белән бергә Хиҗазга сәфәр итеп, хаҗ кылды. Шушы сәфәрдә атасы вафат булып, ялгызы гына ничә еллар йөргәннән соң үз иленә сәламәт кайтып җитте. Казан шәһәренә барып гыйлем туплаганнан соң Пәрәү авылына имам булды. Вафатында Әхмәд, Хәсән исемле уллары калды. Хатыны Җарулла бине Бикмөхәммәд бине Тәймур әл-Әшнәки белән бертуган була. Бу кемсә хакында Хуҗаҗан бине Җарулла: «Зирәк, зиһенле, галим иде. Дөньяда хәлләрен, кеше белән аралашу тәртибен гүзәл белер иде. Акыл вә аңы гаять зур иде. Тарикатьтә шәех Фәйзхан бине Хозырхан әл-Кабули силсиләсенә мөнәсәбәтле иде. Атабыз хәзрәтләрен һәрвакыт: «Гомереңне кәлям әһеле карашлары юлында әрәм иттең! – дип шелтәләр иде», – дип әйтә.

### 367. Сәгъдеддин бине Фәйзулла бине Үтәш

Казан шәһәрендә Печән базары мәчетендә имам булып, 1278 (1862) елның 1 шәүвәлендә (20 февраль) вафат булды. Асылы Саратов ягындагы Мастак авылыннан иде. Казанда имам булганына күрә монда аның турында яздык.

### 368. Фәхреддин бине Мостафа бине Рамазан бине Нияз

1278/1862 елда 64 яшендә Мәдинә шәһәрендә // [345] вафат булып, Җәннәт бәкыйгъда җирләнде. Әхмәд, Мөхәммәд, Әхмәдясәви, Хәсәнбасрый исемле уллары калды. Тифлис Идарәи шәргыя исламиясендә мөфти булган Таҗеддин бине Мостафа әл-Әшнәки белән бертуган иде.

Остазлары: Габделгаффар бине Сәгыйдь әл-Казаный, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый. Насреддин бине Зәйниш әл-Калмакый хәләкасендә тәрбияләнеп, рөхсәт алган. Лаеш өязе Кече Әшнәк авылында дөньяга килеп, Сарапул өязе Әгерҗе авылында имам вә мөдәррис булып дөнья кичерде. Динилеге, мәгърифәте, яхшылыгы белән билгеле иде, диләр. // [348]

**369. Сабит бине Габдри бине Габбас бине Исмәгыйль**

Зөя өязе Нурлат авылында имам булып, 1279 (1862) елның 155 зөлхиҗҗәсендә (1 июнь) вафат булды. Яше 67 иде.

Уллары: Җәлаледдин, Җәмаледдин. Җәмгыяте шәргыядә әгъза булып хезмәт итте. 1830, 1831, 1845 елларда имзалаган кәгазьләрне күрдем.

Идарәи шәргыядә әгъза булып торган вакытында мөфти тарафыннанмы яки Собрание тарафыннанмы Троицки вә Чиләбе якларына җибәрелгән булганын риваять кылалар.

**370. Габделвахид бине Сөләйман бине Сәгълүк бине Габделхаликъ**

Җәмгыяте шәргыя Оренбургиядә өченче мөфти булып, 76 яшендә 1279 (1862) елның 19 сәфәрендә (4 август) вафат булды. Кабере Уфа зиратында, ишектән кергәндә уң тарафта, казанлы сәүдәгәр Ибраһим бине Исхак (бу кемсә 57 яшендә 1888 елда вафат булган) исемле кемсәнең баш очында. Каберендә ихата вә рәшәткә юк. Баш очындагы ташында «Әл-мәрхүм әл-мәдфүн Оренбург мөфти әл-ислам тархан Габделвахид Сөләйманов 76 яшендә дар әл-бакыйга рихләт итте...» дип язылган. Вафат булган вакыты туфрак астында калган, булса кирәк. Хасталыгы сәбәпле 1862 елның 2 августында Собраниега кәгазь язып мөфтилек хезмәтен старший заседатель булган Таҗеддин бине Максудка тапшырган.

Асылы Нижгар вилаяте Ырбишча исемле авылдан булып, Сөләйман исемле бер ахун улы иде. Ни җирдә укыганы вә остазлары кем булганы безгә мәгълүм булмады. Петербург шәһәренә барып, үз хәленә туры килүче сәүдә кәсебенә тотынды. Петербургта торган Нижгар мишәрләре тырышып моны үзләренә имам итеп тоттылар. Бу вакыт беркадәр русча белеп, кайбер бөек адәмнәр белән дә таныш булган. Мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим вафат булуында заманының булышлыгы сәбәпле // [349] Җәмгыяте шәргыягә мөфти булып билгеләнеп, Уфа шәһәренә китте. Петербургта булган вакытында 1830 елда Искәндәр мирза Апанай улының Тутыя исемле кызына, атасының ризалыгыннан башка, Мәскәүдә сәүдәгәр улы Ибраһим бине Макай исемле кеше белән никах укыды. Шул сәбәпле хөкем астында калып беркадәр маҗараларга очрады.

### 371. Җәгъфәр бине Салих бине Мөхәммәдгали әл-Кулаткый

Саратов вилаяте Кулаткы авылында 74 яшендә 1279 (1862) елның 5 рәҗәбендә (декабрь) вафат булды. Гөлфари исемле хатыныннан булган балалары: Мөхәммәдҗан, Бәдигылҗәмал, Хәбибҗәмал, Васфыҗәмал. Анасы Бохария исемле иде. Атасы гади халыктан бай бер адәм иде.

Бу кемсә якын авылларда кечкенә мәктәпләрдә беркадәр укып йөргән, бәлки, яше зур булса кирәк, атасы бер җирдән // [390] надан бер хатын алып биргән. Аз булса да гыйлем ләззәтен сизгәнгә һәм шул хатыны белән табигать берлеге вә өлфәт булмаганга, көннәрнең берсендә Казан шәһәренә качып киткән. Мөхәммәделкәрим бине Габдеррәхим әт-Тәкәнеши мәдрәсәсенә кереп, хатынына талакнамә вә ата-анасыннан ризалык сорап хат язган. Өч ел чамасы бу мәдрәсәдә торгач, күзе хаста булган. Язу язарга мәшәкатьле булып, укуын дәвам итә алмаслыгын аңлагач, бар гыйлеменә канәгать булып озын бер сәфәргә чыккан. Шул сәфәрендә Ташкент, Сәмәрканд һәм башка мәшһүр шәһәрләрдә йөреп, соңыннан Бохарага барган. Бохарада Вәлид ишан бине Мөхәммәделәмин әс-Сәгыйди вә шәех Фәйзхан бине Хозырхан әл-Кабули якыннарыннан, соңгысының хәлифәсе булган Габделхаликъ бине ... [төп нөсхәдә шулай. – *Төз.*] әл-Баллыкүли әл-Казаный хозурында тарикать юлына басып тәрбияләнгән. Габделхаликъ исә бервакыт хәлифәи Рамазаный вафат булганнан соң аның урынында мөрид җыйган. Әмма соңрак Нәсәф шәһәренә китеп шунда төпләнеп калды. Ахырында хаҗ сәфәренә барып, хаҗ гамәлләрен тәмам итеп кайтып килгәнендә Шам якларында вафат булды, диләр. Асылы Спас өязе Баллыкүл авылыннан иде.

Җәгъфәр ишан, Габделхаликъ тарафыннан иҗазәт алганнан соң, хаҗ кылу нияте белән сәфәр чыккан. Бу сәфәрендә Шам, Бәгъдад, Мисыр вилаятьләрендә озак вакытлар сәяхәт иткән. Шул вакытта аның Бәрдә Садыйк исемле казанлы бер юлдашы да булган, имеш. Шул сәяхәте дәвамында Мәдинә шәһәрендә унике еллар чамасы яшәгән, дип риваять кылына.

Унсигез еллар йөреп, 1250 ел ахырында көннәрнең берендә Җәгъфәр ишан үз асыл ватанына кайткан. Атасы вә анасы икесе дә сәламәт, имеш. Өстендә фәкыйрь вә дәрвишләр киеме булып, үзе // [391] дә тәкәллефсез вә гади рәвештә йөргәнгә,

Кулаткыда булган ир вә хатыннар бер-берсенә: «Сәләй сукыры кайткан икән!» – диерләр, вә Җәгъфәр ишан үзе дә моны ишетеп йөргән. Бу вакытларда Шаһиәхмәд ишан бине Йосыф Кулаткы авылына килеп китеп йөргәнендә Җәгъфәр ишан белән аралашып, аның фазыллыгын аңлап, һәрвакыт мактау сүзләрен әйтә торган булган. Шул авылда Әюб исемле бер байның Гөлфари исемле кызын никах итеп, шуның белән беркадәр булса да дөнья кичерүе юлына кергән. Кулаткыда урнашып калып шәехлек итеп мөрид җыйган. Укучыларының күбесе башкорт, кыргыз һәм Нижгар вилаяте мишәрләре булыр иде, диләр. Хатыны Әюб кызы вафат булганнан соң, алты ел чамасы хатынсыз торып хаҗ сәфәренә чыккан. Әмма кайбер киртәләр булу сәбәпле кире кайтырга мәҗбүр булган. Бер ара вакыт Дагыстан вилаятендә сәяхәт итеп йөргән, Тифлис шәһәрендә дә булган. Соңрак Самара якларындагы Исәнтимер авылыннан Мөршидә бинте Мөхәммәд исемле кызны никах кылып, шуның белән фәкать биш ай торып дөньядан кичкән.

Шәкерт вә дәвамчылары: Габделлатыйф бине Яһуда, Габделлатыйф бине Халид әл-Бәдәнки, Хөснеддин бине Гомәр әс-Суыксувый әл-Казаный, Фәтхулла бине Вәлид әз-Задурый, Нәҗмеддин бине Әхмәд әл-Әстерханый.

Бу кемсә хакында Габдулла әфәнде бине Гайсә әл-Кулаткый: «Җәгъфәр ишан, сәфәреннән кайтып, Кулаткы авылында 35 еллар гомер сөрде. Атасы бик озын гомерле булганга, барча дөнья мәшәкатьләрен моның өстенә салды. Авыл вә тирә-як муллалары үзенә артык каршы булганга күрә, вак кына нәрсәне артык күпертерләр, һәрвакыт гайбәтен сөйләрләр. Хәтта Зимничә авылындагы мәшһүр бер мөдәррис һәрвакыт «Җәгъфәр зиндикъ» // [392] дип әйтер иде. Шул сәбәпле Җәгъфәр ишан бөтен гомерен кайгы вә хәсрәт белән кичерде. Үзенә очраган вакытта муллалар гаять орышырлар, юк нәрсәләр өчен дә кыямәт куптарырлар иде. «Сукыр монафикъ» дигән сүзләр моңа һәрвакыт әйтелер иде. Күп мәҗлесләрдән елап чыкканы риваять кылына. Зөя башының Хорамшаһ бай Акчуриннар аңа яхшы мөнәсәбәттә булганнарыннан, махсус мәчет бина итсәләр дә, анда да төрле фетнә чыгып, ул имам булу фикереннән ваз кичте. Ялгыз бер генә өе булып, йортының тирәсенә ихата кылыр. Үзе дөньяны рәхәтләндермәгән кебек, дөнья да аны куандырмады. Мөхәммәдҗан исемле улы озын гомер яшәде, Газизә исемле хатыны булып, Мифтахеддин, Хисамеддин, Хөснеддин

исемле балалары бар иде. Бәдигылҗәмал исемле кызыннан бүген Мөхәммәдзариф бине Таҗеддин исемле бер имам улы бар. Гыйлемнәрдә белеме урта дәрәҗәдә иде. Иҗазәтнамәсен үзеннән соң хатыны кулыннан бер ялганчы хәйләкәр адәм алып качып китте, диләр. Кызы Бәдигылҗәмал кулында тагын бер иҗазәтнамәсе күренде. // [393]

### 372. Әхмәд бине Мөхәммәдшаһ бине Әхтәм әс-Суыксувый

Буа өязе Суыксу авылыннан булып, 30 яшеннән узып 1279/1862 елда Бохарада вафат булды.

Остазлары: Габделвахид бине Габдеррахман әл-Буавый, Габелмөэмин бине Үзбәк әл-Бохарый, Шиһабеддин бине Баһаведдин әл-Мәрҗани һәм башкалар.

Шәкертләре: Хәйдәр бине Әмин, Җәмаледдин бине Габделлатыйф, Әхмәди бине Фәтхулла әл-Куяный һәм башкалар.

Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Зиһенле, тугры фикерле, галим вә фазыйль, сөйләргә маһир бер зат иде. Чын галимнәр, акыл ияләренең әсәрләрен карап, камиллеккә ирешкән иде. Өйрәнү, тикшеренүләргә һәвәсле иде. Кызганыч, гомере кыска булды. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә гомеренә форсат биргән булса иде, гыйлем өлкәсендә бөек бер тырышлыклар күрсәтер иде», – дигән.

### 373. Минһаҗ бине.. бине ... [төп нөсхәдә шулай. – *Төз.*] әл-Мәдәни

1279/1862 елда Мәдинә шәһәрендә вафат булды. Үз илендәге галимнәрдән укыганнан соң, Бохара вә аннан һиндстанга барып укуын камилләштергән.

Бу кемсә хакында Мөхәммәд Морад әл-Минзәләви [Морад Рәмзи ]: «Минһаҗ әфәнде галим, төрле фәннәр белгече, бик тырыш, дәртле иде; Мәдинәнең олы галимнәреннән иде. Суютыйның «әл-Җамигъ әс-сагыйр» исемле китабын кыскартып язган, бу әсәрнең бер нөсхәсе Каһирәдә хәдив китапханәсендә бар, дип риваять кылалар. Йосыф Гази әфәндегә һәрвакыт фәтвәдә булышчы иде. Үзе исән вакытында без килеп җитешә алмадык [Мәдинәгә]. Вафат булганыннан соң Фәхреддин әфәнде аның урынына мөдәррис булып билгеләнде», – дигән. // [395]

**374. Хәсән бине Муса бине Исмәгыйль бине Апанай**

Казанда мәшһүр сәүдәгәрләрдән, 64 яшендә 1280 (1863) елның сәфәр (июль) аенда вафат булып, Казан каберлегендә җирләнде. Анасы Сахибҗәмал бинте Габдеррәшид бине Гали булганыннан, Шаһиәхмәд мирза бине Мөхәммәд бине Габдеррәшидкә туган була. Мөхәммәджан, Мөхәммәдшаһ, Әхмәдшаһ исемле уллары калды. Атасы Муса да мәшһүр байлардан булып, 75 яшендә 1242/1827 елның 19 рәҗәбендә вафат булды.

**375. Корбангали бине Ягъкуб бине Исмәгыйль бине Сөбханкол бине Котый бине Бикән әл-Казаный**

Казан байларыннан булып, 1280 (1863) елда Казан шәһәрендә вафат булды. Бабасы Сөбханкол бине Котый булганга, Ибне // [396] Сөбәй буларак билгеле иде. Шакир исемле улы калды.

Бертуганы Хөсәен бине Ягъкуб та могтәбәр байлардан булып, 1276/1859 елда вафат булды. Әмирхан бине Кучкар бине Ягъкуб (№130) хатында телгә алынган «Корбангали» белән «Хөсәен» шушы сахибе тәрҗемә белән аның абыйсы Хөсәен булалар инде.

**376. Госман бине Муса**

Оренбург шәһәренең беренче мәчетендә имам булып, 56 яшендә 1280 (1863) елның рабигыль-ахир аенда (19 сентябрь) вафат булды.

Остазлары: Габделлатыйф бине Әдһәм әл-Юлыкый, Бәдреддин бине Сәйфелмөлек әс-Сәгыйди, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый.

Асылы Сәгыйдь бистәсеннән булып, Нигъмәтулла бине Габдеррәхим вафатыннан соң имам булып зур мәдрәсәләр тотты, күп шәкерт җыйды, уй-фикерләре гүзәл иде, диләр. Мөхәммәди исемле улы бүген шул мәчеттә мөәззин, хатыны Зәйнәб бинте Гатаулла бине Габдеррахман әл-Кирмәни дә сәламәт.

**377. Мөхәммәджан бине Хөсәен әл-Колчурый**

Ор[ск] өязе Колчур авылында имам булып, 65 яшендә 1280/1863 елда вафат булды. Габдеррәшид бине Иманкол әт-Ташкичүви әл-Ачулый хозурында укыган. Утыз еллар укыту белән мәшгуль булган. Күп имамнар җитештерде, диләр. Хөснеддин бине Мөхәммәдгали, Әмир бине Сагынбай, Мөхәммәдкәрим бине Ишбирде, Муса бине Серелбай әт-Тамачый бу зат якыннарыннан. // [397]

**378. Таҗеддин бине Габдессаттар бине Габдеррахман бине Хәсән**

Казан өязе Олы Мәңгәр авылында имам булып, 65 яшендә 1280 (1864) елның 20 рабигыль-ахирендә (гыйнвар) үпкә авыруыннан вафат булды.

Остазлары: Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри, Таһир бине Сөбханкол әл-Адайи. Шәех Габделхаликъ бине Ибраһим әл-Курсавыйга дус булган, берничә тапкыр хаҗ сәфәренә барган.

**379. Шиһабеддин бине Фәхреддин бине Мортаза бине Габделгазиз әл-Казаный**

Казан шәһәрендә 50 яшеннән узып, 1280 (1864) елның шәүвәл ахырында (23 март) вафат булды. Анасы Мәхбүбә бинте Ибраһим әфәнде әл-Казаный иде.

Остазлары: Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый, Сәгыйдь бине Хәмид, Габделкаһһар бине Сәгыйдь һәм башкалар.

Бохарага барып казый Шәриф хуҗа һәм башкалардан укыган, үз иленә кайтканнан соң, Казан шәһәренең өченче мәчетендә беркадәр вакыт имам булып торгач, урыныннан алынган. Габделгафур бине Мәхмүд кызын алып, кияве булды. Ялгыз бер баласы калды.

**380. Мөхәммәд бине Гыйрфан бине Габденнасыйр бине Бикмөхәммәд әл-Ишеви**

Шәкерт булган вакытында Казан шәһәрендә 24 яшендә, 1280/1864 елда вафат булды. Казан ягындагы Иши авылыннан. Атасының абыйсы булган Фәхреддин бине Бикмөхәммәд хозурында укыганнан соң, Казан шәһәрендә фазыйль Мәрҗанинең

дәрес түгәрәгендә укыган, шул вакытта вафат булган. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Фәһеме яхшы, зиһене тугры, зирәк, заһид, // [398] диндар вә изге кеше иде. Узган заман галимнәренең әсәрләрен күреп, алар белән таныш иде, дөрес игътикадларны аңлап белер иде, чын галимнәрнең күп гыйлемнәрен алган иде. Әгәр дә гомере булса иде, мәгърифәт мәйданында бөек эз калдырыр иде. Ләкин яшьлегендә вафат булды», – дигән.

**381. Сәгъдеддин бине Габделҗәлил бине Заһид бине Гаид**

Минзәлә өязе Метрәй авылында имам булып, 1280 елда вафат булды.

Остазлары: Әмирхан бине Кучкар әл-Үтәки, Шаһиәхмәд бине Рәфыйк әс-Симәки. Фикъһ, әхлак, тәфсир, хәдис, хисап гыйлемнәреннән беркадәр белеме бар иде, язган китабы да гаять күп иде. Үзе турында бик яхшы уйлап, гасырдашларына өстен карап, үзенең ялгышларын танымас иде, диләр.

**382. Корбангали бине Юлдашбай бине Бакыбай**

Ор[ск] шәһәрендә имам хәлендә, 65 яшендә 1280 (1864) елның зөлхиҗҗә аенда (15 май) вафат булды. Шунда күмелгәннән соң гәүдәсен туганнары Акъяр авылына күчерделәр. Акъяр авылында вә аннан соң Орск шәһәрендә укыту белән шөгыльләнгән.

Остазлары: Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли, Тимербулат әл-Кунакбайи һәм башкалар.

Уллары: Хөснеддин, Габделгалим, Габелгалләм. Әүвәлгесе укыган вакытында Бохарада вафат булды.

Шәкертләре: Мөхәммәдгали бине Илбакты, Фәтхулла бине Гобәйдулла һәм башкалар.

**383. Хөсәен бине Йосыф бине Мөхәммәд бине Сөләйман**

Казан шәһәренең зур сәүдәгәрләреннән, Чукин дигән билгеле фамилиядән булып, 1281 (1863) елның // [399] 10 мөхәррәмендә (15 июнь) хаҗ сәфәреннән кайткан

вакытында, Янбәгъ шәһәрендә вафат булды. Мөхәммәдҗан бине Муса бине Яхъя исемле кемсәне хезмәт өчен вә Шыгай авылыннан имам вә мөдәррис Мәүләви Җәләледдин бине Борһанеддин бине мулла Шәрифне Аллаһ ризалыгы өчен үзе белән бергә алып барган иде. Ибраһим, Мөхәммәдҗан исемле уллары вә Гайнелхәят, Хөснә исемле ике кызы калды. Инсафлы, юмарт, гыйлем әһелләренә ярдәмчел бер зат иде, диләр.

**384. Габделҗаббар бине Җәгъфәр бине Габделгафур әл-Пәрәвый**

Спас өязе Пәрәү авылында шәехлек итеп, 80 яшендә 1281(1864) елның рабигыль-әүвәл аенда вафат булды. Нигъмәтулла бине Гобәйдулла әл-Әлмәтидән иҗазә алып, мөридләр тәрбияләде. Аның үзеннән Мөхәммәд бине Габдулла әл-Кизләви рөхсәт алды. Фәтвәче, суфый, гүзәл холыклы бер зат иде, диләр.

**385. Габид бине Минкә бине Ягъкубине**

Тәтеш өязе Суыксу авылында имам булып, 1281 (1864) елның рабигыль-әүвәл аенда (2 август) 81 яшендә вафат булды. Җәмгыяте шәргыядә никадәр вакыттыр әгъза булып торды. Остазы Йуртыш авылыннан Хәмид бине Ислам иде. Биләл, Габдессаттар, Мөхәммәдвафа исемле уллары калды. Биләл бүген Казан шәһәрендә Бишбалта мәхәлләсендә, Мөхәммәдвафа исә Суыксу авылында имамнар.

**386. Фәхреддин бине Зәйнелгабидин бине Габдулла**

Ор[ск] шәһәрендә имам булып, 1281/1864 елда хаҗ сәфәренә китеп, Суэц шәһәрендә 60 яшендә вафат булды. Зәйнелгабидин // [400] ишан бине Габдулла әл-Юлыкыйның улы иде. Хаҗ сәфәренә барган вакытында Түнтәр авылына килеп шәех Гали бине Сәйфулла әт-Түнтәри мәдрәсәсендә бераз вакыт торган. Шәех хәзрәтләреннән төрледән-төрле белем алган. Ошбу вакыт шәех хәзрәтләрен мактап бер касыйдә иҗат иткәне риваять кылына.

**387. Таһир бине Сөбханкол бине Баһадиршаһ бине Чиркәс әл-Питраксый**

Малмыж өязе Адай авылында имам булып, 90 яшеннән кичеп, 1281 (1864) ел рәҗәбендә вафат булды. Хатыны Бикә бинте Әюб булып, балалары Мөхәммәдшәриф, Мөхәммәдсадыйк, Габделвәли исемле.

Остазлары: Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый, Габдеррәшид бине Кадермөхәммәд әс-Сабавый. Кыйраәт гыйлемендә булган шәехләре: Ишмөхәммәд бине Заһид әл-Күбәки, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади.

Шәкертләре: Таҗеддин бине Габдессаттар әл-Мәңгәри, Таҗеддин бине Габделҗәлил әт-Төбъязый, Таҗеддин әл-мөфти бине Мостафа, Габделхәким бине Габделкәрим әл-Питраксый, Сәйфеддин бине Сөбханкол әл-Кичүчатый, Сибгатулла бине Бикмөхәммәд әл-Күгәрчени һәм башкалар.

Бөтен гомерен кыйраәт гыйлемен укытып кичергәне өчен шәкертләре күп иде. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Озын гомер сөрде, Габделгалләм бине Габделкадыйр әс-Сабавый хәтта йөз егерме яшькә җиткән дип уйлый иде. Ләкин мин аның кадәр булыр дип уйламыйм. Асыл ватанына кайтып йөргәнендә безгә кергәли иде. Күкрәге киң, сулуы иркен булып, хәрәмәйн, коддус, мисыр мәкамнәре дип аталган төрле мәкам белән Коръән укыр иде. Шул мәкамнәрдә шәригать тыйган көйләр булмас, бәлки гүзәл тавыш, күркәм башкару вә яхшылап уку // [401] кебек кыйраәт әдәпләре саклана иде. Остазы Ишмөхәммәд бине Заһидның башкаруы никадәр камил булса да, моның башкаруы тагын да камилрәк иде. Шәкертлек мөнәсәбәтем булмаса да, кыйраәтенә бик ихласлы идем, аны ишеткән вакытымда һушым таралыр вә уй-хисләрем тәэсирләнер иде. Үзе: «Мин кыйраәтне Мөхәммәдрәхим ахун бине Йосыф әл-Ашытыйдан алдым, аннан соң Ишмөхәммәд бине Заһид әл-Күбәки хозурында укыдым вә хаҗи Бәгъдади Вәлиэддин бине Хәсән түгәрәгендә төзәттем; минем кыйраәтемне хаҗи Бәгъдади хуш күрер вә укытыр иде», – дип сөйләр, ләкин иҗазәтнамәләрендә Ишмөхәммәд хаҗи исемен генә искә алып язар иде», – дигән.

**388. Хәммад бине Халид бине Габделваһһаб бине Дустмөхәммәд бине Колмөхәммәд**

Казан шәһәренең дүртенче мәчетендә имам булып, 1281 (1865) ел рамазанының 2 нче көнендә (17 гыйнвар), 66 яшендә вафат булды. Хатыны Габделгаффар бине Сәгыйдь әл-Казаный әш-Шырданый кызы иде.

Балалары: Закир, Сабир, Шакир, Фатыйх.

Остазлары: Сәйфулла бине Үтәгән әс-Сәрдәви, Габдеррәхим бине Бикчәнтәй әс-Сабавый, Әбүбәкер бине Йосыф әл-Казаный, Габделгаффар бине Сәгыйдь әл-Казаный, Бохарада Мөхсин бине Биккол әш-Шашый, Гаяз бине Заһир һәм башкалар.

Шәкертләре: Таҗеддин бине Бәшир әс-Суыксувый, Гайнулла бине Шәриф әл-Мастакый һәм башкалар.

**389. Фәхреддин бине Бикмөхәммәд бине Рәхмәтулла бине Мәскәү**

Мамадыш өязе Шайтан Елга авылында имам булып, 1281 (1865) елның рамазан аенда вафат булды.

Балалары: Шакир, Йосыф, Гариф.

Остазлары: Бохарада Мөхсин бине Биккол әш-Шашый, Салих бине Надир әл-Хөҗәнди һәм башкалар.

Шәкертләре: Габделфәттах бине Габделхәким әл-Ярмәки, Бәдигыддин бине Габденнафигъ әл-Кырмыскавый әл-Эстәрли, Мөхәммәдҗан бине Кадермөхәммәд ән-Нөркәйи әл-Минзәләви һәм башкалар.

// [403]

Асылы Казан елгасы буендагы Гайшә бикә сүзеннән бозылган Иши авылыннан. 1245/1830 ел ахырында Бохарадан кайтып Курса авылында имам булды. Соңрак исә Шайтан Елга авылына имамлыкка күчте, шунда вафат булды. Шәкерте Мөхәммәдҗан бине Кадермөхәммәд ән-Нөркәйи тарафыннан иҗат ителгән бер мәрсияне күрдек. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Галим вә фазыйль, язуга оста, хисап вә үлчәү гыйлемнәрен яхшы белә иде. Гүзәл холыклы, тыйнак, тәкәллефсез бер зат иде», – дигән.

**390. Габделмәннан бине Гадел бине Котлыг бине Алтынбай**

Чистай өязе Адәмсуы авылында, 75 яшьләрендә 1281 (1865) елның шәүвәл аенда (10 март) вафат булды. Бохарада укып, шул авылда имам иде. Соңрак беркадәр вакыт Җәмгыяте шәргыядә әгъза булып хезмәт итте. Ахырында имамлыгыннан чыкты. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Үзе диндар вә тәкъва иде, казый булуы да фәкать кеше димләве сәбәбеннән булды. Фәкыйрь булып көн кичерде», – дигән. 1846 елда имзалаган кәгазьләрен күрдек. Асылы Дүртиле авылыннан.

Хатыннары: Гайшә бинте Фәхреддин бине Вәлишаһ бине Мансур әт-Тигәнәле (Сибгатулла казый белән бертуган), Фатыйма бинте Хөснеддин әл-Ибрайи, Рахиләтелмөслимә. Беренче хатыныннан Нәгыймә исемле кызы булып, Хөснеддин исемле кемсәгә никахланды. Икенче хатыныннан Әхмәд, Хөснизәмал, Маһҗәмал исемле, өченче хатыныннан Мөхәммәд исемле балалары булды. Мөхәммәд исә Дүртиле авылында имам. // [404]

**391. Искәндәр бине Максуд бине Әхмәд бине Биги әл-Кирмәни**

Кызылъяр (Петропавел) шәһәрендә имам булып, 1281 (1865) елның зөлхиҗҗәсендә вафат булды.

Остазлары: Исхак бине Сәгыйдь әл-Казаный, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый, Фәйз бине Габделгазиз әл-Кенәри, Бохарада казый Шәриф Мәүләви, Нияз бине Бинейәмин ал-Сәлахи, Салих бине Надир Хөҗәнди, Хәсән бине Хәл әл-Бохарый. Бохарадан кайтканында Кирмән ягындагы бер авылга имам булган иде. Соңрак исә, Сираҗеддин бине Сәйфулла кулга алынганга күрә, Кызылъярга күчеп аның урынына имам булды. Хиҗазга сәфәр кылып, бу сәфәрендә Казан шәһәреннән үтеп китте.

// [405]

**392. Хәбибулла бине Мөхәммәдшәриф бине Биккол**

Тәтеш өязе Кече Күккүз авылында имам вә мөдәррис булып, 1281 (1864) елның зөлхиҗҗә аенда, хаҗ гамәлләрен тәмам итеп Минада вафат булды.

Остазлары: Хәмид бине Ислам әл-Юртышый, Фәтхулла бине Сәфәр әл-

Казакларый, Мөхәммәдъяр бине Хәмид әс-Сәрдәви һәм башкалар.

Шәкертләре: Казый Таҗеддин бине Мөштәри, Таҗеддин бине Нәҗмеддин һәм башкалар.

Балалары: Насыйбулла, Гобәйдулла, Латыйфә, Сәгыйдә, Маһруй.

Насыйбулла исемле улы Фәхреддин бине Мостай эн-Нурламый, Фәтхулла бине Сәфәр әл-Казакларый, Хәммад бине Халид әл-Казаный хозурында укып, атасына иптәш булып имам булды, 1312/1895 елның зөлкагдә аенда (30 апрель) вафат булды. Аның Сөнгатулла исемле улы Казанда Мөхәммәдзакир бине Хәммад хозурында укуын тәмамлап, Чабаксар өязе Кармыш авылында имамлыкка указ алганнан соң, 31 яшендә 1322/1904 елның җөмадиел-әүвәл аенда (1 июнь) вафат булды. Әхлагы гүзәл, гыйлеме тиешлечә, дөнья әхваленнән хәбәрдар иде. Фәйзеррахман исемле икенче улы Күккүз авылында имам.

Сахибе тәрҗемә ачык йөзле, аз сүзле, тырыш бер зат булып, шәкерт булган вакытында үз кулы белән «Шәрх Мулла», «Шәрх әл-Гакаид ән-Нәсәфия», «Шәрх әл-Гакаид әл-Гаддыя», «Мишкәт әл-мәсабих» һәм башка китапларны күчергән. Язуы гүзәл булса да, хаталы, хәрәкәләрнең дөреслеген сакламаган (Оренбург шәһәренә килгәнебездән соң, оныгы Җарулла бине Фәйзулла шушы тәрҗемәи хәлен безгә язып җибәрде. Без исә шуннан сайлап алып, шушы җирдә өстәдек). // [406]

**393. Исмәгыйль бине Тимергали әс-Сөләйманый**

Уфа ягындагы Сөләйман авылында имам булып, 1281/1864 елда вафат булды. Кыйраәт гыйлемендә оста булып, Габделхаликъ бине Габделкәрим әт-Тырнавыйда укып, рөхсәт алды.

Шәкертләре: Сәедбаттал бине Фәйзулла әл-Мөслими, Фәхреддин бине Үтәгән әл-Минайи, Мөхәммәдхәсән бине Мәсгудә, Бәдреддин бине Вәйс әл-Кызылъярый, Ризван бине Әсәдулла әл-Итаушый һәм башкалар. Коръән укырга вә укытырга осталыгы белән тирә-якта шөһрәт казанган иде.

**394. Фәхреддин бине Мөхәммәдсадыйк бине Габдеррәфыйг әс-Сөни**

Мамадыш ягындагы Кече Сөн авылында имам вә мөдәррис булып, 65 яшендә 1282 (1865) елның мөхәррәм аенда (28 май) вафат булды.

Остазлары: Исхак бине Сәгыйдь әл-Ләжи әл-Казаный, Габделгафур бине Габделмәннан әл-Чистопулый һәм башкалар.

Шәкертләре: Хәсән бине Хәмид әл-Курсавый, Хәйрулла бине Нигъмәтулла әл-Әлмәти, Сәлахеддин бине Исхак әл-Казаный, Габденнасыйр бине Төхфәтулла әл-Чубытлый, Габденнасыйр бине Габдессәлам әз-Зимнәҗәви, Гыйсмәтулла бине Сәйфулла әз-Зирекләви әт-Төмәни, Әхмәд бине Мөхәммәд әл-Кизләви, Борһанеддин бине Габдеррәфыйг әш-Шәбкәви, казый Мөхәммәдсафа бине әл-Мөхәммәд әс-Сөни һәм башкалар. Асылы Мамадыш өязе Бөрсет исемле авылдан иде.

Хатыны үз остазының кызы Фәридә бинте Исхак әл-Ләжи булып, балалары Латыйфә, Зарифә, Мәрфуга, Юныс. Юныс атасы урынына имам вә мөдәррис булып, мәдрәсәдә шәкерт тәрбияләде, 58 яшендә 1318/1900 елның // [407] мөхәррәм аенда (12 май) вафат булды. Моның Гыйсамеддин исемле улы сәламәт вә атасы урынында имамлык вә укыту белән көн кичерә.

**395. Габденнасыйр бине Габдеррәхим бине Әхмәр бине Габделмәннан бине Юрткә бине Ютәбай бине Кол бине Килдеш бине Дәүләҗар бине Имин бине Байтәүкәл бине Илүс бине Әлкәш**

Бөгелмә өязе Тайсуган авылында имам вә мөдәррис булып, 72 яшендә 1282 (1865) ел сәфәр аеның 12 нче көнендә (25 июнь) вафат булды. Кабере Тайсуганда.

Балалары: Габделгани, Шәмсекәмал, Шәмгыҗиһан һәм башкалар.

Остазлары: Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Габид бине Габделгазиз әл-Кенәри, Фәтхулла бине Сәфәргали әл-Казаклары́й, Бохарада казый Ниязбирде, Фәхреддин бине Сөбханкол әл-Кичүчатый һәм башкалар.

Шәкертләре: Мөхәммәдсадыйк бине Габделҗәлил әд-Думайи, Габдулла бине Габделгафур әл-Чакмакый, Габделфәттах бине Габделкаюм әш-Шәлчели, Гали бине Салих әл-Чокрый. Габделкариб бине Бинейәмин әл-Аклушый, Габделкадыйр бине Габделмәҗид әл-Кенәли әл-Карамалый, Гаделгәрәй бине Корбангали әл-Мөэмини әл-

Кенәли һәм башкалар.

Асыллары Казан өязе Байланлар [Байлангар] авылыннан булып, бабаларыннан берсе Әхмәр бине Гаделмәннан Бөгелмә өязе Урыссу авылына күчкән. Габденнасыйр хәзрәт шул авылда дөньяга килеп, үз илендә берничә остаз хозурында укыганнан соң, 22 яшендә Бохарага сәфәр итеп, шунда ничә еллар укып, үз җиренә кайткан. Бохарага баруы Әбеннасыйр Габденнасыйр // [407] бине Ибраһим әл-Курсавыйның икенче мәртәбә барганында бу якларга кайтыр өчен сәфәр иткәненә туры килде. Үз иленә кайтканнан соң Уфа вилаятендәге Катай, Такталачык, Катыш Каран авылларында указсыз гына укыту белән шөгыльләнде, Мөхәммәдзариф бине Габделҗәббар вафатыннан соң Тайсуган авылында указлы мулла булды. Утыз биш ел кадәр дәрес укытты, шәкерте дә хисапсыз иде. Бохара ысулы белән дәресләрен яхшы укытты, диләр. Гомере буе көнләшүчеләрдән төрле кайгы-хәсрәт күреп яшәде. Укыган вакытында булган иптәшләре Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри һәм Сәгыйдь бине Хәмид әл-Бәрәскәви иде.

Остазы казый Ниязбирде Әбеннасыйр әл-Курсавыйга каршы язылган фәтвәне имзалаган кеше булганга, сахибе тәрҗемә дә Курсавыйның мәсләген хата санар, шәкертләренә дә һәрвакыт Бохарада булган маҗарасын тәфсилләп хикәят итәр иде.

Имам вә мөдәррис булганнан соң Казан шәһәреннән сәүдәгәр Мортаза бине Минлибай бине Габдеррәшид бине Йосыф әл-Казаный Тайсуган авылында агачтан мәчет бина кылып, мәдрәсәләрен дә төзеткән. // [410]

### 396. Габделкадыйр бине Каһарман бине Атйитәр бине Нургали

Чиләбе өязе Сафакүл авылында имам вә мөдәррис булып, 61 яшендә 1282 (1865) елның рабигыль-ахир аенда вафат булды.

Остазлары: Габденнасыйр бине Сабит әл-Әлмәни, Габделлатыйф бине Әдһәм әл-Юлыкый.

Мирзазаһид исемле улы шул авылда имам булып, мәдрәсә тотты. Бүген сәламәт булу-булмавы безгә мәгълүм түгел.

**397. Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим бине Гаид**

Истанбул шәһәрендә 60 яшендә 1282 (1865) елның рабигыль-ахир аенда вафат булып, Әбү Әюб әл-Әнсарый каберлегендә күмелгән.

Остазлары: Җарулла бине Бикмөхәммәд әс-Сатышый, Гайнан бине Ихсан әл-Казаный, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый, Бохарада Салих бине Надир әл-Хөҗәнди һәм башкалар.

Шәкертләре: Әхмәджан бине Әхмәд әл-Әтрәкли әл-Мәчтәйи, Габделвәли бине Габделгаффар әс-Сенбери, Мөхәммәдрәхим бине Миндан әл-Пәлдәнги, Габделгали бине Гобәйдулла әл-Бәйрәкәви, Гыйсмәтулла бине Сәйфулла әз-Зирекләви, Габделкаюм бине Габделбәдигъ әл-Җәбәли, Шаһигәрдән бине Мөхәммәд әс-Сафарый, Габделвәли бине Габделгаффар әл-Казаный, Габдулла бине Нигъмәтулла әл-Бубый, Габделҗәббар бине Зөбәер әт-Теләнчи, Нургали бине Габдеррәкыйб әл-Барудый, Нуреддин бине Мифтахеддин әт-Тарханый һәм башкалар. // [411]

Казан шәһәрендә вә Русия мөселманнары арасында билгеле булган мөдәррисләрнең мәшһүрләреннән берсе иде. Асылы Мамадыш өязе Тәкәнеш авылыннан булып, үз илендә укыганнан соң, Бохарага барып, андагы галимнәрдән белем алган. Ватанына кайткач, Казан шәһәренең икенче мәчетенә имам булып билгеләнгән. Шәкерте гаять күп булыр иде, мәдрәсәсеннән чыккан имамнарның да хисабы юк, диләр. 1267/1851 елда Хиҗазга барып, хаҗ кылып кайтты. 1277/1861 елда икенче мәртәбә хаҗ сәфәреннән кайтканында Истанбул шәһәрендә туктап, шунда торып калды. Бу кемсә хакында Гыйсмәтулла бине Сәйфулла әт-Төмәни әз-Зирекләвинең: «...Фәхреддин бине Мөхәммәдсадыйк әс-Сөни, Исмәгыйль бине Муса әл-Кышкарый дәресләренә даими кердем, һәрберсенең гыйлемнәрен вә сәләтләрен гүзәл рәвештә аңладым. Әмма һичберсенең гыйлемнәрен Мөхәммәдкәрим дәрәҗәсендә тапмадым. Мөхәммәдкәрим хәзрәтнең дөресе, китапларны тикшерүе, бәхәстә булган ягымлылыгы, фикер аңлата белүе акылымны хәйран калдыра иде. Дөресен әйтәм, аның кебек башка бер остазны гомеремдә күрмәдем», – дип сөйләгәнен Уфа шәһәрендә ишеттем.

Шәех Зәйнулла бине Хәбибулла әл-Халиди хәбәренә күрә, сахибе тәрҗемә Истанбулда шәех Зыяэддин әл-Гөмешханәви белән якын аралашкан.

Салих исемле улы Истанбулда сәүдә белән шөгыльләнеп, 1321 елның 12 шәгъбанында вафат булды. Гаять ышанычлы вә вәгъдәсендә // [412] торучы бер зат иде, диләр. Нәселе шул якларда калды. Анасы исә Мөхәммәдкәрим хәзрәтләреннән аерылып, Чистополь өязе Чирмешән елгасы буенда Киекле авылында гомер сөрде. Минемчә, ул инде вафат.

Габдеррахман исемле икенче улы гаскәри мәктәптә укып, хәрби кеше булганын ишетсәк тә, тәфсилле мәгълүмат безгә билгеле түгел.

Мөхәммәдкәрим хәзрәт Истанбулга баргач беркадәр шәкерт җыеп дәресләр башлаган булса да, беренчедән, андагы телне белмәгәненнән, икенчедән, ул яклардагы дәрес бирү ысуллары башкача булганга, шәкертләре таралып беткән, диләр. // [413]

## 398. Шәфи бине Ягъкуб бине Габделҗәлил бине Ибраһим бине Балтай бине Нурмөхәммәд бине Айбакты бине Байбакты бине Яхъя бине Муса әл-Багышый

Тәтеш өязе Чирмешән-Багыш авылында 1282 (1865) елның җөмадиел-әүвәл аеның 12 нче көнендә (22 сентябрь) 77 яшендә вафат булды. Башта Морзалар исемле авылда имам булган, соңыннан Җәмгыяте шәргыягә сайланган. 1833 елда имзалаган кәгазьләрен күрдек. Аннан кайтканнан соң азмы-күпме вакыт узгач, имамлыктан алынды. Фәкыйрьлек белән гомер сөрде, диләр.

Уфа шәһәрендә торучы Сәгыйдь бистәсе мещаны Мөхәммәдшәфигъ бине Валид бине Сәгыйдь бине Фулад бине Әмин исемле затның 1836 ел апрелендә 54 сум кыйммәтендә булган 80 мыскал көмешен урлауда гаепләнеп, тикшерү астында калды. Озын маҗаралар соңында асыл ватанына кайтып китте. Кайда укыганы вә башка әхвале безгә билгесез. Казан вилаятендә булган Мәхкәмәи исламиядә әгъза булып хезмәт итәр өчен дип сайлануы сәбәпле монда тәрҗемәи хәлен китердек.

## 399. Шәмседдин бине Ярмөхәммәд бине Гобәйдулла

Хаҗ сәфәренә барганында 40 яшендә Таганрог шәһәрендә 1282/1865 елның җөмадә айларының берсендә вафат булды. Оренбург өязе Ишмәт исемле авылда

дөньяга килгән, кечкенә вакытында күзләре сукырайган. Авылының суы Зәк исемле булганга, Шәмседдин суфый Зәки дип мәшһүр булды. // [414] Гомерендә ике мәртәбә никахланып, бер хатыны үзеннән алда вафат булды.

Шәкертләре: Заһиреддин бине Мөхәммәдгали бине Баим әл-Бөрҗаный, Мөхәммәд бине Динмөхәммәд әл-Баими, Мөхәммәдгазиз бине Мөхәммәдгали әл-Баими, Габдулла бине Сәед бине Нурмөхәммәд әл-Бөрҗаный, шагыйрь Акмулла (Мифтахеддин бине Мөхәммәдъяр) һәм башкалар.

Башта Эстәрле[баш] өязендә Котлыкилде исемле кемсә хозурында, аннан соң Ашкадар Балыклы авылында Габдеррахман хәзрәт мәдрәсәсендә укып, тагын да яхшырак белем алыр өчен Казан шәһәренә сәфәр иткән. Казанда Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим мәдрәсәсендә торган, шәкертләргә аңлатып, аларны бәхәсләштереп тынычсыз иткән өчен, Мөхәммәдкәрим хәзрәт тарафыннан мәдрәсәдән чыгарылган. Моннан соң үз авылына кайтып мәдрәсә ачкан, күп шәкерт җыеп, дәрес белән мәшгуль булган. Бервакыт үз авылының халкы белән үпкәләшеп, аларны ташлап, бөтен шәкертләре белән Эстәрлебаш авылына әш-шәех Харис бине Нигъмәтулла хозурына күчкән. Шунда шәкертләр укыткан.

## УНДҮРТЕНЧЕ КИСӘК

## ۱۴ نچی جزء

**400. Мәхмүд бине Вәли бине Әмир Мәхмүд әл-Хөсәени**

Петербург шәһәрендә Мәхмүд ишан буларак билгеле кеше. 1262 (1846) елда вафат булды. Кабере Петербург шәһәрендә мөселман каберлегендә булып, вафат булу тарихы кабер ташында язылган. Риваятьләргә күрә, асылы Әфганстанда Сарухан исемле шәһәрдән булып, ни сәбәпледер Себердәге Петропавел шәһәренә килгән вә шунда 1833 елда Гайнелхәят исемле бер кызга өйләнгән. 1834 елда Рәгыйбҗан исемле бер улы дөньяга килеп, үзе хаҗ кылу нияте белән 1841 елда Петербург шәһәренә килгән. Паспорт бирелмәү сәбәпле, шушы шәһәрдә туктап калган. Коръән хафиз булган, мөридләр тәрбиясе белән дә шөгыльләнгән. Вафатыннан аз вакыт алдан Габдеррәсүл Чохан Вәлиев исемле затның матди ярдәме белән ташбасма буларак «Дәләил әл-хәйрат» әсәрен бастырган.

// [425] Хатыны белән баласын үз янына Петербург шәһәренә китергән, баласын укыр өчен Истанбулга җибәргән.

Вафатыннан соң хатыны Нижгар вилаятендәге Куйсу авылыннан Габид исемле бер кемсәгә никахланып Царское Селода күп еллар бергә торганнар. Шушы тәрҗемәи хәлне 1325 нче елның рамазанында Петербург шәһәрендә Йосыф мөәззин Рәхим тарафыннан төзелгән җыентыктан күчереп алдым. «Дәләил әл-хәйрат» нөсхәсен үз күзем белән күрә алмадым.

**401. Зәйнеддин бине Габдеррәшид бине Габдекәй бине Атнакай бине Дусан**

Минзәлә өязе Иске Әлмәт авылында имам булып, 65 яшендә 1276 (1860) елның 1 зөлкагдәсендә вафат булды. Кабере шул авылда. Ышанычлы бер зат бу кемсәнең үз каләменнән ошбу җөмләләрен китерә: // [425] «1823 (1238) ел маһ Шәрифенең (рамазан аен күздә тота булса кирәк) 19 көнендә Иске Әлмәт авылына муллалыкка килдек. Май йолдызының 18 көне иде. Бу вакытта 1796 (1210-1211) елдан хисап итеп яшебез егерме җиде иде. Шул авылда дүрт ел биш көн указсыз торып, 1827 (1242) елның 12 июнендә указ алдым».

Асыллары Бәләбәй өязе Дим буендагы Динис авылыннан булып, Дусан исемле бабасы авылдан авылга мулла булып күчеп йөргән, ахырында Нөркәй авылына килеп төпләнеп калган. Шул авылда тегермән буасына төшеп вафат булганга, шул урын

бүгенгә кадәр Дусан Тугае буларак билгеле. Атнакай да Нөркәйдә торган, Габдекәй белән Габдеррәшид шулай ук берсе артыннан берсе Нөркәйдә имам булганнар.

Әлеге зат, Чистайда Исхак бине Сәгыйдь хозурында укып, күп кенә әсәрләрне күчереп язган.

Хатыннары: беренче хатыны Нөркәй авылыннан Зәйнеддин мулла кызы булып, аннан соң алган хатыны Саклаубаш авылыннан Идрис бине Габделмән бине Күкләш кызы Шәмсеҗиһан иде.

Беренче хатынынннан балалары: Сахибзадә, Мәгыйнеддин, Минһаҗеддин, Бибигабидә вә Гайнеддин. // [427] Боларның әүвәлгесе Яхшыбай авылында имам иде. Икенчесе юкка чыккан, өченчесе Казан шәһәрендә хастаханәдә вафат булды. Өчесе дә Казанда фазыйль Мәрҗани хозурында укыганнар иде. Икенче хатынынннан балалары: Сахибеддин, Фәрхиҗиһан, Хөснеддин, Фәхрелбанат, Бибиәфза. Фәрхиҗиһан – Иске Әлмәт авылында Баһадиршаһ бине Габдулла бине Гаделшаһка, Фәхрелбанат исә Чалпы авылында имам Әхмәдхан бине Солташ бине Нугайбиккә никахландылар. Заманыбызның билгеле шәехләреннән булган Мөхәммәдморад әфәнде әл-Мәкки әл-Минзәләви [Морад Рәмзи] җәнабләре беренчесенең улы була.

**402. Шәех Мөхәммәдгаяз Тантавый**

Мисырның Танта шәһәреннән булып, 1840 елда Петербург шәһәренә килде вә университет шәкертләренә гарәп телен укыта башлады. Кыйраәт гыйлемендә оста булып, мәшһүр кариларның берсе иде. Петербургта Мөхәммәдгалим мулла белән кардәше Мөхәммәдсадыйк бине Хантимерләр моннан кыйраәт гыйлемен өйрәнделәр. Хатыны да гарәп кызы булып, шул хатынынннан Петербург шәһәрендә Әхмәд исемле улы дөньяга килде. Үзе, 1277 яки 1278 (1861) елда вафат булып, Петербург шәһәрендә мөселман каберлегендә җирләнгән. Каберендә кара мәрмәр таштан ясалган монументта исеме вә асылы тәфсилләп язылган. Улы Әхмәд яшь чагында Петербургта гимназиядә укыган. Атасыннан соң ун ел чамасы мөселманнар күзендә күренеп йөрсә дә, соң егерме еллардан бирле ни хәлдә икәне мәгълүм булмаганлыгы турында 1325 ел рамазанындагы сәяхәтем вакытында Петербург мөәззине Йосыф әфәнде Рәхими сөйләде. Хатыны шәех Тантавыйның үзеннән алда вафат булды.

Шушы тәрҗемәи хәлләр үзләренә тиешле урыннарыннан кичегеп язылдылар.

### 403. Гатаулла бине Алтынхуҗа

Оренбург шәһәрендә кәрвансарай мәчетендә имам вә ахун булып, 63 яшендә 1282 (1865) елның 2 рәҗәбендә (10 ноябрь) вафат булды. Кабере шундадыр. Асылы Эстәрлетамак өязе Аллагуат [Аллагуватово] авылыннан иде. Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни хозурында укыганнан соң, 1837 елда үз авылына кайтып имам булды. Соңрак, кәрвансарай мәчете тәмам булганнан соң, Оренбург шәһәрендә яшәгән каенагасы мирза Искәндәр Батыршин тырышлыгы белән шул мәчеткә беренче имам булып билгеләнде. Үзенә торыр өчен кәрвансарай биналарыннан урын бирелде, моннан башка утын, су бушлай бирелер, моның өстенә дә елына йөз илле сум акча да билгеләнде. Гүзәл холыклы, зиһенле, аңлаучан бер зат иде, диләр. // [431]

### 404. Габдулла бине Мөслим бине Мөэмин әл-Иштирәки

Богырослан өязе Балыклы Күл – Давыд авылында имам булып, 80 яшендә 1282 (1865) елның җөмадиел-ахир аенда вафат булды. Хатыны Бәлхия бинте Гомәр әл-Киекли булып, Габделҗаббар бине Гомәр әл-Киекли белән бертуган иде.

Балалары: Мостафа, Әхмәд.

Остазлары: Габдеррәшид бине Мөхәммәд әш-Шөгери, Хисамеддин бине Мөэмин әл-Әлкәйи, Гомәр бине әл-Киекли, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади һәм башкалар.

Асылы Бөгелмә өязе Иске Иштирәк авылыннан. Укуын тәмамлап, мәдрәсәдән чыкканнан соң, Саратов вилаятендәге Пәлдәнге [Бәлдәнге] авылында Дибирди улларында торып балалар укыткан. Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли белән якыннан аралашкан, суфыйчылык дәресләрен алган. Мостафа исемле улы да шул Балыклы авылында имам иде, хәзер // [432] вафат. Балалары һәм оныклары бар. Пәлдәнгедә Габденнасыйр, Габделмәннан, Хәбибулла, Муса әфәнделәр исеменә язган бер хатын күргәнебез бар.

**405. Җамаледдин бине Шәмседдин бине Хисамеддин бине Габделхәмид әс-Сабавый**

Мәшһүр Саба авылында имам булып, 1283 (1866) елның мөхәррәм аенда (11 май) 86 яшендә вафат булды. Җеназасын Габделгалләм бине Габделкадыйр әш-Шәрифи укыды. Анасы – Зөбәйдә бинте Шәриф әт-Тенеки; бертуган кыз кардәше Мөһреҗәмал бинте Шәмседдин Минзәлә өязе Кара Чишмә авылында ахун Габденнасыйр бине Солтангали әл-Уфавый (Кырмыскалы авылының) никахында иде.

Остазлары: Сәйфеддин бине Әбүбәкер әш-Шыңарый, Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавый һәм башкалар. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Гәрчә гади халык карашында галимнәрдән хисапланмыйча, китап язып гомер итүче булып саналса да, хакыйкатьтә галим вә фазыйль, аңлы бер зат иде. Фикерләве тугры булып, хакыйкать әһелләре файдаларыннан күп нәрсә туплаган иде, шул сәбәпле гыйлем ягыннан күпләрдән өстен иде», – дигән.

**406. Хөсәен бине Фәйзхан бине Фәйзулла бине Биккенә бине Исмәгыйль бине Тәңребирде әс-Сабачайи**

Курмыш өязе Сабачай авылында 45 яшендә[1] 1283/1866 ел 28 рабигыль-ахир аенда (августта) вафат булды. Җеназасын шул авылның имамы Әшрәф бине Мифтахеддин укыган.

***Рәсми тәрҗемәи хәле***

Милади белән 1866 нчы ел декабрь аенда Санкт-Петербург университеты канцеляриясендә язылган тәрҗемәи хәл кәгазенә күрә рәсми биографиясе мондый:

---

[1] Дөресе – 38 яшендә. Р.Фәхреддиннең «45 яшендә» дип ялгыш язуы мәсьәләсенә соңгы дәвер тикшеренүчеләр игътибар иттеләр (Усманов М. За- ветная мечта Хусаина Фаизханова: повесть о жизни и деятельности. - Казань: Татар, кн. изд-во, 1980. - С. 13).

// [433] «Мулла Хөсәен Фәезхан улы Петербург университеты Шәрекъ телләре факультетында лектор һәм дә Шәрекъ телләре мөгаллиме. Яше 38 дә, ислам динендә. Барлык вазыйфасы – 1000 сум. Җир-су кебек милке юк. Мәгариф министрлыгының рөхсәте белән Шәрекъ телләре факультеты шәкертләренә төрки, татар телләрен укыту өчен тәгаен ителде. Ләкин вазыйфа бирелмәү шарты белән 1857 нче елның 14 нче ноябрендә шушы рәвештә булган хезмәте кабул булган җәһәттән Мәгариф министрлыгы тарафыннан 300 сум вазыйфа бирергә рөхсәт ителде.

1860 нче ел 15 мартта Уку округы мөдире тарафыннан мөселман язуы (каллиграфия) өчен еллык 400 сум белән мөгаллим итеп билгеләнде. 1861 нче ел 1 нче апрельдә һәм шул көннән башлап крестьян вә налог түләү сословиесеннән чыгарылып, дәүләт хезмәтендә дип хисап ителде. 1862 нче ел 13 августта Сенат указы, патша фәрманы белән барлык хокукына ия булган хәлдә Шәрекъ телләре факультетына лектор итеп билгеләнде. 1863 нче ел 1 нче сентябрьдә 1866 нчы ел 22 мартта Мәгариф министрлыгы тарафыннан бирелгән фәрман буенча гыйльми хезмәте өчен биш айга кыргыз сахраларына сәяхәт итәргә җибәрелде. 1866 нчы елның 1 апрелендә шул сәфәреннән кайтып килгән вакытында Сембер губернасында вафат булды, 1866 нчы ел 28 августта. Сугышта булмады. Хөкем ителмәде. 1862 нче ел 30 апрельдән башлап дүрт ай һәм дә 1863 нче ел 29 көн отпускада булды. Хатыны – Фатыйма Яхъя кызы, балалары: Гайшә, 1855 нче ел 8 нче октябрьдә дөньяга килгән; Зәйнәп, 1860 нчы ел 7 нче октябрьдә дөньяга килгән; Әминә, 1862 нче ел 25 нче октябрьдә дөньяга килгән. Хатыны вә балалары үз янында бергә, барысы да ислам динендә».

Сабачай авылында дөньяга килеп, Бәрәскә авылында Габдеррәхим бине Бикчәнтәй хозурында, аннан соң Казан шәһәренә килеп Мөхәммәткәрим бине Мөхәммәтрәхим әт-Тәкәнеши вә Байморад бине Мөхәррәм хозурында белем алган. Моннан соң Шиһабеддин бине Баһаведдин әл-Мәрҗани мәдрәсәсенә кереп югары дини белемнәрне өйрәнде.

Шәкертләре: Кәлимулла бине Әмин әс-Сабачайи, Биниәмин бине Әмин әл-Исәки, Хәбибулла бине Мөхәммәт бине Салих, Галим бине Әмин һәм башкалар. Бу затлар Казандагы вакытында укыган булсалар кирәк.

Үзе ифрат дәрәҗәдә зирәк һәм сакчыл, яхшы холыклы булып, һәм дә гайрәтле, тугры фикерле вә һиммәтле, дөрес гыйлемле һәм гадәттән тыш акыллы, фазыйль вә саф күңелле, өстенә алганны үтәүче, вәгъдәсендә торучы, рас һәм ачык сүзле, диндар вә инсафлы, китап укырга хирыс, зур дин китапларын укыган, философларның максатын дөрес аңлый, зиһенле милләтпәрвәр бер мөхтәрәм зат иде диләр. Тарих гыйлеменә булган кызыксынуы шул дәрәҗәдә булган ки, русча язылган әсәрләрдән файдалану һәм үзенең электән туплаган мәгълүматы белән чагыштыру нияте белән рус телен өйрәнергә керешкән вә чиксез зур тырышлыгы нәтиҗәсендә бу максатына ирешкән.

Казан шәһәрендә булган кайбер Шәрекъне өйрәнүче галимнәр белән аралашып йөрүеннән һәм аларга да һәрвакыт язу эшләрендә булышканлыктан кайбер әсәрләренең шулар исеменнән басылуын уйлаучылар бар. Болардан кайберләренең өндәвенә күрә, 1259/1853 елда Петербург шәһәренә барып, университетта Мәшрикъ телләре факультетында гарәпчә, төркичә телләр мөгаллиме буларак билгеләнде. Соңрак үпкә авыруы белән хәстәләнеп, асыл ватаны – Сабачай авылына кайтканда әҗәле ирешеп, вафат булган.

Госманлы солтаннары, рус патшалары, Кырым ханнары арасында булган рәсми хатлар тупланган гаять кыйммәтле бер әсәре басылуы сөйләнсә дә, бик табарга тырышуыбыз соңында да безгә күрергә һаман насыйп булмады. Тарих хакында һәм Русия мәдрәсәләре турында язган әсәрләре үз вафатыннан соң юкка чыкканлыгын сөйлиләр.

Төркия язучыларының берсе: «Бөек адәмнәрнең бөеклекләре кайчагында вафатларыннан соң аңлашылыр; шуның өчен хакыйкатькә тугрылыклы булганнар бүгеннән соң Фәезхан улы Хөсәен әфәндене рәхмәт илә яд итәчәкләр» дигән.

Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Петербург шәһәренә күчү ниятенә керүен белүемнән соң һич җибәрәсем килмәде, төрле сәбәпләр күрсәтеп, бу морадыннан кире кайтармак булдым, аннан муафыйк урыннар һәм яшәү өчен җиңел булган гайре юллар күрсәттем, фәкать теләгәнемә ирешә алмадым, ул исә Петербург шәһәренә китте. Ләкин аның анда булуыннан мин дә һич фикер итмәгән файдаларын күрдем. Үзе сәламәт күңелле һәм гүзәл холыклы, хуш табигатьле, язуы матур, фикъһ вә

ысулел-фикъһ фәннәрендә зур өстенлеге бар иде. Гомуми һәм хосусый тарихларны белүе җәһәтеннән бер заманнарда мөселманнарның дәүләт вә шәүкәтләре, һөнәр вә сәнгатьләре, гыйлем һәм мәгърифәтләре, хөррият вә гаделлекләре, камиллек вә сәгадәтләре, байлык һәм сәүдәләре гаять югары дәрәҗәдә булганлыгын вә абруйлары да Мәшрикъ илә Мәгъриб арасында эшләгәнлеген, сүзләре дә муафыйк һәм каршылар арасында үрнәк булганын вә бу көндә исә тәмам моның киресенчә — мөселманнарның зәгыйфь, хур һәм түбән вә фәкыйрь төшкәнлекләрен белер, бу җәһәттән янар һәм көяр иде. Моңа сәбәп исә һичкем булмыйча, бәлки үзләренең һөнәр вә сәнгатьләрдән һәм дә иҗтимагый тормыштан вә үзара низаглары фәлсәфәләреннән мәхрүм торулары һәм бу мәхрүмлеккә, мәктәп вә мәдрәсәләре тәртипсез буларак, дәресләренең дә файдасыз схоластикалардан гыйбарәт булган, хакыйкый гыйлемнәрдән хәбәрдар булмауларын белер иде. Шуның өчен мөселманнарны сәгадәткә ирештерү һәм тәрәкъкый юлына юнәлтү иң элек мәктәпләрдән башлануын теләр, якут вә алтын булачак кешеләрне йомшак бәхәсләр укыту сәбәбеннән кара таш булып калуларыннан саклау өчен киң вә тирән фикерләр йөртер иде һәм дә мәдрәсә вә дәресләрне ислах итү өчен мондый тәртипне монасыйб күрер иде:

«Дәүләттән рөхсәт алып Казан шәһәрендә мөселманнарга махсус бер мәдрәсә оештырылыр. Һәрбер фән өчен бер мөдәррис һәм һәрбер мөдәррис өчен бер фән тәгаен ителеп, дәресләр тәртипкә куелыр. Шәкертләрнең әхвале, мәктәпнең идарәсе, кыскасы, барлык кагыйдәләре Русия, Төркиядә булган тәртипле мәктәпләргә охшатып корылыр. Моның чыгымнары өчен акча дәүләт хәзинәсеннән соралыр. Әгәр хәзинәдән бирелү мөмкин булмаса, дәүләт рөхсәте илә мөселман халкыннан җыелыр. Бу мәдрәсә хозурында зур һәм яхшы рәвештә бер мөселман матбагасы оештырылып, гаять төзәтелеп вә яхшы сыйфатта мөселман әсәрләре бастырылыр һәм матбагадан хасил булачак файда мәдрәсә казнасына кушылыр» диер иде. Бу турыда бөек кешеләр белән киңәшеп йөрсә дә, теләктәшлек итүче булмады, сүзен дә аңламадылар. Көнләшүчеләре исә халыкка аның максатын бөтенләй киресенчә аңлатып, биздерү юлына керделәр һәм, әлгайазе билләһи, гүя ислам зарарына тырышучы итеп күрсәттеләр һәм ничәмә-ничә яла вә ялганнар тараттылар. Ләкин, минем фикеремә күрә, әгәр дә мондый бер мәдрәсә дәүләт чыгымнары белән ачылачак булса, әлбәттә,

фәлсәфи гыйлемнәр рус телендә, дәүләт тарафыннан тәгаен ителгән рус мөгаллимнәре тарафыннан укытылыр, бу тәкъдирдә рус мөгаллимнәре мондый гыйлемнәрнең элек мөселманнарда булганлыгын бик тә белдермәсләр, бәлки һөнәр һәм сәнгать гыйлемнәреннән мәхрүм булганлыкларын күрсәтүгә гайрәт итәрләр. Бу сәбәптән шәкертләрнең исламга мәхәббәтләре аз булыр һәм һәрбер гореф вә гадәтләрендә рус мөгаллимнәренә иярерләр. Шуңа күрә, теләнгән файда күрелмәс» дигән.

## *Фикерләү*

Мондый мәдрәсә оештырылган тәкъдирдә, ихтимал ки, фазыйль Мәрҗани бәян иткән хәвефләр дә булыр. Фәкать безнең уебыз андый түгел. Дөньяда яхшылык яки яманлык кушылмаган нәрсә, хосусан, гомумгә бәйле нәрсәләрдә гаять сирәк була. Бу тәкъдирдә гомуми файда китерәчәк эшләрнең вак зарарларына күз йомыла. Шулай ук моның киресе буларак, аз файдасы өчен гомуми зарар кабул ителмәс. Фаразланган мәдрәсәбездә русча һәм башка яңа фәннәр мөгаллимнәре укучы мөселманнар арасыннан билгеләнер. Теләгәнгә каршы буларак руслар билгеләнсә дә, моннан зур бер хәвеф юк, чөнки рус теле белән укытылачак яңа фәннәр, табигый буларак югары сыйфатларда, үз диннәрен тулаем белгән һәм фикер иясе булу өчен мотлакан мөселманлык белән яңача фәлсәфәне бер-беренә аралаштырырга кирәк дигән инану зиһеннәренә урнашкан шәкертләргә укытылыр. Бу дәрәҗәдә булган шәкертләрнең ул тарафка да, бу тарафка да авышачаклары һәрникадәр ихтимал булса да, куркынычлы ихтимал түгел. Үз мөселман кагыйдәләрен дөрес аңлаган бер шәкерт, кемнән укыса да укысын вә ни җирдә һәм нинди телдә булса булсын, гыйлем һәм фән сәбәбеннән диненнән мәхәббәт алуы шулай торсын, бәлки, хыялларга килмәслек сурәттә, исламга мәхәббәт баглар. Гыйлем һәм фән юлында ара азайган саен исламга мәхәббәт якынаер. Ислам өчен куркыныч дип уйланылса да, бу да гыйлем һәм фән тарафыннан түгел, бәлки наданлык тарафыннан булачагы һәркемгә мәгълүм булса кирәк. Фәкать кайбер вакыт укучылар арасында да ялгышучылар булыр, хәтта кайбер затлар пәйгамбәр заманында Рәсүлулла әфәндебез хозурында ислам дине белән нурланып,

соңында, Алла сакласын, һидайәттән-тугры йулдан кире дүнгәннәр. Һидайәт мәсьәләсе – башка бер мәсьәлә. Укыган адәмнәрнең ялгышулары чынлыкта гыйлем һәм фән сәбәбеннән булмыйча, бәлки икенче бер сәбәпләргә нигезләнә, безнең сүзебезгә каршы килми. Укымышлы бер затның гыйшык бәлаләре этәргеч биреп, киртәдән сикерүенә укыганлыгын сәбәп итеп күрсәтү – мантыйкый дөрес түгел. Бу юлда дөрес бер дәлил китерү – уку сәбәбеннән ялгышканнар белән наданлык сәбәбеннән ялгышучылар арасында тугры бер тиңләштерү кирәклегеннән. Мин дә гомеремнең зур бер өлешен мөселман мәдрәсәсендә кичердем, башкалар белән бәрабәр ислам гыйлемнәренең ысул һәм фәлсәфәләреннән көчем җиткән кадәр хәбәрдар булдым, фәкать Коръәни шәриф һәм хәдис, кыскасы ислам диненә турыдан-туры ләззәтле мәхәббәтем вә камил ихласым Көнбатыш философларының әсәрләренең тәрҗемәләре аша файдаланганнан соң мәйданга килде. Һәрхәлдә, Русия мөселманнары тарафыннан бер заманнарында мәдрәсәи көллийә (университет) ачылачагы ерак ихтимал түгелдер. Фәкать мондый зур эш Казан шәһәрендә вә Казан мөселманнарыннан көтелмәс. Чөнки аларда гади халыкта да һәм укымышлыларында да әхлакый бозыклык таралганлыктан мондый нәрсәне мәйданга чыгарулары бик ерак. Бәлки була калса, Урал мөселманнары тарафыннан булыр, алардан көтәргә мөмкин. Бары да Алла хөкемендә.

Хөсәен әфәнде тарафыннан язылган кайбер мәкаләләр рус әдипләре тарафыннан да мактауларга лаек булды. Бу җөмләдән Ашмарин исемле зат үзенең «Болгар һәм чуашлар» әсәренең 69 нчы битендә: «Березин мәкаләсе чыкканнан унбер еллар үткәч тагын өч данә кабер ташы табылды, боларның икесе Сембер вә берсе Тәтеш өязендә. Бу ташларны мулла Хөсәен Фәезхан улы табып, болар турында Император карамагындагы Археология җәмгыяте хәбәрләренең 1863 нче ел, 4 нче санында «Өч Болгар кабер ташлары язулары» исемендә бер мәкалә язган иде. Бу мәкаләсендә Хөсәен әфәнде Болгар кабер ташларын чуаш теле ярдәме белән өйрәнү юлын беренче мәртәбә буларак дөньяга хәбәр биргән иде. Шуның өчен бу мәкалә гаять әһәмиятле. Хәлбуки, моннан элек Болгар кабер ташларын өйрәнүчеләргә чуаш теле ярдәме белән тикшерү хәтерләренә дә килмәгән» дип бер мәкалә язган.

Петербург шәһәреннән үзенең остазы булган фазыйль Мәрҗанигә язган

хатының кайбер урыннары бу җирдә бастырыла. Мәсәлән, «Сез изге зат безгә ничә мәртәбә хатлар җибәрсәгез дә, мин Сезгә рәхмәтләр укып ун тапкыр артыграк язсам да, һаман кимчелегем булыр иде. Мин фәкыйрьнең әхвален сорасагыз, һәр хосуста элеккечә, ләкин Сез изге зат кебек хуш күңелле һәм гүзәл табигатьле кешеләр булмавы һәммә ләззәтләрне харап итә.

Башкала Петербургта туган кызга 1855 нче елның гыйнвар башларында өйләндем, Аллаһы Тәгалә хәерле итсен!

Минем килерем бер җирдән 240 һәм икенче бер җирдән 250 сум иде. Әмма бу кыш 250 сум алган хезмәтебез туктатылды, аның урынына икенче урын өмет ителә. Биниәмин университетта хаттатлык хезмәтенә керде, сентябрь башыннан елга 400 тәңкә вазыйфа тәгаен ителде. Язуга күп сәләте бар. Мәхмүдевтән күпкә өстенрәк дип уйланыла, хатт-почеркларны кагыйдәләре белән яхшы яза. Нәсех, тәгъликъ хаттлары гүзәл. Үзе рус теле грамматикасын өйрәнеп, русчаны яхшы яза башлады, мәгърифәт хасил итәргә һәвәсле. Миннән нәхү, сарыф өйрәнә.

Мәшһүр Европа галимнәреннән барон Сильвестр де Саси[2] исемле кешенең «Шәрхе мокамат»ен ун тәңкәгә сатып алдым. Мисыр басмасын табу кыен, чөнки Русия дәүләте илә Госманлы дәүләте арасында барлык бәйләнешләр тыелган. Бу гаугалар[3] китап алышуны күп кыенлаштырды...»

Икенче бер хаты бу: «Данлыклы, хакыйкать билгесе – изге остазыбыз хәзрәтләренең хозурларына ихласыбызны күндереп, бу тарафны, әлхәмделилләһи, сау-сәламәт дип белерсез. Ләкин шәгъбан ае 5 нче көнендә газиз әтиебезнең вафат хәбәрен алып бик хәсрәткә төштем. Мөхтәрәм җәнапләрегезнең ике хатыгызга бу вакытка кадәр җавап язарга вакыт мөмкинлеге булмады, һәр хәлдә игътибарсызлыгымны кичерегез. Коръәни шәрифне Сез әйткәнчә төзәтеп бастыру кирәк иде. Бу безнең җирдәге Коръәннәр һич ярый торган түгел дип, бер елдан артык бу фикер минем башымда булган иде. Чөнки Сез әйткән сүзләрне мин Суйутиның бер

---

[2] Сами бәк бу затны «Камусел-әгълам»дә һәр фәннән хәбәрдар зур галим дип сыйфатлый. 1838 елда вафат. – *Р. Ф.*

[3] Севастополь сугышын күздә тотса кирәк. – *Р. Ф.*

әсәрендә вә Кятиб Чәләбинең «Кәшфез-зөннун»ында күргән идем. Әлхәмделилләһи, инде Сезнең хатыгыз килгәч бик куандым. Күп яхшы, хәерле истәлек калдырасыз икән. Коръәни шәрифтән башка китапларны да чагыштырып төзәтү бик мөшкел эш, дүрт вә биш мәртәбә яхшы фикерләп, укып чыккач та хатадан котылып булмый. Бер мәртәбә бер Коръәнне яхшы итеп бастыргач икенче вакытта сәләтлерәк шәкертләрегездән бер-икесенә беренче һәм икенче тапкыр чагыштыруны йөкләп, өченче, дүртенче мәртәбәсен үзегез кыйлсагыз, ул вакыт җиңелрәк булыр.

Золымлык турында язган хатыгыз хакында бүгеннән христианнарның ураза вә бәйрәмнәре булу сәбәпле белешә алмадым, белмим, монда килдеме икән? Тиз вакыт белешермен.

«Вафийәт»гезне[4] язып акка күчерергә керешкәнсез икән, Аллаһы Тәгалә тәмам итүне насыйп кыйлсын! «Риҗале Җәбәрти»гә хәтле күп эшләр бар. Аллаһы Тәгалә насыйп итеп, киләчәк ел Истанбул сәфәре насыйп булса, инша Аллаһ, укырбыз. «Табакате сөннийә» Истанбул көтепханәләренең күбесендә бар. Минем уемда, укып тәмамлаганнан соң бер исемнәр күрсәткечен язарга кирәк. Вә аннан җиңеллек белән файдаланучы булмас. Мәсәлән, «Гайнел-казат әл-Һәмәдани»да күрдем... дип һәм шундыйлар. Һәм иң муафыйк төзәтүдә игътибар итеп хашиясендә географик урынын бәян итү. Әгәр хәзерге вакытта исеме башка яки вәйран булса, аны да бәян итү артык булмас.

Миңа быел Истанбул сәфәре насыйп булмады, инша Аллаһ, киләчәк елда өмет бар. Оренбург тарафына баруны карар кылып торам. Инша Алла, май числосы урталарыннан да калмамдыр. Ханкирмәнгә дә керергә эшем бар. Хәзергә ниятемнән кире кайтканым юк, башта Ханкирмәнгә барып, бер-ике атна торып, аннан соң июнь башыннан Казанга барырмынмы яки туры Оренбургка барып, кайтуда Мәкәрҗә аркылы Ханкирмәнгә барырмынмы? Һәр тәкъдирдә Казанда бер атна кадәр торып булса иде. Һәм кайбер авылларга чыгарга ният кылдым. Җәнабегез игътибар биреп, бу хатны алгач та бер хат илә мине шатландыруыгызны өмет итәм.

Сез гүя минем яңа фатирымның адресын оныткансыз, әүвәлге фатирыма

---

[4] «Вафийәтел-әсляф вә тәхийәтел-әхляф» китабын күздә тотса кирәк. – *Р. Ф.*

язылып, хат кичегеп килә. Болай язгыгыз: Санкт-Петербург Петербургская сторона Съезженская улица, дом № 4 Журиной (мулла Хөсәен Фәезханов).

Гайде фытырны дүшәмбе көнне кылдык. Дога өмет итеп: фәкыйрь Хөсәен бине Әл-Фәез.

Чәршәмбе көн, 24 апрель, 1860 ел».

## 407. Мөхәммәднәҗиб бине Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри

38 яшендә 1283 (1866) елның рәҗәб аенда Казанда вафат булып, атасы янында күмелде. Баласы вә хатыны юк иде.

Остазлары: атасы Байморад бине Мөхәррәм, Шиһабеддин бине Баһаведдин әл-Мәрҗани, Бохарада Габделмөэмин бине Үзбәк әл-Бохарый һәм башкалар. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Мөгамәләсе гүзәл вә хуш иде, язуга оста, аңлавы дөрес, сүзе матур, зиһене камил, киеме тәртиптә, ягымлы вә юмарт бер зат иде. Фәкать беркадәр ялкаулыгы вә кайбер хак сүзләргә каршылыгы юк түгел иде. Атасы хәстәрлек белән көн кичергән хәлдә, бу кемсә иркен торыр вә чыгымлы мәҗлесләр уздырыр иде. Атасыннан зур байлык калган булса да, күп нәфис китаплар вә газиз әсәрләр җыйды, бу юлда бөтен байлыгын фида итеп, зур бурыч астына керде. Бохарада унике еллар торып, Казанга кайтты вә кияве Габделвәли бине Йосыф ханәсендә бер ай вакыт торганнан соң вафат булды», – дигән. Аның хакында Гаяседдин бине Хәбибулла әл-Казаный бер мәрсия сөйләгән иде («Мөстафадел-әхбар»ның икенче кисәк, 90 нчы битенә мөрәҗәгать итегез).

// [444]

## 408. Төхфәтулла бине Хәлил бине Сәгыйдь

Тау ягында Шәмәк исемле авылда имам булып, 65 яшендә 1283 (1866) елның рәҗәб ахырында (22 ноябрь) кинәт кенә вафат булды. Җәмгыяте шәргыягә әгъза булыр өчен Казан вилаяте галимнәре тарафыннан сайланып, Уфа шәһәренә килгән иде. 1848 елда имзалаган кәгазьләрен күрдек.

**409. Һибәтулла бине Сәедбаттал бине Салих бине Бикмөхәммәд бине Ишмөхәммәд**

Сәгыйдь бистәсендә 73 яшендә 1283 (1867) елның рамазан аенда вафат булды. Мәхтүмә исемле хатыныннан – Мәхбүбә, Кәримә, Фатыйма, Гафифә, Гаишә исемле балалары, Шакирә бинте Мөхәммәджан исемле хатыныннан Хәләф, Шәрәф, Габделхак, Җәмил, Сара исемле балалары бар иде. Хаҗивафа бинте Габделҗәмил исемле хатыны өйләнешкәннән сон фәкать ике ай торып вафат булганыннан, баласы калмады. Шушы хатынына артык күп мәхәббәте булганга, вафатыннан соң олы хәсрәт чикте, газәл вә мәрсияләр иҗат итте. Латыйфа бинте Дәүләтшаһ бине Гаделшаһ исемле хатыныннан Мәстүрә исемле кызы бар иде.

Остазлары: Мәгаз бине Габдулла әл-Карамалый әл-Орый, Мөхәммәделәмин бине Габделбакый әс-Сәгыйди, Вәлид бине Мөхәммәделәмин бине Сөләйман әс-Сәгыйди, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади. Дәүләтшаһ бине Гаделшаһ хәзрәтләреннән тарикатьтә рөхсәт алып, үзеннән Нигъмәтулла бине Габдеррәхим, Исхак бине Солтанхуҗа, Гыйсмәтулла бине Әл-Хөсәени, Мөхәммәдмөҗавир бине Габделкаһир әл-Муйнакый исемле затлар тәрбияләнеп, рөхсәт алдылар. Әсәрләреннән «Мәҗмәгъ әл-әдәб», // [445] «Төхфәт әл-әүләд» исемле китаплары кабат-кабат басылды. Башка шигырь вә касыйдәләре күп булса да, без күргәннәрдән иң гүзәле «Мәҗмәгъ әл-әдәб»тер. Үзе матур сүзле, тугры җаваплы, сабыр вә тыйнак, гүзәл холыклы вә йомшак вәгазьле, җәмәгать намазын калдырмаучы, нәсыйхәтләре тәэсирле бер зат иде. һәр намаздан кайтканында өендә булган әһелләреннән: «Намазыгызны укыдыгызмы?» – дип сорар вә һәр кич ястүдән соң балалары вә әһелләре янына барып: «Мин сездән риза, сез дә миннән риза булыгыз!» – дип ризалашып ята иде, диләр.

Асыллары Чистай өязе Тахталы авылыннан булып, Сәгыйдь бине Гаед исемле кемсә Сәгыйдь бистәсен бина кылганда, аның белән бәрабәр Салих бине Бикмөхәммәд күчеп килгән. Сәедбаттал Чебенле авылында гыйлем әһелләреннән булып 1248 елның зөлхиҗҗә аенда вафат булды. Үзе дә яшьлегендә Чебенледә имам булып, шәех Дәүләтшаһ бине Гаделшаһ Курса авылыннан күчеп килгәннән соң, аның дәресенә йөргән. Соңыннан Сәгыйдь бистәсенә өченче мәчет имамлыгына күчеп,

унбиш еллар гомер кичереп вафат булган. // [450]

**410. Әхмәд бине Сәгыйдь бине Әхмәд бине Йосыф әш-Шырданый**

Казан шәһәренең бишенче мәчетендә имам булып, 80 яшендә 1284 (1867) елның сәфәр аеның 1 нче көнендә (23 май) вафат булды. Баласы булмады, нәселе калмады.

Остазлары: атасы Сәгыйдь бине Әхмәд вә абыйсы Габделгаффар бине Сәгыйдь, моннан башка Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавый, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый, Таһир бине Сөбханкол әл-Адайи, Бохарада Гыяс бине Захир, Гайсә бине Рәхмәтулла, Габделгазиз бине Габделгани һәм башкалар. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Холкы хуш вә мәҗлесе ләззәтле, тугры игътикадлы вә дөреслекне аңлаучан, тырыш вә түземле иде, кешене рәнҗетмәс иде. Озын гомер сөреп, аның кебекләр [яшьтәшләре] беттеләр, шул сәбәптән Казанда галимнәр вә байлар каршыңда ихтирамы зур иде, ләкин гыйлем өлкәсендә тиешле дәрәҗәдә тырышмады, дәрес белән шөгыльләнмәде, байлар мәҗлесен яратыр вә аларны мактар иде. Бөтен Казан халкы бергә җыелып, 1276 елда ике бистә арасында корбан гаете укыганда, килешү нәтиҗәсендә имам булды», – дигән. Казан төркиләренең беренче мәртәбә мәйданга чыккан мөхәррирләре Габделкаюм бине Габденнасыйр әфәнденең остазы шушы зат иде, диләр.

**411. Вилдан бине Сәгъди бине Максуд бине әл-Мөхәммәд бине Исмәгыйль әт-Туймый**

Уфа ягындагы Туймы авылында имам булып 63 яшендә 1284 (1867) елның 3 җөмадиел-әүвәлесендә (28 август) вафат булды. Хатыны Фатыйма бинте // [451] Мөхәммәдҗан бине Мәхмүд булып, Гайнан исемле фазыйль бер улы калды.

Остазлары: Динмөхәммәд бине Габделбакый әл-Минчәши һәм башкалар.

Шәкертләре: Фәхреддин бине Үтәгән әл-Мәнәиси, Габделихсан бине Фәтхулла әл-Мөслими, Зиннәтулла бине әл-Юкәли һәм башкалар. Зирәк вә тугры зиһенле, күп гыйлемнәр белән таныш, бигрәк тә нәхү [грамматика] вә фикъһ фәннәрең яхшы белә иде. Фарсы телендә маһир булып Җәлаледдин әр-Руми «Мәснәви»енә гашыйк булып,

даими укый иде. Баштарак дәресләрен тырышып, өзлексез укытса да, соңрак авыруы сәбәпле хезмәтенә шактый зәгыйфьлек килде, диләр.

### 412. Әбүйәзид бине Әднакол бине Бигем мирза бине Гыйшмәнд бине Урай бине Әлмәт бине Арыслан

Казан өязенең Олы Әтнә исемле авылында имам булып, 1284 (1867) елның рәҗәб ахырларында (8 ноябрьдә) вафат булды. Яше 110 иде, диләр. Наласа авылында имам булган Фәхреддин моның улы иде.

### 413. Әүхәди бине Искәндәр бине Сәгыйдь

Казан ягында Иске Җөлби авылында имам вә мөхтәсиб булып, 58 яшендә 1284 (1867) елның шәгъбан ае ахырында (6 декабрь) вафат булды. Өч нәүбәт Җәмгыяте шәргыядә әгъза булды. Мөфти Габделвахид бине Сөләйман вафат булгач // [452] мөфти вазыйфасын башкарган Таҗеддин бине Максудның вакыты җитеп, хезмәтеннән чыканнан соң, мөфтилек вазыйфасын башкарып торган. Остазы Кышкар авылыннан Фәйз бине Габделгазиз әл-Кенәри исемле кемсә иде. Хатыны Мәхфуза бинте Таһир бине Ишмирза бине Габдулла иде. Уфа шәһәрендә моның хәлен белүче мирзалар: «Өендә аю асрый иде. Гаять олы бер кеше булып, чиновниклар вә иске алпавытлар гадәтенә ия иде. Урам вә кунакларда йөргәндә хатынының күлмәк итәкләрен асрау кызлар күтәреп йөри иде», – диләр. Асылы Тәтеш өязе Бакырчы авылыннан булып, Казан өязе Җанык Шашы авылында имам иде. Аннан соң Иске Җөлбигә күчте. Атасы Искәндәр Симетбаш авылында имам булып, вафат китте. Урынына икенче улы Садыйк Бохарадан кайтып бераз вакыт имам булып торды, аннан соң өченче улы Кәмаледдин имам вә ахун булып, 1289/1872 елның сәфәр аенда (март) вафат булды.

### 414. Хәсән бине Муса бине Ягъкуб бине Исмәгыйль бине Үтәгән бине Баймирза бине Балтай

Малмыж өязе Саена авылында 26 яшендә 1284 (1868) елның 15 зөлкагдәсендә

(25 февраль) вафат булды. Галимнәрдән булмыйча, бәлки билгеле сәүдәгәрләрдән иде. // [459]

### 415. Мөхиддин бине Хәсән

Самар ягындагы Алты Ата авылында имам булып, 104 яшендә 1284 (1868) елның 12 нче зөлкагдәсендә (22 февраль) вафат булды.

Остазлары: Фәйз бине Габделгазиз әл-Кенәри, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, // [460] Үзбәк бине Сөбханкол әс-Сәгыйди, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади, Мәккәдә Габдулла бине Габдеррахман бине Гомәр әс-Сираҗ, Истанбулда Мөхәммәд әфәнде һәм башкалар. Атасы Казан ягы Олы Мәңгәр авылында имам булып торган. Сахибе тәрҗемә Мамадыш ягындагы Чураш авылында дөньяга килеп, дүртенче яшендә ата-анасыннан ятим калган. Соңрак кемнәрнеңдер кайгыртуы нәтиҗәсендә мәктәпләргә йөреп, Сәгыйдь бистәсендә зур остазлар хозурында тәрбия алу насыйп булган. Укуын тәмамлаганнан соң, Бүкәй иленә барып, хан хозурында беркадәр вакыт имам булып торган. Соңрак Хиҗазга сәфәр кылып, Мәккәдә Габдулла әс-Сираҗ дәресләренә йөргән. Каһирәгә килеп кыйраәт гыйлемен үзләштергән. Шулай унбиш еллар гомерен уздырып үз иленә кайтты, Алты Ата авылына имам булып билгеләнде. Фарсы вә гарәп телләрендә оста вә бернинди тоткарлыксыз дөрес вә матур сөйли иде. Йөз яшендә булганда, кайсы урыннан булса да, «Кәфия», «Шәмсия», «Тәнкыйг» китапларын яттан укый иде. Гасырдашлары бердәм рәвештә аның фазыллыгын таныйрлар, авыр мәсьәләләрдә аның белән киңәшерләр иде, диләр. Мөхәммәдвәли исемле улы бүген 70 яшьләрендә, сәламәт, атасы урынында имам булып тора. Бер кемсә безгә: «Мөхиддин хәзрәтнең язган китаплары да күп, ләкин сәяхәтнамәсе бармы-юкмы, белә алмадым. Әмма үз кулы белән язган шәҗәрә вә иҗазәтнамәләре бар, берсе улында вә берсе кызында. Ләкин алар һичкемгә бирмиләр, хәтта сезгә күчереп җибәрү хакында тырышып карасам да, бу ниятемә ирешә алмадым, гафу итәрсез!..» – дип язды. // [461]

**416. Сиражеддин бине Сәйфулла бине Үтәгән**

Кызылъяр шәһәренең беренче мәчетендә имам булып, хаҗ сәфәреннән кайткан вакытында, 55 яшендә 1285 (1868) ел мөхәррәмендә Каһирәдә вафат булды.

Остазлары: атасы Сәйфулла (аның турында инде язылды), Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри, Бохарада Салих бине Надир әл-Хөҗәнди, казый Шәриф бине Гата әл-Бохарый. Үз иленә кайткач, Кызылъяр шәһәрендә имам булды.

Шәкертләре: Әхмәдвәли бине Төхфәтулла әл-Кызылъярый һәм башкалар. Кайбер әсәрләр барлыгы турында риваять кылына.

**417. Җәлаледдин бине Борһанеддин бине мулла Шәриф әш-Шыгайи**

Минзәлә өязе Шыгай авылында имам вә мөдәррис булып, 1285 (1868) ел рәҗәбендә 68 яшендә вафат булды. Кабере Шыгай авылында. Минзәлә өязендә булган имамнарның күбесенә остаз булды.

Остазлары: атасы Борһанеддин бине мулла Шәриф, Габделгаффар бине Сәгыйдь әш-Шырданый, шәехе исә Габделхаликъ бине Ибраһим әл-Курсавый. Моның хакында атасы Борһанеддин бине мулла Шәриф үз каләме белән: «Ошбу 1217 елның 10 шәгъбанында, дүшәмбе кич сәхәр вакытында таң алдыннан улым Җәләледдин дөньяга килде. Мәүләви дип ләкаб куштык, милади исәбе белән 1802 елда», – дип язган.

// [462]

Балалары: Габделвәли, Зыяэддин, Лотфулла, Мәрхәбә, Мәрфуга, Мәсфуфә, Гарифә, Заһидә. Мәрхәбә Дөреш авылында имам Гыймадеддин Сәйфелмөлек никахында, Мәрфуга – Бөре өязе Иске Чокыр авылында имам Мөхәммәдгали бине Габдессалих никахында, Мәсфуфә – Шөкрәле авылында имам Шәрәфеддин бине Габделхаликъ никахында, Гарифә – Бигеш авылында имам вә мөхтәсиб Солтанбәк бине Сагындык никахында, Заһидә Кәүҗияк авылында имам Габделгани бине Мөхәммәдҗан никахында булып, һәрберенең нәселләре бар. Зыяэддин үзенә алмаш булып, имам вә мөдәррис булды, бүген сәламәт. // [471]

**418. Габбас бине Мөхәммәделәмин**

Оренбург ягында Зөбәче [Зубачи] авылында имам вә мөдәррис булып, 79 яшендә 1285 (1868) елда вафат булды. Асылы Богырослан өязе Котлыгмәт [Котлымбәт] авылыннан иде. Шәкерте күп булыр иде, кырык ел дәрес укытты, үзе Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавыйның могтәбәр шәкертләреннән иде, диләр. Гафифә исемле кызы Кәшшаф бине Габделваһһаб исемле имам никахында булып, бүген Алматыда мөдәррис булган хаҗи Мөхәммәдзакир әфәнде анасыдыр.

**419. Дәүләтшаһ бине Мөхәммәдлатыйф бине Зәйнелгабидин бине Юныс**

Бөре өязе Мәскәү авылында имам булып, 75 яшендә 1285 (1868) елда вафат булды.

Остазлары: Фәйз бине Габделгазиз әл-Кенәри, Сәгыйдь бине Әхмәд әл-Казаный әш-Шырданый һәм башкалар. Казан якларында укып кайткач, Юкәле Күл авылында Җиһаншаһ // [472] бине ... [төп нөсхәдә шулай. – *Төз.*] исемле мөдәррис мәдрәсәсендә балалар укытып өч елга якын торганнан соң Мәскәү авылына рәсми имам булып билгеләнде. Кабере шул авылда. Сабыр, фәнгә һәвәсле, кичләрен белем алып үткәрер иде, диләр. Бу кемсә хакында Габделкәбир әфәнде бине Габделмөнир әс-Сикәли: «Дәүләтшаһ хәзрәтләрен яшь вакытымда күреп калдым, йөзендә аксөяклек әсәре чагылган иде. Күргән кешеләр дә моның гыйлемен мактыйлар иде. Габдеррәкыйб бине Габделҗәббар бине Сәйфелмөлек бине Мортазадан: «Безнең бу якларыбызда гыйлем ягыннан Дәүләтшаһ мулланың тиңе юк», – дип мактаганын үзем ишеттем. Бу затлар икесе дә укыган көннәрендә күп урында бер-берсенә иптәш булганнар. Ахыр гомерендә Сарсаз авылында Фәттахеддин бине Габделмәҗид хозурына барып тарикать юлына баскан», – дигән.

**420. Әбелхәер бине Шәммас бине Җәгъфәр бине Бигем бине Биккол бине Ходайбакты бине Җүлкә бине Богдан**

Тәтеш өязе Сүтәк авылында 1804 елда дөньяга килгән вә, шул авылда 37 ел

имам булып, 1285 (1868) елда вафат булган. Остазы Хәмид хәзрәт Юртышый иде.

Балалары: Габделхәким, Мөхәммәдсадыйк, Габделкәрим, Габделәхәд, Бибикәмал, Гаишә, Рәхимә, Маһруйҗәмал, Шәмсеҗиһан, Гарифә.

Габделхәким исемле улы атасы урынына имам булып калды. Остазы Габденнасыйр бине Мөхәммәделәмин Буавый иде. Баласы юк. Мөхәммәдсадыйк әфәнде ун елдан соң абыйсына иптәш имам булды. Габделкәрим исә балалар тәрбия кылып бер мәркәзгә җыеп торган булса да, соңрак сәүдәгә тотынып бу эшеннән ваз кичте. Өчесе дә сәламәт.

Әбелхәер мулланы, әхлагына кызыгып, күрше авыллардагы чуаш, мукшы кебек ул вакыттагы динсез халыклар хайван бугазлау, бәйрәм итү кебек эшләрнең һәрберендә үрнәк итәләр, хәтта йомышлары булса, «мулла абсый заратмый» дип чәч, мыекларын кыскартып керәләр, имеш.

Сүтәк авылындагы иң әүвәлге мәктәп 1880 елларда гына бина кылынганга, Әбелхәер хәзрәт заманында читтән җыелган шәкертләрнең // [479] булмавы гыйлеменең булу-булмавын белергә юл бирми, пәрдә булыр. Шулай булса да, язган китапларының күплеге гыйлемгә һәвәс бер зат икәненә дәлил булып тора. Бу китаплар үзеннән соң булган 4-5 зур янгыннарда барысы да юк булган.

**421. Хөснеддин бине Шәмседдин бине Җәгъфәр бине Сөбханкол**

Эстәрлетамак өязе Балыклы Күл авылында имам вә ахун булып, 102 яшендә 1285 (1869) ел зөлхиҗҗәсенең 1 нче көнендә вафат булды. Шәех Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли кызы булган Мәрзыя исемле хатыны вафат булганнан соң, Мөрес авылыннан Миһран кантонның Хәбибҗәмал исемле кызына никахланды.

Уллары: Зыяэддин, Гыйзздеддин, Фәхреддин.

Остазлары: ахун Гаделшаһ бине Габдулла әл-Эстәрли, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Хөснеддин бине Ибраһим әл-Әначи һәм башкалар.

Шәкертләре: Мөхәммәдрәхим бине Мөнасиб әл-Әлшәйи, Ягъкуб бине Әхмәд әл-Ахундый, Хисамеддин бине Габделкәрим әт-Таубазый һәм башкалар.

Бабасы булган Җәгъфәр «Ждан» дип билгеле булганга (Мәгънәсе нинди? Вә нинди телдә?..), бүген булган балалары «Жданов» дип искә алыналар. Җәгъфәрнең

уллары Сәгъдеддин, Сәйфеддин, Сираҗеддин, Шәмседдин, Хисамеддин, Рәхмәтулла исемле иделәр. Шәмседдин балалары Нәриман, Хөснеддин һәм башкалар.

Хөснеддин ахун үз якларындагы галимнәрнең мәшһүрләреннән булып, шәкерте күп, хөрмәте зур иде, Уфа шәһәренә килгәнендә мөфтиләр хозурында аңа гаять зур ихтирам күрсәтелә иде.

Фәкать Габделвәхид мөфти аңа салкын мөнәсәбәттә булган. Соңрак шәкертләре дә таралып, дәресе тукталган. Һәрвакыт: «Һай, мәдрәсәне караучы булса, укыту белән шөгыльләнер идем!» – дип хәсрәт чигеп // [480] йөргән булган. Китап өйрәнүгә омтылышы бик зур булганга, сирәк вә кыйммәтле нөсхәләрдән күпләрен китапханәсендә булдырткан. Фарсы теленә маһир булып, «Мәснәви», «Гөлистан», «Гөлбостан» китапларын мәхәббәт белән укыр, күп бәетләрен яттан белер, мәҗлесләрдә мөнәсәбәт туры килгәндә шуларны сөйләп, мәҗлес әһелләренең күңелләрен күтәрер, имеш.

Эстәрлебаш шәехләреннән берсенең өендә ерак вә якыннан җыелган мәшһүр, дәрәҗәле кешеләр алдында һич тартынмыйча: «Безнең халкыбызның надан калуларының иң олуг сәбәбе – Бохара шәһәренең гыйлем чыганагы икәненә ышанып, уку нияте белән шунда барулары вә анда ни күрсәләр, сабый балалар мисалында мәмләкәтебезгә гыйлем исемендә китереп сату; дөньяда бер тиенлек файдасы булмаган вә ахирәттә дә үкенечтән башка бер нәтиҗәсе күрелмәячәк нәрсәләрне саф күңелле шәкертләребезгә ятлатып каннарын бозу, әхлакларын табигый хәләтләреннән чыгарудыр», – дип озын бер нотык сөйләгәне билгеле. // [481]

## 422. Мөхәммәд Хәлилулла бине Мөхәммәд Гофранулла бине Мөхәммәд Ризванулла бине Мөхәммәд Борханулла бине әш-шәех Нурыләхәд бине әш-шәех Шаһмөхәммәд Фәкыйрулла бине Шаһмөхәммәд Яхъя бине әл-имам әр-Раббаный шәех Әхмәд әл-Фарукый әс-Сирһинди ән-Нәкышбәнди

1285 (1865) елда Бохара шәһәрендә вафат булды. Сахибзадә буларак билгеле булган ишан. Хуканд шәһәрендә шәехлек итте, хаҗ сәфәренә барганында Казан шәһәреннән үтеп йөрде. Фәтхулла ахун бине әл-Хөсәен әл-Орыйның Фатыйма исемле кызына никахланды. Хукандка кайтып киткәненнән соң бераз вакыт үткәч, // [482]

Җәмгыять шәргыядә тикшерелгән дәгъвага нигезләнеп никахлары көчен югалтты.

### 423. Мөхәммәдморад бине Габделкаюм әл-Бәдәхши

Пермь ягындагы Ишмәтче авылында 1286 (1869) елның сәфәр аенда вафат булды. Мирза Рәйхан исемле улы калды. Бәдәхшанда дөньяга килеп, шул тараф галимнәреннән укыган. Тарикать гыйлемен атасы вә Сахибзадә ишаннан алган. Соңыннан атасы белән бергә Һиндстанга барып, Габдулла Голямгали бине Габделлатыйф әл-Голви әл-Һинди әл-Бәнҗаби әд-Дәһләвидән, Хөсәен бине Йосыф әл-Бохарыйдан, аннан соң Мөхәммәдҗан бине әл-Мәккидән, Ташкентта Йосыфхан бине Мансурхан исемле шәехтән рөхсәт алган. Бу якларга килгәч, Пермь ягындагы Сараш авылында торып шәехлек иткән. Тирәсендә тавыш вә талаш булу сәбәпле, аның хакында төрле сүзләр йөреп, хәтта Җәмгыяте шәргыядә эше тикшерелде. Фарсы телендә язылган бер рисаләсен күргәнебез бар. Шәех Мәхмүд әфәнде бине Мөхәммәдсадыйк әл-Алмалы белән иптәш иде. Атасы, Ташкент шәһәрендә ишанлык кылып, «Шәех Караташы » дип билгеле иде.

### 424. Әхмәд бине Габделкадыйр бине Сәйфелмөлек бине Мортаза

Минзәлә өязе Такталачык авылында имам вә мөдәррис булып, 60 яшендә 1286 (1869) елның рабигыль-әүвәл аенда вафат булды. Мирза Заһид исемле улы калды.

Остазлары: атасы Габделкадыйр бине Сәйфелмөлек, Шаһиәхмәд бине Рәфыйк әс-Симәки, Кансареддин бине әл-Бурайи, Казанда Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәһгәри.

Шәкертләре күп булыр иде, гарәп теле фәннәрен белә иде, диләр. Бөре өязе Коры Алачык авылында дөньяга килеп гыйлем туплаганнан соң, Такталачык авылына // [488] имамлыкка указ алды. Аннан Уран Карамалы авылына күчте, соңрак тагын Такталачыкка әйләнеп кайтты. Тамагына сөяк кадалып кинәт вафат булды. Атасы Габделкадыйр Коры Алачык авылында имам вә мөдәррис булып, диндар, намазын саклаучы бер зат иде, диләр. Бабасы Сәйфелмөлек бине Мортаза телгә алынды инде.

**425. Җарулла бине Бикмөхәммәд бине Биктимер бине Котлыгфулад әл-Ишки**

Мамадыш өязе Сатыш авылында имам вә мөдәррис булып, 75 яшендә 1286 (1869) елның 15 шәгъбанында вафат булды.

Балалары: Кәфия, Мөбарәкшаһ, Хуҗаҗан, Мирза Габдулла, Мөхәммәдзакир. Кәфия Лаеш өязе Пәрәү авылы имамы Мөхәммәтхәнифә бине Шәмседдин бине Мөхәммәдъяр никахында иде, Мөбарәкша Сатыш авылында имам. Хуҗаҗан тәрҗемәи хәле үзенә тиешле урында язылыр. Башка уллары да имамнар....

// [489]

Шәкертләре: Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим әл-Казаный әт-Тәкәнеши, Хөснеддин бине Гомәр әс-Суыксувый, Исмәгыйль бине Муса әл-Кышкарый, Җәмаледдин бине Сөбханкол әт-Турый, Сибгатулла бине Бикмөхәммәд әл-Күгәрчени, Мөхәммәд бине Гали бине Ягъкуб бине Хәсән әс-Сатыгшый, Хәйдәр бине Котлыгәхмәд әр-Рәҗәби һәм башкалар. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани дә язган.

**426. Мөхәммәдсадыйк бине Галиәкбәр бине Гайсә бине** // [490] **Ягъкуб бине Габдеррәззак бине Галим хафиз әл-Орый**

Вятка ягындагы Иж заводында имам булып, 70 яшендә 1286 (1869) елның рәҗәбендә вафат булды. Анасы Шәһрибану Әсфәндияр кызы иде. Асыллары Казан ягындагы Оры авылыннан. Атасы Галиәкбәр бине Гайсә Күәм авылында урта мәчеттә имам булып, мәдрәсә тотты вә шәкертләр тәрбияләде. Агасы Шәмседдин бине Гайсә Югары Оры авылында имам иде, сахибе тәрҗемә Шашы авылында имам булып, Казан вилаятендәге булган галимнәрнең сайлаулары нәтиҗәсендә Җәмгыять шәргыя әгъзасы булды. Икенче нәүбәт сайланган иде, әмма Габделвахид мөфти бине Сөләйман тарафыннан Казан губернаторына: «Казыйлык өчен мәдрәсә тотып шәкерт укытучы мөдәррисләр генә сайлансын», – дип язганга, Уфага барудан тыелды. Ләкин үзе Эчке эшләр министрлыгына мөрәҗәгать итеп, сайлануы хаклы икәне исбат кылынганнан соң, Уфага китте. Вазыйфасының вакыты тәмам булганнан соң, Иж заводына имам булып билгеләнде, шул җирдә вафат булды. // [494]

**427. Колмөхәммәд бине Гобәйдулла бине Гомәр**

Златоуст өязе Вәкыйрь авылында имам булып, 82 яшендә 1286 (1870) елда вафат булды. Остазы Сәгъди бине Мәксуд әт-Туймый иде. Хатыны Мәхмүдә бинте Сәеджәгъфәр булып, балалары Хаҗимөхәммәд, Мөхәммәдсафа исемле.

Диндар бер зат булуыннан башка, гүзәл вә ышанычлы гыйлеме бар иде, диләр. Шәрәфеддин бине Сәгыйдь әл-Юкәли мәдрәсәсенә барып, күп еллар дәрес укытты. Бу кемсә хакында Гайнан бине Вильдан әт-Туймый: «Гыйлеме гүзәл, фарсы телен яхшы белә иде; сүзе ләззәтле, холкы күркәм, үзе әдәпле иде; гасырында тәкъвалыгы вә тугрылыгы белән шөһрәтле иде; соң көннәрендә аның белән сөйләшеп аралашу бәхетенә ирештем», – ди.

**428. Сәйфулла бине Мирсәлим**

Касыйм шәһәрендә 72 яшендә 1287 (1870) елның 3 мөхәррәмендә (25 март) вафат булды. Костров дигән мәшһүр фамилиядән бер сәүдәгәр һәм хаҗи иде. Касыйм шәһәрендә 1868 елда зур бер мәдрәсә оештырып, шәкертләр һәм мәдрәсә вә мөдәррисләр файдасы өчен дип Пенза вилаятендә Кашкаука исемле урында 145 десятинаны вакыф иткән. Шул вакыфны һәм мәдрәсәнең бинасын, җирен 1869 елда нотариус идарәсендә раслаган. Бу мәдрәсә бүгенгә кадәр могтәбәр мөдәррисләр җитәкчелегендә булып, гүзәл шәкертләр җитештереп тора. Пенза, Саратов, Сембер вилаятендә булган имамнарның күбесе шушы мәдрәсәдән чыккан затлар.

// [495]

Сәйфулла хаҗиның Хисамеддин, Хәйрулла исемле уллары бар иде. Болар хәерле дәвамчылар булып, аталарының теләгенә муафикъ рәвештә шул мәктәпне гүзәл тәрбия кылдылар, кирәк булган иганәләрдән мәхрүм тотмадылар, диләр. Хисамеддин 1894 ел шәгъбанында (4 февраль) вафат булды, 63 яшендә иде. Хәйрулла исә шушы елның шәүвәлендә (4 апрель) 68 яшендә вафат булды. Әхмәд вә Мөхәммәдфатыйх исемле уллары калды. Ислам милләте өчен эшләнгән хәер гамәлләре сәбәбеннән бу җирдә тәрҗемәсе китерелде.

## 429. Габдеррәкыйб бине Габделҗәббар бине Сәйфелмөлек

Бөре өязе Ләяшты авылында имам булып, 1287 (1870) елның мөхәррәмендә (17 апрель) вафат булды. Кабере шул авылда. Казан тарафында вә Казан шәһәрендә күп мәдрәсәләрдә укып йөргән булса да, күбрәк файданы Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри хозурында алган. Бу кемсә хакында Габделхәбир әфәнде бине Габделмөнир әл-Ишкаравый: «Габдеррәкыйб хәзрәтне галим, төрле фәннәр белүче иде, диләр. Ләкин ни сәбәпледер укыту белән шөгыльләнмәде, хәтта остазы булган Байморад бине Мөхәррәмнең: «Габдеррәкыйб гыйлеме минем гыйлememнән күп мәртәбә артык», – дип мактаганы риваять кылына», – дигән. // [496]

## 430. Гыяседдин бине Хәбибулла бине Рахманколый

Казан шәһәрендә дүртенче мәчет хозурында имам вә мөдәррис булып, 40 яшьләрендә 1287 (1870) елның рабигыль-әүвәл аенда вафат булды. Казан зиратында җирләнгән. Габдеррахман исемле бер улы калып, икенче елның шәүвәлендә 5 яшендә вафат булды. Шуның белән сахибе тәрҗемәнең нәселе киселде. Анасы Бакырчы авылында имам Әхмәд бине Бәхтияр кызы Сафия иде.

Нәмүзәҗ укыган вакытларында остазы булган атасы Хәбибулла бине Рахманколый вафат булу сәбәпле, фазыйль Марҗанидә дәрес алган. Кызыксыну вә дәрт белән тырышып укыганына күрә, үз яшьтәшләреннән өстен булып, һәркем көнләшерлек дәрәҗәдә камиллеккә иреште. Соңрак иске мәдрәсә бинапары тузып, яңалары әле җитешмәгән вакытта Мәчкәрә авылында Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый мәдрәсәсенә барып, өч ай шунда торган. Аннан кайтып, остазының киңәше белән Бохарага сәфәр итте. Анда исә Габделмөэмин бине Үзбәк әл-Әфшәнҗи әл-Бохарый мәҗлесенә кушылып, шул шәһәрдә җиде еллар чамасы гомер кичерде. Үз иленә кайтканнан соң ун еллар дәрес укыту белән шөгыльләнеп, вафат булды. Язуы дөрес вә гүзәл, үзе табигый сурәттә шагыйрь булып, кинәт кенә [экспромт рәвештә] шигырьләр сөйләр иде, имеш. Шигырь вә мәрсияләре «Мөстафадел-әхбар»да китерелгән. // [502]

Ышанычлы вә төпле гыйлемгә ия булганнарның, милләтебезгә хезмәтләре өметле булганнарның яшь вакытларында вафат булулары арабызда гомум бер

кагыйдә булып бара. Сахибе тәрҗемә дә шулай, яшьлегендә булды да китте.

Шәкертләре: Нургали бине Хәсән әл-Буавый, Шакир бине Габделҗәббар әл-Буавый һәм башкалар.

# УНБИШЕНЧЕ КИСӘК

## ١٥ نچی جزء

**431. Харис бине Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли**

Уфа ягындагы Эстәрлебаш авылында имам вә мөдәррис булып, 1287 (1870) елның 20 шәгъбанында (ноябрь) вафат булды. Кабере шул авылда. // [505]

Остазлары: атасы шәех Нигъмәтулла бине Биктимер, Бохарада Хәсән бине Хәл һәм башкалар. Үзенә ияргән якыннары: Фазлулла бине Фәйзулла әт-Тактавый, Әхмәдҗан бине Нуриман әл-Әлми һәм башкалар.

Хатыннары: беренче хатыны агасының кызы Зәйнәб бинте Гобәйдулла бине Биктимер, икенче хатыны Габдулла кантон бине Дәүләтшаһ бине Гаделшаһ кызы Фаизә. Соңгысы, минем уемча, бүген сәламәт. Эстәрлебаш авылында булган мәдрәсәләр файдасына булу шарты белән 1895 елда Эстәрлетамак өязе Рәзән волостендә илле десятина җир вакыф итеп, рәсми сурәттә моны раслады. (Собрание архивында булган эше, 1905 ел, 313 нче номер.)

Балалары: Габдулла, Гобәйдулла, Хәбибулла, Шакир, Габделмәҗит, Габделкадыйр, Зөбәйдә, Зәһрә. Зөбәйдә исемле кызы абыем улы Габдеррахман бине Хәбибулла белән бергә 1321 елда хаҗ сәфәренә китеп, 1322 елның мөхәррәм аенда кайтты. Габделмәҗид 1310 елда Мәккәдә хаҗ көннәрендә ваба авыруыннан вафат булды. Башкалары бүген сәламәт. Шакир әфәнде Икенче, Өченче Милләт Мәҗлесләренә Уфа вилаятеннән сайланып, Петербург шәһәренә барды.

Харис хәзрәт Бохарада Гобәйдулла бине Ниязколый әт-Төрекмени хозурында тәрбияләнеп, рөхсәт алды. Аннан кайткач, шәехлек итте. Яраны күп иде, заманының мәшһүр олуглары вә галимнәре аның тирәсенә җыелыр иде. Вафатыннан ун ел алдан хаҗ кылып кайтты. Заһид, диндар бер зат иде, шәкерт тәрбияләргә оста, замана хәлләреннән хәбәрдар иде, Русия мөселманнары өчен дәүләт телен белү шиксез кирәк дип, мәдрәсәләрендә русча укытыр өчен аерым мөгаллим тотты, шәкертләргә рус телен өйрәнергә әмер кылды. // [509]

**432. Әхмәд бине Ихсан бине Гомәр бине Кадермәт бине Сәед бине Ирмән бине Исәнкол әл-Мәмсәви**

Казан ягындагы Мазарбаш авылында имам булып, 1287 (1871) елның рамазанында вафат булды. Шул авыл зиратында җирләнгән. Атасы Ихсан бине Гомәр

Борбаш // [510] исемле авылда имам иде. Анасы Сәлимҗан бинте Шәмседдин бине Хисамеддин бине Габделхәмид булып, Саба авылыннан Җәмаледдин бине Хисамеддин белән бертуган. Хатыны Салавыч авылыннан Һибәтулла бине Динмөхәммәд кызы Нәгыймә иде.

Бу хатыны исә үзе 52 яшендә булган хәлдә 1862 елда өйләнгәненә күрә, икенче никах икәне аңлашыла. Фазыл бине Халид бине Биккол бине Ибраһим әш-Шашый вафатыннан соң шул авылда Орының Мөэмин бай бине Таһир бине Нәзир бина кылган таш мәчеттә имам булды.

Шәкертләре: бертуганы Мөхәммәд бине Ихсан, Габдулла бине Габделгаффар әл-Казаный әш-Шырданый, Габделгани бине Салих әл-Казаный, Хафизеддин бине Насреддин һәм аның абыйсы казый Борһанеддин бине Насреддин һәм башкалар.

Бу кемсә турында фазыйль Мәрҗани дә язган. Вафатыннан соң мәхәллә әһеле Сабир исемле улын имам иткәннәр. Бу кемсә дә 1314 елда 59 яшендә вафат булды. Җеназасын Хафизеддин бине // [511] Насреддин укыды. Агасы Мөхәммәд бине Ихсан бине Гомәр кызына никахланган иде.

### 433. Габделкариб бине Бинияэмин бине Яһүдә әл-Аклуши

Уса төбәге Аклуш авылында имам булып, 1287 (1871) елда вафат булды. Анасы Җәгъфәр ишан бине Габди белән бертуган Фәрхиҗиһан Габди кызы иде. (Атасының тәрҗемәи хәле язылды.) Хатыны Гайнелнәвәл исемле булып, 1853 елның мөхәррәм башында вафат булды. Фәйзеррахман исемле улы атасы урынында имам булды.

Түбәнчелекле, диндар бер зат иде, диләр. Язып тәмамлаган бер китабы ахырына болай язылган: «Моны Габделкариб бине Бинияэмин Такталачык авылында дамелла Габденнасыйр бине мулла Габдеррәхим мәдрәсәсендә 1243 елның җөмадиел-әүвәл аенда язды...»

### 434. Нәҗмеддин бине Зәйнелгабидин бине Габдулла әл-Юлыкый

Орски өязе Ишан авылында имам булып, 75 яшендә 1287 (1871) елда вафат булды. Бохарада укып, тарикатьтә рөхсәт алды. Монда кайткач яран тәрбия итеп, утыз

биш еллар гомер итте. Моның хакында Мөхәммәд әфәнде бине Гыйләҗ: «Шәригатьне белүче, фазыйль бер зат иде; мөридләр тәрбияләгән хәлдә, аларга кушмыйча, үзе игенчелек белән шөгыльләнде. Авылы исә шуңа нисбәтле Ишан авылы дип атала башлады», – дигән.

### 435. Әхмәд бине Халид бине Габид бине Габдулла бине Мөслим бине Бикбулад бине Ишкинә бине Ишбулад бине Шаһфулад

Троицки шәһәрендә Оры авылы бае Мөэмин бай бине Таһир бине Нәзир бина кылган таш мәчеттә имам вә мөдәррис // [512] булып, 1287 (1870) елның шәүвәлендә (27 декабрь) вафат булды. Асылы Казан ягындагы Мәңгәр авылыннан булып, Исмәгыйль бине Габдулла әл-Мәңгәринең бертуганының улы. Бабасы Габид бине Габдулла Троицки шәһәрендә сәүдә иткән иде. Атасы Халид бине Габид шулай ук зур вә мәшһүр сәүдәгәрләрдән иде. Ерак бабасы булган Габдулла бине Мөслим – Байморад бине Мөхәррәм бине Мөэмин бабасы булган Мөэмин белән бертуган. Боларның тагын Мөхәммәд бине Мөслим исемле туганнары бар иде. 1302 елда Казан шәһәрендә вафат булган Габдеррахман бине Ибраһим бине Мөхәммәд бине Мөслим моның оныгы була.

Сахибе тәрҗемә Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри мәдрәсәсендә грамматика, мантыйк өйрәнеп, 22 яшьләрендә гыйлем туплау максаты белән Бохарага сәфәр кылган. Анда Күгелташ мәдрәсәсендә Бохараның галиме вә казые булган Мөхәммәдшәриф хуҗа мәүләви бине Һади дәресләренә кереп, аларны тулысынча үзләштергән. Бохарада унөч ел торган. Үз иленә кайтып, Габделгафур бине Габделмәннан вафатыннан соң Чистай шәһәрендә имамлыкка сайланып, шунда эшләде. Указ алдымы-юкмы, хаҗи Мөхәммәдшаһ бине Мирас белән бергә Троицки шәһәренең югарыда телгә алынган мәчетендә имам булды. Шушы мәчет хозурында иң беренче булып мәдрәсә оештырып, тәгълим ишекләрен ачкан зат шушы кемсә булды, диләр. Егерме биш ел имамлык вә укыту белән шөгыльләнеп, ахирәткә сәфәр итте.

Шәкертләре: Сәлахеддин бине Исхак әл-Казаный, шәех Зәйнулла бине Хәбибулла әл-Халиди, Әхмәд хаҗи бине Габдеззаһир әл-Бәрәскәви әт-Турый,

Мөхәммәджан бине Габдеззаһир әл-Бәрәскәви әт-Турый, Шәрәфеддин бине Әхмәд әл-Булатый, Муса бине Фәтхулла әр-Рәсүли әл-Ахунди һәм башкалар.

// [513]

Бохарага сәфәре алдыннан Галиәсгар бине Әбүязид бине Рәхмәтулла бине Иманкол бине Рахманкол әл-Мәмәши исемле кемсәнең Фатыйма исемле кызына өйләнде. Бохарадан кайтып җиде ел торганнан соң, бу хатыны вафат булды. Аннан соң Троицки шәһәрендә асылы Бәрәскә авылыннан булган Таһир бине Уразай исемле сәүдәгәрнең Маһиҗәмал исемле кызына никахланды. // [514] Беренче хатынынннан – Хәкимҗан вә икенчесеннән Габдулла, Йосыф исемле уллары калды. Кыз баласы юк иде. Йосыф Ташкент шәһәрендә сәламәт вә сәүдә белән шөгыльләнә, диләр.

### 436. Сәгъди бине Атнабай бине Сәярбай бине Колбай бине Акчуаш бине Мирас

Златоуст өязе Мирзалар авылында имам булып, 1287 (1870) елда вафат булды. Галимбикә бинте Йайуш исемле хатынынннан Гыймадеддин, Хисамеддин исемле уллары калды. Үзе Җилем Каран исемле авылда Рәхмәтулла исемле кемсә хозурында укыган. Ата-бабалары һәммәсе шушы авылда имам булганнар. Атнабай бине Сәярбай Уфа наместнигы идарәсе тарафыннан 1791 елның 3 маенда имам вә мөдәррис булырга 2330 нчы санлы указ алды. Остазы Эстәрлетамак өязе Балыклы Күл авылында Габделваһһаб бине Габделкәрим булып, 1830 ел ахырында вафат булды, диләр. Җәгъфәр ишаннан тарикатьтә рөхсәт алды, диләр. // [515] Гыймадеддин исемле улы бүген Мирзалар авылында имам, сәламәт икән дип ишеттек.

### 437. Шәмвил бине Мөхәммәд

Шәех Шамил дип билгеле булган зат, 75 яшендә Мәдинәдә 1287 (1871) елның зөлкагдә аенда вафат булды. Кабере хәзрәт Габбас бине Габделмөтталиб (Аллаһ аннан разый булсын) янында.

**438. Әхмәд бине Хөсәен әл-Мәкки**

Хәбәш [Эфиопия] мәмләкәтендә 1287/1870 елда вафат булды. Асылы Мәккә шәһәреннән иде. // [529] 1268 елда Казан шәһәренә килеп, берничә ел торды. Әхмәд бине Максуд дигән кешенең кызы Зөләйхага никахланды, Фатыйма исемле баласы дөньяга килде. Соңрак хатыны вә баласын ияртеп Мәккәгә күчте, аннан Җиддәгә килеп, бер микъдар торды, ахырында Хәбәшкә һиҗрәт итеп, анда вафат булды. Коръән хафиз, беркадәр гыйлеме бар, тырыш вә гаять юмарт иде, диләр. Кайбер шигырьләре дә күренде. Казанлы сәүдәгәр Исхак бине Гобәйдулла бине Мөхәммәдрәхим әл-Юнысый, Мәккәдә булган тәкиясе хакында вакыфнамә яздырып, аны раслар өчен, шушы сахибе тәрҗемәне үз тарафыннан вәкил иткән иде.

**439. Исхак бине Ибраһим бине Габделмәҗид бине Әбүбәкер бине Ураз әл-Казаный**

Казан шәһәрендә сәүдәгәрләрдән булып, 63 яшендә 1288 елның 24 сәфәрендә (май аенда) Казанда вафат булды. Анасы Зөбәйдә бинте Йосыф бине Бикбау иде. Муса, Әхмәд, Габделвәли исемендә уллары калды. Аның исеменнән хаҗ кылу өчен Нургали бине Габдеррәкыйб әл-Баруди җибәрелде. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани дә язган.

Бабасы булган Габделмәҗид бине Әбүбәкер Наласа авылыннан Казанга күчеп килгән, 1243 елның мөхәррәм аенда Мәдинә шәһәрендә вафат булган. // [530]

**440. Габделгани бине Салих бине Сәгыйдь әл-Кили әл-Казаный**

Казан шәһәренең Печән базары мәчетендә имам булып, 60 яшендә 1288 (1871) елның рабигыль-ахир аенда вафат булды.

Остазлары: Габделгаффар бине Сәгыйдь, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый, Бохарада Мөхәммәд бине сәфәр әл-Хөҗәнди һәм башкалар.

1859 елда аңа Җәмгыяте шәргыя тарафыннан бастырылачак Коръән шәрифне хатасыз бастыру эше кушылды. Атасы Салих бине Сәгыйдьнең тәрҗемәи хәле язылды.

// [532] Хатыны Гаишә бинте Гобәйдулла бине Габделгазиз ире вафат булганнан соң Казан имамнарыннан Габдулла бине Габделгаффарга никахланды.

## 441. Хәмди бине Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза әл-Бәзнәви

Тау ягындагы Чокалы авылында имам булып, 90 яшендә 1288 (1871) елның җөмадиел-әүвәлендә вафат булды. Абыйсы Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек һәм башкалардан укыган.

## 442. Фазлулла бине Фәйзулла әт-Тактавый

Минзәлә өязе Такталачык авылында имам вә мөдәррис булып, 1288 (1871) елның 26 рамазанында (декабрь) вафат булды. Кабере шул авылда.

Шаһиәхмәд бине Рәфыйк әс-Симәки хозурында укып, камиллеккә ирешкәч, имам булды. Соңрак указын ташлап гаиләсе белән Эстәрлебаш авылына күчеп шәех Нигъмәтулла бине Биктимер хәзрәтләренә буйсынырга булды. Шул шәех һәм аның вафатыннан соң улы Харис хәзрәт белән якыннан аралашып, күп еллар мөрид булып, соңыннан үзе дә мөридләр тәрбияләргә рөхсәт алды. Шуннан соң кабат Такталачык авылына килеп имам вә мөдәррис булды. Гомерен шәкерт вә яраннар тәрбиясе белән кичерде. Мөхтәрәм әтием Фәхреддин бине Сәйфеддин моның яраннарыннан берсе иде. Хәбибулла бише Харис әл-Эстәрлидән ишеткәнемә күрә, Харис бине Нигъмәтулла хәзрәтләреннән ялгыз шушы зат рөхсәт алган булган. Түбәнчелекле вә галим, зиһенле вә тәкъва, диндар вә фазыйль, күп нәрсә турында белүче, зур галимнәр арасында җитдилек вә сабырлык белән гыйльми сүзләр сөйләгән бер зат иде, диләр.

// [533]

Балалары калса да, камиллегенә варис булган баласы ахун Ягъкуб бине Нигъмәтулла әл-Әлми никахында булган Мәгъдәнелҗәмал исемле кызы иде. (Моның тәрҗемәи хәле «Мәшһүр хатыннар» исемле әсәрдә язылды.) Шушы фазыйль кызы, озын гомер сөреп, 1906 елның 7 рабигыль-ахирендә (17 май) чәршәмбе көн вафат булды. Кабере Әлем авылында.

**443. Харрас бине Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли**

Эстәрлебаш авылында имам вә мөдәррис булып, 1288 (1871) елның 29 рамазанында 57 яшендә вафат булды.

Остазлары: Бохарада Хәсән бине Хәл, Габделмөэмин бине Үзбәк, Фазыл бине Гашур әл-Гыйждуваный. Тарикатьтә рөхсәт алып укытты, абыйсы шәех Харис хәзрәтләре кебек яраны күп иде. Дөньясы да киң, шәкерте күп булды.

Балалары: Лотфулла, Габдеррахман һәм башкалар.

**444. Хөснеддин бине Гомәр бине Сәед бине Ишмөхәммәд әс-Суыксувый**

Казан шәһәренең җиденче мәчетендә имам булып, 60 яшендә 1288 (1872) елның шәүвәлендә (гыйнвар) вафат булды. Хатыны Габделгафур бине Мәхмүд әл-Казаный кызы Гаишә иде.

Остазлары: Фәтхулла бине Сәфәргали әл-Казакларый, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый, Таһир бине Сөбхан әл-Адайи. Асылы Чуашиле авылыннан булып, атасы Суыксу авылында имам булган вакытында дөньяга // [534] килгән. Вафатыннан соң Шакир исемле улы, Истанбулдан кайтып, атасы урынына 1289 елда имам булды. Ул озак вакытлар авырып, 1322/1904 елның 27 рабигыль-ахирендә (июнь) вафат булды.

**445. Корбангали бине Әбүшәхмә әт-Тубылый**

Тубыл губернасының Казанлы авылында имам булып, 67 яшендә 1288 (1872) ел ахырында вафат булды. Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый хозурында укыган, үз авылына кайтып, укыту белән шөгыльләнгән. Аның турында: «Үз гомерендә күп шәкерт тәрбияләде, уллары да имамнар, ләкин улларының кайберләре мәгънәле, ә кайберләре мәгънәсездер», – диләр.

**446. Хәсән бине Хәмид бине Исмәгыйль бине Габдерраззак әл-Мөслими әл-Курсавый**

Казан өязе Курса авылында имам вә мөдәррис булып, 60 яшеннән узып, 1289 (1872) елның 15 мөхәррәмендә, якшәмбе кичәсендә вафат булды. Шул авылның

каберлегендә үз шәехе Габделхаликъ бине Ибраһим әл-Курсавый янында җирләнгән. Васыятенә күрә җеназасын хаҗи Габделвәли бине Вәлид бине Максуд ән-Наласавый укыды. Хатыны шул шәехнең кызы Газизә иде. Шакир, Закир, Гариф исемле өч улы вә Рабига, Хәдичә исемле ике кызы калды.

Остазлары: Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый, Исхак бине Сәгыйдь әл-Казаный, Фәхреддин бине Садыйк әс-Сөни.

Шәкертләре: Гатаулла бине Мөхәммәд әл-Курсавый, Хәсән бине Исхак бине Кадер әл-Әлдермеши, Хәлил бине Насреддин әл-Арысланый әл-Уфавый, Сәгъдеддин бине Салих һәм башкалар. Габделхаликъ бине Ибраһим әл-Курсавый хозурында тәрбияләнеп, суфыйчылыкта рөхсәт алды; аның вафатыннан // [535] соң шәехлек кылып, яран тәрбияләде. Вафатыннан соң аның дәвамчысы Гатаулла бине Мөхәммәд әл-Курсавый булды. Фәхреддин бине Мостай ән-Нурлатыйның моның хакында сөйләнгән мәрсиясен күргәнебез бар. Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани дә язган.

Улы Шакир, Казанда фазыйль Мәрҗани хозурында, соңыннан Бохарада укып, Курса авылында имам булды. Күпмедер вакыттан соң, 1897 елда, указын Казан шәһәренең Печән базары мәчетенә күчертте. 1908 елның 22 июнендә, якшәмбе көн Курса авылында вафат булды. Хасталыгы сәбәпле ял итәр өчен үз авылына кайткан булган. Казан шәһәрендә унике ел торган була. Мәдрәсә тоту, укыту белән шөгыльләнмәсә дә, гыйлеме // [536] бар, әхлагы гүзәл, мөлаем бер зат иде. Уфа шәһәрендә торган вакытыбызда өебезгә күп мәртәбәләр килеп, озак вакыт утырыр иде, бер дә гайбәт сөйләгәнен яки бер кемчәдән шикаять иткәнен ишетмәдем.

Рабига исемле кызы Лаеш өязе Казаклар авылында имам Борһанеддин бине Габдеррәфыйгъ никахында, Хәдичә исә Олы Мәңгәрдә имам Мөхәммәдһади Бикчәнтәй улында кияүдә.

**447. Габделваһһаб бине Иманкол бине Мансур бине Нур**

Спас өязе Рәҗәп авылында беренче мәчет имамы булып, 102 яшендә 1289 (1872) елның мөхәррәмендә (5 март) вафат булды. Казан өязе Күшәр авылында Габбас бине Габдеррәшид бине Әхмәд хозурында укып кайтканнан соң шушы мәчеттә имам булды. Бу вакытта Рәҗәп вә башка авыллар артык наданлыкта булып, ирләр белән

хатыннар, егетләр белән кызлар бергә катнашып йөреп, русларның элек заманнарыннан калган май вә башка бәйрәмнәрдә катнашып, кызлар вә егетләр бергә май чабып йөрерләр иде. Сахибе тәрҗемә исә рәсми имам булганнан соң боларны тора-бара бетерде. Кизләү авылында шәех Гобәйдулла бине Җәгъфәр бине Ибраһимгә буйсынып, аның тарафыннан тәрбияләнде. Нигъмәтулла бине Гобәйдулла әл-Әлмәти кызына никахланып, аңа кияү булды.

Аталары шушы авылда имамнар булып килгән. Анасы Зөлхәя Сөбханкол кызы булып, уллары Габделвәли, Габделгафур, Лотфулла, Сибгатулла, Габделгани, Сөнгатулла, Әхмәдҗан, кызлары Шәмсия, Маһибәдер, Җәмалия исемле.

Уллары гасырларына күрә гыйлем әһелләре булып, кызлары да гыйлем әһелләренә бирелде.

// [537]

Габделвәли балалары: Шаһвәли, Вәлиулла, Газизә.

Габделгафур балалары: Гайнелхәят, Әхмәдсафа, Галимә, Мөхәммәдвафа, Хәйрелбанат, Әхмәдгата, Сафиулла.

Лотфулла балалары: Габделбар, Габбәсә, Морад, Хәмирә, Ләбиб, Рәшидә, Галия. Үзе фазыйль Мәрҗани хозурында укыды.

Сибгатулла балалары: Хәдичә, Фәезхан, Мәликә, Закирә, Габдеррахман, Мәрьям.

Габделгани балалары: Һади, Мәрзыя, Гәрәй, Йосыф, Габделфәттах, Закир, Галимә, Габденнасыйр, Сабир, Бибиҗәмал, Гаделгалләм, Нәгыймә, Хафиз, Мәгъсумә, Кәрим, Газизә, Кыям, Габделкәрим.

Сөнгатулла балалары: Гатаулла, Өммегөлсем, Гәрәй.

Әхмәдҗан балалары: Кәмалия, Гарифулла, Фатыйма, Хәлилулла, Фатыйха, Зөһрә.

Шәмсия балалары: Габдессамад, Габделхак.

Җәмалия Спас өязе Киек авылында мулла Нурулла никахында булып, балалары: Габделхак, Гыйззелбанат, Габделбарый, Гыйззенәвәл, Гыяседдин, Зыяэддин.

**448. Таҗеддин бине Әхмәр бине Динмөхәммәд бине Кадерле бине Колмый бине Алтын бине Айбакты бине Айдар**

Сәмәрканд шәһәрендә 1289 (1872) елның сәфәрендә вафат булды. Асылы Зөя өязе Айдар авылыннан иде. Атасы шул авылда имам булып гомер сөрде.

Үз илендә гыйлем туплаганнан соң, Сәмәрканд // [539] шәһәренә барып шәех Байсуный мәҗлесенә катнашып, Тарикатьтә рөхсәт алды һәм вафатыннан соң аның урынына калып яран тәрбияләде.

Остазлары: Әбел-Хәсән Рәхимулла бине Әманулла бине Фәйзулла бине Нияз әл-Һинди әл-Газыймабади әш-Шәһид. Аның дәвамчысы Хәбибулла Мөхәммәд бине Салих бине Сәлим һәм башкалар.

Бу кемсә хакында фазыйль Мәрҗани: «Яхшы вә диндар бер зат иде, шәехе шәех Шафигый мәсләгендә гомер итте», – дигән.

**449. Фазыл бине Ибраһим бине Арыслан бине Туймый** // [540] **бине Тимә бине Әмир Туган әл-Кимеви**

Казан өязе Киме авылында имам булып, 75 яшендә 1289 (1872) елның рабигыль-әүвәл аенда вафат булды.

Балалары: Сибгатулла, Гыйнәятулла, Габделгалләм. Хатыны Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек әл-Ашытый кызы Гаишә иде.

Остазлары: Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади.

Улы Гыйнәятулла да шул авылда 40 яшендә 1303 елда вафат булып, җеназасын Хәсән бине Мөхәммәдшәриф бине Фәхреддин әл-Бәхтияри укыды. Өч сабый кыз баласы калды. Фазыйль Мәрҗани хозурында укыган, аның белән бергә хаҗ сәфәрендә йөргән.

**450. Габделкәрим бине Улмазкол**

Златоуст өязе Салҗут авылында имам булып 1289 (1872) елның җөмадиел-әүвәлнең 2 нче көнендә (27 июнь) вафат булды. Остазы Әбеннасыйр Габденнасыйр

бине Ибраһим әл-Курсавый иде. Дәүләтшаһ, Мөхәммәдгалим исемле балалары калды. Бу кемсә хакында Салҗут авылының бүгенге имам вә ахуны Габделгалим бине Габделмөгыйн бине Габделмән бине Рәсүл: «Габделкәрим хәзрәт галим, тәкъва бер зат иде, яшь вакытымда аннан гыйлем укыдым, соңрак исә аның урынында имам вә ахун булдым», – ди.

### 451. Рузмөхәммәд бине Гомәр әт-Тубылый

Тубыл ягындагы Шулкин авылында 77 яшендә 1289 (1872) елның 4 шәгъбанында (26 сентябрь) вафат булды. Себердә Рузый ишан дип билгеле булган зат шушы кеше. Остазы Фазыл бине Ибраһим әл-Әлмәни иде. Тубыл шәһәрендә миллионер бер рус тарафыннан сәүдә вәкиле сыйфатында Бохарага барган, анда беркадәр еллар калган.

// [532]

### 452. Габделхәким бине Корбангали бине Габделхәмид бине Исәнгилде бине Бурсык бине Юлъяхшы

Чиләбе өязе Чардаклы Айбат авылында имам вә мөдәррис булып 63 яшендә 1289 (1872) елның шәгъбан аенда вафат булды.

Балалары: Гыйсамеддин, Гобәйдулла, Габделмәҗид.

Башта Юлык авылына барып, Габделлатыйф бине Әдһәм хозурында укыган, аның вафатыннан соң Симәк авылында Шаһиәхмәд бине Рәфыйк хозурына барган, әмма бу вакытта Симәки үлем хасталыгында иде, шул сәбәпле моннан Эстәрлетамак шәһәренә китеп, Шәрәфеддин бине Зәйнеддин хозурында гыйлем туплаган. Дәресләрне тулысынча үзләштергән, тарикатьтә кереп, иҗазәт алган. Югарыда аталган авылына кайтып укыту вә тәрбия белән шөгыльләнгән. Иҗазәт биргән дәвамчылары: Зәйнулла бине Галикәй әл-Арысланый әл-Эстәрли, Кәмаледдин бине Шәрәфеддин бине Зәйнеддин, Хисамеддин бине Габделкәрим әт-Таубазый, Габделәхәд бине Габденнасыйр әл-Әлмәни әл-Әчкәни, Ибраһим бине Габденнасыйр әс-Сәгыйди, шәех Зәйнулла бине Хәбибулла әл-Халиди һәм башкалар. Бүген

Гобәйдулла исемле улы Мидйәк авылында имам һәм ахун булып дәрес вә шәкертләр тәрбияләү белән шөгыльләнә.

// [543]

**453. Гайсә бине Габделмәҗид бине Уразгилде бине Рахманкол бине Бикбау бине Иркәш бине Тулунхуҗа бине Акхуҗа бине Чинкәй бине Кадерхуҗа бине Кадершәех бине Пәһлеван-ата**

Бөгелмә өязе Камы Исмәгыйль авылында имам булып, 80 яшеннән узып 1289 (1872) елда вафат булды. Хатыны Сәрвиҗамал исемле булып, Галиәкбәр исемле кемсәнең Хәфизә бинте Габдеррәшид бине Мортаза әл-Иштирәки исемле хатыннан булган кызы иде. Шәрәфеддин исемле улы да шул авылда имам булып, 80 яшендә 1901 елның мөхәррәмендә вафат булды.

Сахибе тәрҗемә берничә җирдә гыйлем туплаганнан соң хатын алды һәм үзенең каенагасы булган Таҗеддин бине Габдеррәшид әл-Иштирәки хозурында укыр өчен Сасна авылына китте. Шунда үз тырышлыгы вә остазының игътибар вә дәрте белән дәресләрне тулысынча үзләштереп авылына кайтты. Бохарага сәфәр кылу нияте белән йөрде, хәтта паспорт алып кайткан иде, ләкин хатыны: «Мине алганыңнан соң бу кадәр вакыт мине ташлап йөрдең! Мин исә ничә еллар сабыр итеп сине көтеп тордым, хәлбуки син һаман да мине калдырып китү ниятендә икәнсең, валлаһи, болай булмас, хәзер инде янымда тор! Мин сиңа, никахлы булганым хәлдә, тол хатын булып яшәр өчен килмәдем!» – дип орышканыннан әсәрләнеп, бу максатыннан ваз кичте. Казан – Уфа юлы өстендә булган Мактама авылында мәдрәсә оештырып, шәкерт җыеп дәрес белән шөгыльләнде. Соңрак ни өчендер шәкертләре таралып бетте, һәм ул, үз авылына кайтып, рәсми рәвештә имам булды. Озын буйлы, сирәк сакаллы, күп // [543] сүзле, ачык йөзле, түбәнчелекле бер зат иде. Күпчелек гомерен җәяү йөреп кичерде. Ун-унбер яшьләремдә булса кирәк мин бу затны күрдем, ләкин сөйләгән сүзләреннән бер җөмлә булса да хәтеремдә калмады. Тәрҗемәи хәлләрен язарга җыенган затлардан үз күзем белән күргәннәремнең беренчесе шушы адәм.

// [535]

**454. Таҗеддин бине Гыйсмәтулла бине Сатылган бине Сөләйман бине Акманай бине Атай бине Балагыш бине Байсары бине Кадербакты бине Агъчак бине Бирдебәк бине Аллаһгават бине Тугызак бине Бузуби бине Сәнкарат**

Бөре өязе Чишмә авылында имам булып, 63 яшендә 1289 елның зөлхиҗҗә ахырында (15 февраль) вафат булды. Казан вә Бохара галимнәреннән укып кайтканыннан соң, имам булып, авылында шәкерт җыеп, аларны укытып гомер кичерде. Тел гыйлеме, шигърият белеме, тәҗвид гыйлемнәрен яхшы белеп, төркичә вә фарсыча шигырьләр иҗат иткән. // [536]

**455. Габделгалим бине Яһүдә бине Хәсән**

Минзәлә өязе Бикбау авылында имам булып, 1289 (1873) елның зөлкагдә аенда (5 гыйнвар) 87 яшендә вафат булды. Атасы Бәләбәй өязе Корыч авылында имам булган иде. Ерак бабалары Ханкирмән тарафыннан бу җирләргә күчеп килгәннәр.

Остазлары: Шаһиәхмәд бине Рәфыйк әс-Симәки, Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли, Харис бине Нигъмәтулла әл-Эстәрли.

Шәкертләре: Гайнеддин бине Әхмәд әл-Каенлы, Сәгъдеддин бине Мансур әл-Чебенле, Динмөхәммәд бине Нурмөхәммәд әл-Актанышый, Низамеддин бине Гыйсамеддин әл-Күбәки һәм башкалар. Бу кемсә хакында Хәбибулла бине Харис әл-Эстәрле: «Бер сәфәремдә өенә // [547] кердем, алача тышлы бер мендәр белән берничә китап булып, шуннан башка һичнәрсәсе юк иде. Үзе галим вә фазыйль, булганга канәгать итүче вә сабыр бер зат иде», – дип сөйләде.

**456. Мөхәммәдшәриф бине Габбас бине Габдулла бине Уразмәт бине Шәмшәб бине Шүшә**

Сары Кукшай (Царевококшайск) өязе Котаймаз авылында имам булып озын гомер сөрде, ахырында Сими (Семипулат) шәһәренә китеп, 1289/1873 елда вафат булды.

Казан өязе Мәтәскә авылында имам булганында Җәмгыяте шәргыягә әгъза

булып сайланган иде. 1836-1839 елларда имза кылган кәгазьләре бар. Хатыны Фәтхулла ахун бине әл-Хөсәеннең Фатыйма исемле кызы иде. Симидә сәүдәгәр булган Гарәбшаһ исемле улы өендә вафат булган иде. Атасы вә бабасы Кече Әшнәк авылында имам булдылар. Язуы хаталы вә ялгыш иде.

// [548]

## 457. Сибгатулла бине Габделкадыйр бине Сөләйман бине Мостафа әш-Шәрифи

Казан ягындагы мәшһүр Оры авылында имам вә мөдәррис булып, 75 яшендә 1290 (1873) елның рамазан ае башында вафат булды. Кабере шул авыл зиратында.

Остазлары: атасы Габделкадыйр бине Сөләйман, Сәгыйдь бистәсендә Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Бубыйда Габделкәрим бине Хәлил, Казанда Әбүбәкер бине Йосыф әл-Җәбәли, Орыда ахун Фәтхулла бине Хөсәен һәм башкалар.

Шәкертләре: Фәттахеддин бине Әхтәм әл-Кормашый, казый Борһанеддин бине Насреддин һәм башкалар.

Балалары: Лотфулла, Вәлиулла, Шөҗаг, Сәмигулла, Фәхрелбанат . Үзе сәламәт вакытында Вәлиулла исемле улы үзенә ярдәмче имам булды, үз урынына Шөҗаг исемле улы имам булды.

Вәлиулла 1310 елда вафат булганга, Кенәр авылында имам булган Сәмигулла исемле улы монда күчте. Бүген шул Сәмигулла атасы Сибгатулла хәзрәт урынында. Лотфулла Котаймаз авылында имам вә ахун. Моның Галимәтелбанат исемле кызы Ханкирмән ягындагы Яубаш авылында 1906 елның зөлкагдәсендә (29 ноябрь) вафат булды. Яше фәкать 30 иде, диләр. (Тәрҗемәи хәле «Мәшһүр хатыннар» исемле китапта бар.) Бәдрелбанат исемле галимә вә фазыйлә кызы атасының бертуганы булган Габделгалләм бине Габделкадыйр улы Мөхәммәдхәлил әфәнде никахында. Сибгатулла хәзрәт бервакыт Казан шәһәренең алтынчы мәчет хозурында булган мәдрәсәдә шәкертләргә дәрес укытты. Соңрак Оры авылында Фәтхулла ахун бине әл-Хөсәен мәдрәсәсенә күчте вә ахун вафат булганнан соң имам вә мөдәррис булды. Галим, пакь бер зат иде, диләр. Атасы Габделкадыйр вә бабасы Сөләйманның

тәрҗемәи хәлләре язылды.

// [549]

## 458. Җәмаледдин бине Бикәш

Мамадыш өязе Шәдче авылында имам булып, 70 яшендә 1290 (1873) елның 8 рамазанында вафат булды. Асыл ватаны Малмыж өязе Мәмәшир авылыннан булып, тууы Шәдче авылында булган. Башта Мамадыш өязе Көек авылында Габбас бине ... [төп нөсхәдә шулай. – *Төз.*] мәдрәсәсендә торган, тел гыйлемен шунда өйрәнгән. // [550] Соңрак Мәчкәрәдә Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый хозурына барып мантыйк вә гакыйдә гыйлемнәрен укыган. Соңыннан Чистай шәһәренә Исхак бине Сәгыйдь мәдрәсәсенә барып фикъһ, әхлак, хисап дәресләрен укыган, остазының улы Сәлахеддин хәзрәтләренә шул вакыт мөгаллим булган. Мамадыш өязе Ушма авылына имам булырга указ алган, ләкин низаг чыкканга Кирмәнбаш исемле авылга указ алып, бераз вакыт анда торганнан соң указын Шәдче авылына күчертеп, шунда күчеп килгән.

Беренче хатыны Минзәлә өязе Би авылыннан Вәлид мирза бине Исмәгыйль әл-Яушый кызыннан балалары: Садреддин, Фәттахеддин, Мөхәммәдзариф, Мөхәммәдюныс. Икенче хатыны Иске Комазан авылы имамы Габделҗәлил кызыннан Габделҗәмил исемле улы бар иде. Садреддин атасы урынына Шәдче авылында имам булып, Мөхәммәдзариф шунда мөәззин. Габделҗәмил абыйсы Садреддин мәдрәсәсендә укып, Урта Шөләнгер авылында имам булып аз бер вакыт торганнан соң, яшьлегендә вафат булды.

Казан шәһәрендә һәр ел бер-ике тапкыр, һәрберсендә ничә мең данә белән басылучы «Фазаил әш-шөһүр» китабы шушы затның әсәре. Безнең халкыбыз арасында бу китапны дәреслек буларак укымаган кеше булса да бик сирәктер. Шуның өчен сахибе тәрҗемә бу тараф мөселманнарының гомумән бер остазы булып санала. // [554]

**459. Габдеррәкыйб бине Габделмөэмин бине Габдеррәхим бине Габдеррахман**

Казан шәһәрендә Барудия мәхәлләсендә имам булып, 70 яшендә 1291 (1873) елның җөмадиел-әүвәл аенда вафат булды. Остазы Бәйрәкә авылында Гобәйдулла бине Ибраһим иде.

Асылы Бөгелмә өязе Зәй елгасында булган Габдерахман авылындадыр. Шул авылда имам вә мөхтәсиб булырга указ алды, соңрак атасының бертуганы булган мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим тырышлыгы вә яхшы мөнәсәбәте нәтиҗәсендә Казан шәһәренең шул мәхәлләсенә күчте. Гомер ахырында имамлыктан читләште.

Нургали исемле улы Казанда Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим вә Сәлахеддин бине Исхак хозурларында укып, шул мәчеттә имам булды, икенче мәртәбә хаҗ сәфәреннән кайтканында Мәдинә белән Янбәгъ арасында вафат булып, Бир Сәгыйдь исемле җирдә күмелде (1313/1895 ел, 22 мөхәррәм). Диндар вә әхлаклы бер зат иде. Уфа шәһәрендә күп тапкыр күрдем, мәҗлестәш булдым. Урынында Әхмәд исемле улы имамлык кыла. Мөхәммәд исемле икенче бер улы Истанбулга барып гыйлемен камилләштерде, атасы Нургали белән бергә Хиҗаз сәфәренә китте, хаҗ көннәрендә 1895 елда Минада дөньядан китте. Моның хакында фазыйль Мәрҗани дә язган.

**460. Низамеддин бине Сәлимҗан**

Малмыж өязе Салавыч авылында имам булып, 60 яшендә 1291 (1874) елның рәҗәбендә вафат булды. Хатыны Габдулла бине Яхъя // [555] әл-Чиртушый кызы иде.

Остазлары: Исхак бине Сәгыйдь әл-Казаный, Ягъкуб бине Җәгъфәр әт-Төбъязый, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый вә Бохарада Хәсән бине Хәл һәм башкалар. Фәтхелкадыйр исемле улы калды.

**461. Габдеррәкыйб бине Исмәгыйль бине Сөбханкол әл-Кодашый**

Троицки якларында казак арасында мосафирлыкта булган вакытында, 75 яшендә 1291 (1874) елда вафат булды. Асылы Бөгелмә өязе Тайсуган авылыннан булып, атасы Исмәгыйль бине Сөбханкол аннан җиде чакрым ераклыкта булган

Кодаш авылына имам булды.

Габделхәлим бине Зәйнелгабидин әл-Мортышый хозурында укып кайтканнан соң шул авылда имам булган. Мәдрәсә тотып шәкерт җыймады, гыйлеме белән шөһрәт казанмады. Алай булса да, гарәпчә язылган әсәрләре аның чын гыйлем иясе икәнен исбат итәләр. Дөньясын фәкыйрьлек, мескенлек белән, төрле җәфа вә мәшәкатьләр белән уздырып, ахыр чиктә гаилә һәм балаларын, указын вә барлык әйберләрен ташлап, мосафир булып өеннән чыгып китте. // [556]

**462. Һибәтулла бине Исхак бине Ибраһим бине** // [557] **Бикмәт**

Оренбург яклары Тугызак авылында 80 яшендә 1291 (1874) елда вафат булды.

Балалары: Сафурия, Мөхәммәдсафа, Сөнгатулла һәм башкалар. Ерак бабасы Бикмәт Казан өязе Саба авылыннан Самар якынында Мача исемле су буена күчеп килгән. Сахибе тәрҗемә исә шул урында туып, Кизләү авылына барып, шәех Гобәйдулла бине Ибраһим хозурында укыган. Соңрак шәех улы Нигъмәтулла хозурында тәрбияләнеп рөхсәт алды. Соңыннан авылына күчеп урнашты, анда вафат булды. Юаш, суфый бер зат булып, Зәй елгасы вә Минзәлә якларында күп мәртәбәләр Йөргәнен риваять кылалар.

**463. Искәндәр бине Каландәр суфый әл-Мәргыйнани**

Әстерхан якларындагы бер авылда 1891 (1874) елда вафат булды. Тарикать шәехе булып мөрид тәрбияләде, шушы затларның шәехе иде: Габдеррахман бине Ибраһим әс-Сәмәки, Салих бине Хакбирде, Зәкәрия бине Сәлимҗан һәм башкалар.

**464. Әрмәншаһ бине Әхмәд бине Габдеррәшид бине Вилдан бине Мансур бине Иманкол бине Солтан**

Солтанай авылында 76 яшендә 1291 (1874) елда вафат булды. Хатыны Мәгъфүрә бинте Габделгани иде.

Балалары: Фәрхиҗиһан, Гаишә, Мөхәммәдгата, Гөлчәһрә, Фатыйма, Сара. Фәхреддин бине Мостафа әл-Әгерҗеви мәдрәсәсендә укып, Насреддин бине Зәйниш

әл-Калмакыйга ант бирде, аннан тарикатьтә рөхсәт алды, мөридләр тәрбияләде. Авылы халкы белән имам булырга килеште, әмма үз шәехенә киңәшләшер өчен баргач, шәехе ризалыгын бирмәде, шуңа күрә бу ниятеннән кире кайтты. Баштарак бик фәкыйрь булса да, соңыннан дөньясы үсеп китте. // [558] Хәтта зур сәүдәгәрләрдән санала башлады, диләр. Мөселманнарның байлыгын үз балалары өчен туплаган ишаннар кебек булмыйча, үзе кәсеп иткән байлыгын мөселманнар мәнфәгатенә сарыф итте. Гарип вә фәкыйрьләргә, бигрәк тә гыйлем юлында булган шәкертләргә бик мәрхәмәтле вә гадәттән тыш юмарт иде, диләр. Юмартлыгы хәтта балаларына да мирас булып калганы мәгълүм. Вафат булачак көннәрендә улы Мөхәммәдгата әфәндегә алтмыш тәңкә акча биреп: «Менә шуның белән кәфенлә, күмәргә әзерлә! Балаларыңны укыт! Тәрбияләренә җиңел карама, дикъкатьле бул! Фәлән эшне хәтта егерме мең сарыф итеп булса да җиренә китер!» – дип васыять иткән, ди. Улы исә: «И мөхтәрәм әтием! Сүзең җаныма кадерледер, ләкин егерме мең кадәр акчаны бу хәлем белән мин ни җирдән таба алырмын?» – дип сораган. Атасы: «Аллаһы Тәгалә бирер!» – дигән. Мин исә Уфа шәһәрендә Мөхәммәдгата хәзрәтне күргәнемдә: «Мөхтәрәм атагыз васыятен җиренә җиткердегез кебек, ләкин ни рәвешле шул малны булдырдыгыз?» – дип сорадым. Ул көлде дә: «Аллаһ бирде – диде.

Сахибе тәрҗемәдән Мөхәммәдмөкыйм бине Габделхәким бине Тайяр әл-Чарлакый исемле зат рөхсәт алган.

## 465. Сәгыйдь бине Хәмид бине Йосыф бине Хәсән бине Габдеррахман бине Хәлилулла

Тәтеш өязе Тәүгилде авылында имам булып, 84 яшендә 1278 (1862) елда вафат булды. Шул авыл имамлыгы өчен 1800 елда указ алды. Остазы Казан өязе Күлбаш авылында Максуд бине Корбангали иде. Шәкерт вакытында // [559] хаттат [каллиграф] булып үзе өчен кыйммәтле әсәрләр язып күчергән булса да, имам булганнан соң Сабит исемле улы урынына гаскәрлек хезмәтенә адәм яллап җибәрер өчен кирәк булган бер мең сум бакыр хисабы белән китапларын сатты. Шул әсәрләрне кабат күчерде. Оренбург собраниесендә әгъза булып хезмәт иткән Таҗеддин бине Максуд моның шәкерте иде.

Анасы Гөлгабидә мөфти Мөхәммәджан бине әл-Хөсәен белән бертуган иде.

Балалары: Сабит, Сахиб, Гыймран, Гыймадеддин, Мөхәммәдшаһ, Әхмәдшаһ, Җәмаледдин, Низамеддин, Гатаулла. Сабит Казан арты Бәрәзә авылында Бәшир исемле зат хозурында укыды, Тәтеш өязе Чирмешән авылында имам булып, 72 яшендә 1294/1877 елда вафат булды. Гыймран – Байморад бине Мөхәррәм, Фәхреддин бине Мостай ән-Нурлатый, Шиһабеддин әл-Мәрҗани хозурында укып, Тәтеш өязе Багыш авылында имам булып, 68 яшендә 1313/1894 елның 28 июнендә вафат булды. Фазыйль Мәрҗанинең могтәбәр шәкертләреннән булып, фикъһ, кәлям, ысул фәннәрен үзләштерде, гарәп теле гыйлемнәрендә оста иде. Кайбер шигырьләре дә күрелде. Мөхәммәдшаһ хәзер атасы урынында Тәүгилде авылында имам. Карт булганы хәлдә фикере яшь, газета вә журналлар укый, яңа әдәбиятка һәвәслеге бар, язуы дөрес, хат рәсеме гүзәл. Казан шәһәрендә Шиһабеддин әл-Мәрҗани хозурында укыган. Язган китаплары күп.

Соң алынганга күрә, бу тәрҗемәи хәл үз урыныннан соңрак, бу җирдә китерелде.

Тәмам.

## Шәхесләр күрсәткече

## Ә

Әбелхәер бине Шәммас бине Җәгъфәр бине Бигем бине Биккол бине Ходайбакты бине Җүлкә бине Богдан – 420

Әбүбәкер бине Җәгъфәр бине Ягъкуб бине Әднәкол ал-Әгермени – 339

Әбүйәзид бине Әднакол бине Бигем мирза бине Гыйшмәнд бине Урай бине Әлмәт бине Арыслан – 412

Әбүшәхмә бине Муса бине Габдеррахман – 290

Әрмәншаһ бине Әхмәд бине Габдеррәшид бине Вилдан бине Мансур бине Иманкол бине Солтан – 464

Әсфәндияр бине Ибраһим бине Йосыф бине Айтуган – 326

Әүхәди бине Искәндәр бине Сәгыйдь – 413

Әхмәд бине Габделкадыйр бине Сәйфелмөлек бине Мортаза – 424

Әхмәд бине Гаеткол – 279

Әхмәд бине Ихсан бине Гомәр бине Кадермәт бине Сәед бине Ирмән бине Исәнкол әл-Мәмсәви – 432

Әхмәд бине Мөхәммәд бине Габдеррәззак бине Ишмөхәммәд бине Тими – 354

Әхмәд бине Мөхәммәдшаһ бине Әхтәм әс-Суыксувый – 372

Әхмәд бине Сәгыйдь бине Әхмәд бине Йосыф әш-Шырданый – 410

Әхмәд бине Халид бине Габид бине Габдулла бине Мөслим бине Бикбулад... – 435

Әхмәд бине Хөсәен әл-Мәкки – 438

## Б

Байморад бине Мөхәррәм бине Мөэмин бине Мөслим бине Бутай ...– 274

Баһаведдин бине Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани – 327

Бәшир бине Җомгаколый – 320

Бикмөхәммәд бине Ташбулат бине Алуш бине әл-Мөхәммәд бине Йосыф бине

Җансәед – 334

## В

Вәлишаһ бине Мәхмүд бине Госман бине Биктимер – 268
Вилдан бине Сәгъди бине Максуд бине әл-Мөхәммәд бине Исмәгыйль әт-Туймый – 411

## Г

Габбас бине Габдеррәшид бине Әхмәд бине Шөкер бине Хәсән әл-Күшәри – 307
Габбас бине Мөхәммәделәмин – 418
Габделвахид бине Габделмәннан бине Аблай – 224
Габделвахид бине Габдеррахман бине Колый әл-Буавый – 292
Габделвахид бине Исмәгыйль бине Давыдхан – 309
Габделвахид бине Сөләйман бине Сәгълүк бине Габделхаликъ – 370
Габделваһһаб бине Иманкол бине Мансур бине Нур – 447
Габделвәли бине Габдеррәхим бине Шәриф бине Мөслим бине әл-Мөхәммәд – 348
Габделгалим бине Яһүдә бине Хәсән – 455
Габделгани бине Салих бине Сәгыйдь әл-Кили әл-Казаный – 440
Габделгафур бине Габделмәннан бине Аблай – 232
Габделгафур бине Мәхмүд бине Мөхәммәделәмин бине Ярмөхәммәд – 328
Габделгафур бине Сәйфулла бине Гаделшаһ бине Ибраһим бине Нурай бине Журай бине Илбакты – 331
Габделгаффар бине Габделхәмид бине Үтәгән – 257
Габделҗаббар бине Җәгъфәр бине Габделгафур әл-Пәрәвый – 384
Габделҗаббар бине Сәйфелмөлек бине Мортаза бине Сәлим бине Исмәнән бине Чуракай – 314
Габделҗәббар бине Габделкәрим бине Габделмәннан – 273 Габделҗәббар бине Габдеррахман бине Туймөхәммәд – 256

Габделҗәлил бине Бирмөгаллә бине Мортаза бине Морадгали бине Мәнгеш – 278
Габделҗәмил бине Үтәкол – 355
Габделкадыйр бине Каһарман бине Атйитәр бине Нургали – 396
Габделкариб бине Биниәмин бине Яһүдә әл-Аклуши – 433
Габделкаһһар бине Габдессаттар бине Сәгыйдь бине Әхмәд әш-Шырданый – 286
Габделкәрим бине Улмазкол – 450
Габделлатыйф бине Сөбханкол бине Рәмкол – 265
Габделмәннан бине Гадел бине Котлыг бине Алтынбай – 390
Габделмөэмин бине Фәйз бине Әхмәр – 365
Габделхалик бине Габделкәрим – 228
Габделхаликъ бине Габделмәҗид бине Ибраһим – 343
Габделхәбир бине Синҗаб бине Салих бине Сәлүк бине Бикчура... – 276
Габделхәким бине Исламкол – 277
Габделхәким бине Корбангали бине Габделхәмид бине Исәнгилде бине Бурсык бине Юлъяхшы – 452
Габденнасыйр бине Габдеррәхим бине Әхмәр бине Габделмәннан... – 395
Габденнасыйр бине әл-Мөхәммәд – 266
Габдеррәкыйб бине Габделҗәббар бине Сәйфелмөлек – 429
Габдеррәкыйб бине Габделмөэмин бине Габдеррәхим бине Габдеррахман – 459
Габдеррәкыйб бине Исмәгыйль бине Сөбханкол әл-Кодашый – 461
Габдеррәхим бине Бикчәнтәй бине Ибраһим – 251
Габдеррәхим бине Гашур – 271
Габдеррәшид бине Габдулла бине Мөхсин – 299
Габдессалих бине Габдул бине Шәриф бине Көек бине Күчкән бине Борак... – 272
Габдессаттар бине Габдулла бине Солтанкол – 321
Габдессәлам бине Габделваһһаб бине Мортаза бине Нурмөхәммәд – 344
Габдешшәкүр бине Габдеррәхим бине Габдеррәшид бине Госман бине Симуш бине Тимергази бине Рузчыпчак бине Ишмәт бине Бәхтияр бине Аюхан – 282
Габдулла бине Әмирхан бине Хуҗамкол – 293
Габдулла бине Мөслим бине Мөэмин әл-Иштирәки – 404

Габдулла бине Яхъя бине Мәхмүд бине Максуд бине Сөләйман әл-Чиртушый – 349
Габид бине Минкә бине Ягъкуб – 385
Гаделгаффар бине Гаделшаһ бине Хәлил бине Тукай – 297
Гайнан бине Ихсан бине Рәйхан – 319
Гайнеддин бине Галиәкбәр бине Морад бине Сөләйман – 304
Гайсә бине Габделмәҗид бине Уразгилде бине Рахманкол бине Бикбау... – 453
Гайсә Ибраһим әл-Мәңгәри – 329
Галибай бине Ярмөхәммәд бине Ногайбак – 247
Галим хуҗа бине Каландар хуҗа – 239
Гариф бине Сәламколый бине Фулад – 337
Гатаулла бине Алтынхуҗа – 403
Гатаулла бине Габденнасыйр бине Гайсә әш-Шәрифи – 242
Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуәт – 240
Гобәйдулла бине Сәпкол – 306
Госман бине Муса – 376
Гыйсамеддин бине Ибраһим бине Хуҗаш әл-Казаный – 258
Гыйсмәтулла бине Вәлид бине Нәзир бине Бикәнәй – 281
Гыйсмәтулла бине Габдеррахман бине Туймөхәммәд әт-Тайсуганый – 245
Гыйсмәтулла бине Рәфыйк бине Мөслим бине Килмәт – 345
Гыяседдин бине Хәбибулла бине Рахманколый – 430

## Д

Давыд бине Җәгъфәр бине Биккинә бине Сөбхан – 359
Дәүләтшаһ бине Мөхәммәдлатыйф бине Зәйнелгабидин бине Юныс – 419
Динмөхәммәд бине Габделбакый бине Морадым бине Шыгай – 330

## Җ

Җамаледдин бине Шәмседдин бине Хисамеддин бине Габделхәмид әс-Сабавый – 405

Җарулла бине Бикмөхәммәд бине Биктимер бине Котлыгфулад әл-Ишки – 425
Җәгъфәр бине Салих бине Мөхәммәдгали әл-Кулаткый – 371
Җәлаледдин бине Борһанеддин бине мулла Шәриф әш-Шыгайи – 417
Җәләледдин бине Әхмәд бине Габделҗәлил бине Ибраһим әл-Багышый – 318
Җәмаледдин бине Бикәш – 458
Җиһангир хан бине Бүкәй хан бине Нургали бине Әбелхәер хан – 248

## З

Зәйнеддин бине Габдеррәшид бине Габдекәй бине Атнакай бине Дусан – 401
Зәйнулла бине Улмазкол бине Хуҗамкол – 225
Зөлкарнәйн бине Хәлил әл-Кактамакый – 254

## И

Ибраһим бине Габдулла бине Мөслим – 237
Ибраһим бине Мәдйар бине Ярмәк – 291
Ибраһим бине Мөхәммәдрәхим бине Колыш бине Солтанбәк – 362
Искәндәр бине Каландәр суфый әл-Мәргыйнани – 463
Искәндәр бине Максуд бине Әхмәд бине Биги әл-Кирмәни – 391
Исмәгыйль бине Габдеррахман бине Габдулла әт-Тингәни – 342
Исмәгыйль бине Таһир бине Нәзир бине Туктамыш бине Мөслим – 364
Исмәгыйль бине Тимергали әс-Сөләйманый – 393
Исхак бине Ибраһим бине Габделмәҗид бине Әбүбәкер бине Ураз әл-Казаный – 439

## К

Каракай бине Исәнгали әл-Кундыравый – 332
Каһарман бине Буранкол бине Куәт – 333
Кәмаледдин бине Мирас бине Юзай – 283
Колмөхәммәд бине Гобәйдулла бине Гомәр – 427

Корбангали бине Әбүшәхмә әт-Тубылый – 445

Корбангали бине Мортаза бине Исмәгыйль бине Йосыф бине Исәнәй бине Исәнкол бине Борнагыл – 316

Корбангали бине Юлдашбай бине Бакыбай – 382

Корбангали бине Ягъкуб бине Исмәгыйль бине Сөбханкол бине Котый бине Бикән әл-Казаный – 375

## М

Максуд бине Корбангали бине Әднакол бине Мәскәү – 338

Мәхмүд бине Вәли бине Әмир Мәхмүд әл-Хөсәени – 400

Минуш бине Мостай бине Исмәгыйль бине Әхмәд бине Уразлы бине Уразай бине Уразгилде – 305

Минһаҗ бине ... бине ... [төп нөсхәдә шулай. – *Төз.*] әл-Мәдәни – 373

Миңлебай бине Габдеррәшид бине Йосыф – 351

Мифтахеддин бине Сәлимҗәүһәр бине Сөбханкол әл-Калмашый – 353

Морад бине Йосыф бине Аккош бине Күгәрчен – 294

Мостафа бине Йосыф бине Давыд әл-Казаный Ибнеззаман – 317

Мөхәммәд бине Габделҗәлил бине Мирсәлим – 238

Мөхәммәд бине Гыйрфан бине Габденнасыйр бине Бикмөхәммәд әл-Ишеви – 380

Мөхәммәд Хәлилулла бине Мөхәммәд Гофранулла бине Мөхәммәд Ризванулла... – 422

Мөхәммәдвафа бине Гобәйдулла – 346

Мөхәммәдвафа бине Фазыл бине Сәйфулла – 264

Мөхәммәделәмин бине Мөхсин бине Гали – 285

Мөхәммәделәмин бине Нәүрүзгали бине Габделкәрим бине Үтәгән бине Корбангали – 270

Мөхәммәдҗан бине Мәхмүд бине Максуд бине Габдулла – 357

Мөхәммәдҗан бине Хөсәен әл-Колчурый – 377

Мөхәммәдзариф бине Габделҗәмил бине Фәйзулла бине Бикмөхәммәд – 360

Мөхәммәдйосыф бине Әхмәр әл-Исәки – 358
Мөхәммәдкәрим бине Исхак бине Исмәгыйль – 310
Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим бине Гаид – 397
Мөхәммәдморад бине Габделкаюм әл-Бәдәхши – 423
Мөхәммәднәҗиб бине Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри – 407
Мөхәммәдрәхим бине Әмир бине Җәгъфәр әт-Таршынавый – 234
Мөхәммәдсадыйк бине Галиәкбәр бине Гайсә бине Ягъкуб бине Габдеррәззак бине Галим хафиз әл-Орый – 426
Мөхәммәдшаһ бине Мирас – саны юк, 289-290 арасында.
Мөхәммәдшәриф бине Габбас бине Габдулла бине Уразмәт бине Шәмшәб бине Шүшә – 456
Мөхиддин бине Хәсән – 415
Мөхсин бине Мәхмүд бине Габдулла бине Габделхәй бине Ишкинә бине Ишмәк бине Агый бине Нүкәш – 311
Муса бине Габид бине Дәвеки бине Заһид – 323

## Н

Нәҗмеддин бине Зәйнелгабидин бине Габдулла әл-Юлыкый – 434
Нигъмәтулла бине Биктимер бине Тукай бине Үтәгән әс-Салавычи – 226
Нигъмәтулла бине Габдеррәхим – 262
Нигъмәтулла бине Гобәйдулла бине Җәгъфәр – 300
Нигъмәтулла бине Мөнасиб әл-Бубый – 243
Нигъмәтулла хуҗа бине Зөннун хуҗа – 267
Низамеддин бине Вәйс бине Хуҗамколы – 350
Низамеддин бине Сәлимҗан – 460
Низамеддин бине Сираҗеддин бине Зәйнелгабидин бине Әбүшәхмә бине Габдерраззак бине Дустмөхәммәд бине әл-Мөхәммәд әл-Корычый – 336
Нияз бине Хәйдәр бине Ярымсәед бине Хәйдәр бине Гали – 259
Ногман бине Әмир бине Госман әс-Сәмәни – 255

Нурмөхәммәд бине Ибраһим бине Хуҗаш – 356
Нурулла бине Габдулла бине Баһадир – 363

# Р

Рәмкол бине Максуд бине Мөхсин бине Шәех – 301
Рәхмәтулла бине Гобәйдулла бине Җәгъфәр әл-Кизләви – 244
Рузмөхәммәд бине Гомәр әт-Тубылый – 451

# С

Сабанчы бине Ярмөхәммәд – 308
Сабит бине Габдри бине Габбас бине Исмәгыйль – 369
Сабит бине Сәгыйдь бине Салих – 340
Сәгъдеддин бине Габделҗәлил бине Заһид бине Гаид – 381
Сәгъдеддин бине Фәйзулла бине Үтәш – 367
Сәгъди бине Атнабай бине Сәярбай бине Колбай бине Акчуак бине Мирас – 436
Сәгыйдь бине Хәмид бине Йосыф бине Хәсән бине Габдеррахман бине Хәлилулла – 465
Сәгыйдь бине Хәмид бине Солтан – 325
Сәед бине Нурмөхәммәд – 263
Сәйфеддин бине Сөбханкол бине Бикмөхәммәд – 361
Сәйфулла бине Мирсәлим – 428
Сәйфулла бине Мортаза бине Мөхәммәдкол бине Мәмтәй Туйтик – 287
Сәйфулла бине Үтәгән бине Надир бине Сөбкә бине Сафәр бине Уразай бине Гаедхуҗа бине Шәмсехуҗа – 302
Сәйфулла бине Фәйзулла бине Габделгазиз бине Габдеррахман – 269
Сәйфулла бине Юрткәй бине Габдекәй бине Хатим бине Ишбулад бине Баймәт бине Байкилде бине Ябынчы бине Юл хуҗа – 303
Сибгатулла бине Габделкадыйр бине Сөләйман бине Мостафа әш-Шәрифи – 457

Сиражеддин бине Сәйфулла бине Үтәгән – 416
Сөләйман бине Ибраһим бине Йосыф бине Исәнәй – 322

## Т

Таҗеддин бине Әхмәр бине Динмөхәммәд бине Кадерле бине Колмый бине Алтын бине Айбакты бине Айдар – 448
Таҗеддин бине Габдессаттар бине Габдеррахман бине Хәсән – 378
Таҗеддин бине Гыйсмәтулла бине Сатылган бине Сөләйман... – 454
Таҗеддин бине Мансур – 275
Таҗеддин бине Мостафа бине Рамазан бине Ишнияз әл-Әшнәки – 252
Таиб бине Заид бине Колмөхәммәд әл-Уралый – 313
Таһир бине Габделхаликъ әт-Түнтәри – 236
Таһир бине Сөбханкол бине Баһадиршаһ бине Чиркәс әл-Питраксый – 387
Төхфәтулла бине Хәлил бине Сәгыйдь – 408
Туабил бине Сәбәкъ бине Сарман бине Күчтан бине Тимербулат бине Сиюш бине Тимаш – 233
Тулунхуҗа бине Муса – 229

## Ф

Фазлулла бине Фәйзулла әт-Тактавый – 442
Фазлыссаттар бине Габделҗәлил бине Мирсәлим – 260
Фазыл бине Ибраһим бине Арыслан бине Туймый бине Тимә бине Әмир Туган әл-Кимеви – 449
Фәезбәхеш бине Габделкоддус әл-Гомәри әс-Сирһинди – 253
Фәйзулла бине Галиәсгар – 296
Фәйзулла бине Мортаза бине Мөхәммәдкол бине Мәмтәй бине Туйтик – 288
Фәтхулла бине Сәфәргали бине әл-Хөсәен әл-Мәнәвези – 298
Фәтхулла бине әл-Хөсәен бине Габделкәрим әл-Орый – 223

Фәхреддин бине Бикмөхәммәд бине Рәхмәтулла бине Мәскәү – 389
Фәхреддин бине Габдеррахман бине Морадым бине Җиһанмөхәммәд бине Акмөхәммәд бине Ярмөхәммәд бине Назар бине Юныс – 250
Фәхреддин бине Зәйнелгабидин бине Габдулла – 386
Фәхреддин бине Ибраһим бине Хуҗаш әл-Казаный – 235
Фәхреддин бине Мостафа бине Рамазан бине Нияз – 368
Фәхреддин бине Мөхәммәдсадыйк бине Габдеррәфыйг әс-Сөни – 394

## Х

Хаҗи Гали бине Әбүбәкер бине Кинҗәгали – 347
Харис бине Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли – 431
Харрас бине Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли – 443
Хәбибулла бине Ишдәүләт бине Байгилде бине Котлыгөммәт – 289
Хәбибулла бине Мөхәммәдшәриф бине Биккол – 392
Хәбибулла бине Рахманколый бине Габдеррахман – 280
Хәбибулла бине Рәфыйк бине Мәхмүд бине Мөслим – 352
Хәмди бине Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза әл-Бәзнәви – 441
Хәммад бине Гайсә бине Габдүки бине Иштуган бине Иштирәк бине Ишали бине Бурбай – 261
Хәммад бине Халид бине Габделваһһаб бине Дусмөхәммәт бине Колмөхәммәд – 388
Хәсән бине Габделмәҗид – 227
Хәсән бине Муса бине Исмәгыйль бине Апанай – 374
Хәсән бине Муса бине Ягъкуб бине Исмәгыйль бине Үтәгән бине Баймирза бине Балтай – 414
Хәсән бине Хәмид бине Исмәгыйль бине Габдерраззак әл-Мөслими әл-Курсавый – 446
Хисамеддин бине Мөэмин бине Будач бине Айтуган бине Кудаш бине Апач бине Мирас – 231
Хөсәен Әбүшшәрәф бине Мөхәммәд бине Гомәр әс-Сагыйди әл-Кирмәни – 341

Хөсәен бине Йосыф бине Мөхәммәд бине Сөләйман – 383
Хөсәен бине Муса бине Ягъкуб бине Ишмәмәт – 324
Хөсәен бине Фәйзхан бине Фәйзулла бине Биккенә бине Исмәгыйль бине Тәңребирде әс-Сабачайи – 406
Хөснеддин бине Гомәр бине Сәед бине Ишмөхәммәд әс-Суыксувый – 444
Хөснеддин бине Ибраһим бине Бикмөхәммәд – 230
Хөснеддин бине Шәмседдин бине Җәгъфәр бине Сөбханкол – 421
Хуҗамбирде бине Сөенечбакый – 335

## Һ

Һибәтулла бине Исхак бине Ибраһим бине Бикмәт – 462
Һибәтулла бине Сәедбаттал бине Салих бине Бикмөхәммәд бине Ишмөхәммәд – 409
Һибәтулла бине Тимергали бине Габделкәрим бине Габдерраззак бине Саби бине Атаби бине Кырым бине Әлмән – 284

## Ш

Шаһиәхмәд бине Йосыф бине Котлыгмөхәммәд бине Тәүкил – 241
Шәех Мөхәммәдгаяз Тантавый – 402
Шәмвил бине Мөхәммәд – 437
Шәмседдин бине Бәшир бине Морад әл-Кишети – 315
Шәмседдин бине Зөбәер бине Җәгъфәр – 312
Шәмседдин бине Мөхәммәдъяр әл-Пәрәви – 366
Шәмседдин бине Ярмөхәммәд бине Гобәйдулла – 399
Шәрәфеддин бине Зәйнеддин бине Ибраһим бине Җаукай бине Уйбакты бине Мәнгеш бине Собай бине Җомай бине Нугай – 249
Шәрәфеддин бине Сәгыйдь әл-Юкәли – 295
Шәфи бине Ягъкуб бине Габделҗәлил бине Ибраһим бине Балтай әл-Багышый – 398
Шиһабеддин бине Фәхреддин бине Мортаза бине Габделгазиз әл-Казаный – 379

# Я

Ягъкуб бине Яхъя бине Җәгъфәр әт-Төбъйазый – 246

## Географик атамалар күрсәткече

## А

Агарды – 228

Адай – 252, 265, 387

Адәмсуы – 390

Айдар – 448

Аккирмән – 228

Аллагуат – 403

Атҗитәр – 237

Ахун – 237, 260

## Ә

Әгерҗе – 339, 368

Әлкәзи – 334

Әлкәй – 230, 256

Әлмән – 284

Әлмәт – 300

Әнәч – 230

Әсән – 324

Әстерхан (Хаҗитархан) – 239, 267, 271, 290, 306, 347, 463

Әтнә – 299

Әшнәк – 340

## Б

Багыш – 318

Бакырчы – 413, 430

Балтач – 277, 297, 331

Балыклы – 270, 399, 404

Балыклы Күл – 226, 355, 404, 421, 436

Баулы – 319

Бәйрәкә – 240

Бәләбәй – 230, 250, 256, 265, 276, 277, 298, 310, 321, 337, 353, 401, 455

Бәрәзә – 465

Бәрәскә – 243, 246, 251, 277, 316, 322, 325, 435

Бәхтияр – 250

Бигәнәй – 283

Бигеш – 417

Бикәш – 346

Бикбау – 455

Биккол – 282

Богады – 276

Богдан – 279

Богырослан – 256, 301, 404, 418

Болак – 281

Болгар – 361

Борбаш – 432

Борнак – 312

Бостан – 309

Бохара – 223, 226, 232, 233, 234, 235, 237, 238, 242, 246, 249, 257, 264, 265, 274, 277, 278, 286, 292, 294, 296, 297, 306, 308, 316, 319, 321, 325, 327, 329, 332, 334, 335, 337, 341, 349, 354, 358, 360, 371, 372, 373, 379, 382, 388, 389, 390, 391, 395, 397, 407, 410, 413, 416, 421, 422, 430

Бөгелмә – 224, 231, 232, 240, 245, 247, 256, 291, 301, 303, 319, 323, 331, 346, 351, 352, 361, 395, 404, 453, 459, 461

Бөре өязе – 227, 233, 272, 303, 311, 314, 342, 417, 419, 424, 429, 454

Бөрсет – 394

Буа – 292, 305, 372,

Бубый – 243, 457

## В

Верхнеурал өязе – 225, 289, 293, 313
Вятка – 223, 426

## Г

Габдеррәшид – 294
Габдрахман – 224, 232, 351, 459
Гыйҗдуван – 286

## Д

Димәшкъ – 223, 229
Дүртиле – 390

## Җ

Җиргән – 229

## З

Зәй елгасы – 224, 352, 459, 462
Златоуст – 294, 334, 345, 362, 427, 436, 450

## И

Иделбай – 362
Илче – 293

Имән Елга – 334
Исәк – 269, 358
Иске Әлмәт – 273, 401
Иске Иштирәк – 301, 404
Иске Тазлар – 257
Иске Чокыр – 417
Истанбул – 259, 290, 313, 342, 351, 397, 400, 415, 444, 459
Исфаһан – 224
Иши – 380, 389
Ишмәт – 399
Ишмәтче – 423
Иштирәк – 301

## Й

Йәркәй – 227
Йуртыш – 385

## К

Кабул – 277
Каенлык – 311
Казаклар – 298, 446
Калкан – 225
Калмаш – 353
Каменка – 282
Кандракүл – 277
Кара Чишмә – 405
Карадуган – 297
Кармыш – 392

Касыйм – 309, 428

Каһирә – 259, 265, 271, 373, 415, 416

Кәшер – 231, 232

Келәнче – 275

Кенәр – 340, 457

Кече Әшнәк – 368, 456

Кече Күккүз – 392

Кече Сөн – 394

Киекле – 397

Кизләү – 282, 324, 447, 462

Кизләү-Курманай – 244

Киме – 449

Кичүчат – 232, 247, 301, 351, 361

Коддес (Иерусалим) – 228

Комыргужа – 302

Коры Алачык – 314

Корыч – 265, 336, 455

Котаймаз – 456

Куәт – 333

Куйсу – 400

Кулаткы – 371

Кундырау – 332

Курса – 348, 389, 409, 446

Күки – 275

Күлбаш – 338, 465

Күскәй – 228

Күшәр – 246, 307, 447

Кызылъяр – 302, 325, 330, 334, 391, 416

Кырмыскалы – 405

Кышкар – 246, 413

# Л

Лаеш – 275, 304, 340, 348, 366, 368, 425, 446

# М

Мазарбаш – 432

Малмыж – 226, 236, 281, 349, 387, 414, 458, 460

Мамадыш – 231, 283, 348, 255, 362, 365, 389, 394, 397, 415, 425, 458

Мачали – 271

Мәдинә – 228, 289, 298, 313, 316, 368, 371, 373, 437, 439, 459

Мәккә – 228, 259, 298, 415, 431, 438

Мәмәш – 297

Мәмсә – 274

Мәңгәр – 329, 475, 378, 388, 415, 435

Мәтәскә – 348, 456

Мәчкәрә – 236, 241, 330, 348, 349, 430, 458

Мәчтәй – 310

Минҗар – 303

Минзәлә – 232, 272, 310, 331, 373, 381, 401, 405, 417, 424, 442, 455, 458, 462

Минзәләбаш – 224

Мисыр – 228, 371, 402

Мишәбашы – 365

Морзалар – 398, 436

Мөлек – 369

Мөндеш – 287, 288

Муйнак – 238

Муллагөлем – 249

# Н

Наласа – 285, 348, 412

Наратлы – 232

Нәдер – 352

Нижгар – 370, 371, 400

Норма – 285, 348

Нөркәй – 401

Нурлат – 369

# О

Олы Әтнә – 412

Олы Имән – 310

Олы Мәнгәр – 378, 415, 446

Оренбург – 223, 241, 248, 262, 268, 269, 270, 281, 289, 301, 349, 370, 376, 392, 399, 403, 418, 462, 465

Ормышлы – 232

Орск – 263, 382, 434

Оры – 223, 289, 364, 426, 432, 435, 457

# П

Пәрәү – 366, 384, 425

Пенза – 262, 271, 428

Пермь – 350, 423

Петербург – 232, 248, 270, 400, 402, 431

Рәдүд – 241, 332

Рәҗәп – 447

# С

Саба – 301, 334, 362, 405, 432, 462

Саз – 350

Салавыч – 226, 432, 460

Салҗут – 295, 450

Самара – 305, 371

Сарапул – 243, 339, 368

Саратов – 367, 371, 404, 428

Сарсаз – 419

Сарыалан – 275

Сасна – 281, 414, 453

Сатыш – 231, 425

Сафакүл – 396

Сәгыйдь – 223, 240, 241, 249, 256, 261, 271, 281, 282, 302, 341, 376, 398, 409, 415, 457, 458

Сәед – 289, 347

Сәмән – 255

Сәмәрканд – 371, 448

Сәрдә – 302, 340, 358

Сәрдек – 297

Сембер – 223, 305, 331, 428.

Семипалат (Сими) – 329, 342

Симетбаш – 413

Сингел – 304

Солтанай – 464

Сөләйман – 393

Спас – 270, 340, 371, 384, 447

Суыксу – 372, 385, 444

Сүтәк – 420

Сынташтамак – 228

# Т

Табын – 272

Таганрог – 399

Тайсуган – 245, 256, 351, 395, 461

Такталачык – 395, 424, 433, 442

Танта – 402

Тара – 259, 296

Таршына – 234

Тахталы – 409

Ташкент – 223, 245, 371, 423, 435

Ташкичү – 246, 327

Тәкәнеш – 397

Тәтеш – 269, 318, 358, 385, 392, 398, 413, 420, 465

Тәхтәле – 282

Тифлис – 252, 368, 371

Төркестан – 233

Төркия – 228

Троицки – 232, 238, 360, 369, 435, 461

Тубыл – 296, 308, 335, 445, 451

Тугызак – 462

Туйгилде – 232, 331

Туймазы – 321

Туймы – 357, 411

Түбән Урысбага – 270

Түбән Шәлчәле – 245, 351

Түнтәр – 277, 313, 325, 349, 386

# У

Урта Тигәнәле – 340

Урыссу – 395

Уфа – 228, 232, 255, 266, 284, 285, 305, 315, 340, 343, 364, 370, 393, 395, 397, 398, 408, 411, 413, 421, 426, 431, 436, 446, 453, 459, 464

## Ү

Үтәк – 355

Үтәмеш – 305

## Х

Хәсәншәех – 277

Хиҗаз – 228, 241, 248, 259, 290, 294, 296, 298, 308, 313, 322, 366, 391, 397, 415, 459

Хуҗабик – 289

## Ч

Чабаксар – 284, 392

Чалпы – 224, 233, 247, 291, 401

Чебенле – 261, 281, 409, 455

Чиканас – 252

Чиләбе – 237, 360, 369, 396, 452

Чирмешән – 465

Чиртуш – 349

Чистай – 224, 232, 273, 282, 300, 349, 390, 401, 409, 435, 458

Чокалы – 441

Чокыр – 272, 417

Чураш – 415

## Ш


Шәдче – 458

Шәмәк – 408

Шөгер – 232, 301

Шушма – 301

Шыгай – 245, 330, 383, 417


## Э


Эстәрлебаш – 226, 343, 399, 421, 431, 442, 443

Эстәрлетамак – 226, 229, 249, 343, 355, 403, 421, 431, 436, 452


## Ю


Югары Сәед – 353

Югәмеш – 233

Юкәле – 295

Юкәле Күл – 419

Юлга – 324

Юлык – 238, 261, 452


## Я


Ялгыз Каен – 355

Ямаширмә – 324

Яңа Кишет – 315

Яңа Мөслим – 345

Яңасала – 275

Яубаш – 457

## Эчтәлек

Икенче том ........................................................................................ 1

Төзүчеләрдән ........................................................................................ 3

ТУГЫЗЫНЧЫ КИСӘК........................................................................................ 4

УНЫНЧЫ КИСӘК........................................................................................ 13

УНБЕРЕНЧЕ КИСӘК........................................................................................ 39

УНИКЕНЧЕ КИСӘК ........................................................................................ 71

УНӨЧЕНЧЕ КИСӘК........................................................................................ 87

УНДҮРТЕНЧЕ КИСӘК........................................................................................ 106

УНБИШЕНЧЕ КИСӘК........................................................................................ 132

Шәхесләр күрсәткече ........................................................................................ 152

Географик атамалар күрсәткече ........................................................................................ 164

Эчтәлек ........................................................................................ 175